PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2021 ГЫЙНВАР № 1

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



бала авырый СӘБӘПНЕ... үзеңнән эзлә

ҖӘВИТ ШАКИРОВ һәм үги әни ачыктан-ачык сөйләшәбез

яшел карабодай ипие ПЕШЕРЕП карыйбызмы

Резеда САФИУЛЛИНА:

«Булдырам дип яшәргә кирәк!»

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!



Илсөяр ИКСАНОВА

МИН ӘНИ БУЛДЫМ, ӘНИ!..

Син мине уйлаганымнан
Күбрәк сөйгән икән.
Син дә аңламыйсың дисәм,
Син мине хәтта үземнән
Күбрәк белгән икән.

Күзләрем ник сары дисәм,
Синең сагыштан икән.
Җанга ник ут капты дисәм,
Хисләр табышкан икән.

Мин дә бүген синең кебек
Гамьнәргә тулдым, әни.
Мин сине яңа аңладым –
Мин әни булдым, әни!..

■ Әни белән икәү гаилә ядкаре булдырдык. Безнең эскизлар буенча зәркәнче туганыбыз алка һәм йөзек эшләде. Аларны хәзер әнием тагып йөри. Аннан, гаиләбез мирасы буларак, алар миңа күчәчәк. Чәчләрем чаларгач, мин алараны кызым Хәяткә тапшырырмын. Ул исә – үз кызына...

Аида Яруллина, Казан.

Фото: А. Антонова.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Резеда Сафиуллина
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр
Ильмира Сөләйманова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 11.01.2021 ел.
Чыгу көне: 18.01.2021 ел.
Заказ А-3534
Тираж 9350

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Россиядә: ПО279 (берьеллык)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

PRESSA



Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Кешене өмет яшәтә, диләр. Тагын... максат! Һәм ул максатка ирешү өчен ясаган адымнар... Аннан хыял! Салих бабабыз (иремнең дәү әтисе безнең белән яшәде) арабыздан 103 (!) яшенә бер ай тулмыйча китеп барды. Хәзер аның сөйләгәннәрен күңелемнән барлап, искә төшерәм дә, аның гомер буе үзалдына максат куеп яшәгәнен аңлыйм. Авылдан беравыз русча белмичә килеп, бөтен Казанга билгеле, дан тоткан кием кисүче булуга ирешкән. Сугыш юлын үткән. Бер карасаң, барыбызның да тормышы төрле максатларга ирешеп үтә. Ә безнең бабайны әле хыял белән өмет тә яшәткән икән. Күз алдына китерәсезме, тормыш тәмен югалтмыйча 90 яшенә җиткәндә ул Казанның меңьеллыгын күреп, метрода бер әйләнеп кайту турында хыяллана башлады. Һәм бу максатка ирешү өчен ул барысын да эшләде: физик күнегүләр ясады, дөрес тукланды, кан басымы күтәрелсә, ятып тору урынына – саф һавага чыгып, үзе әйтмешли, «бер-ике әйләнеп» кайтты... Өмет катыш икенче хыялы – Универсиаданы күрү... Анысына да иреште ул вакытта инде йөзгә якынлашып килүче Салих бабабыз. Ә 2016 елда юбилее – 100 яше белән котларга килгән Казан мэры Илсур Метшинның: «Нәрсә бүләк итик? Нинди теләгегез бар?» – дигән соравына бабай: «2018 елда узачак Бөтендөнья Футбол чемпионатына билет кирәк», – дип җавап бирде. Тагын бер хыял! Максат һәм өмет!..

Ни өчен боларны сөйлимме? Яңа кергән елны да төрлечә фаразлыйлар. Тик без күңел төшенкелегенә бирелмичә, яшәү ямен югалтмыйча, өметне өзмичә көн саен максатка бер адым булса да алга атлыйк. Һәм хыялланыйк...

Безнең белән булганыгыз өчен рәхмәт!

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Фото: Анна Арахамия

Безнең тышлыкта

«Киләчәктәге урыныңны билгеләр өчен, хәзерге урыныңны аңларга кирәк. Хәзергесен аңлар өчен, каян килгәнеңне белергә кирәк!»



10 «Башкача яши белмим...»
Эльмира Закирова

Заман һәм без



6 «Әни, эчмә!»
Чулпан Галиәхмәтова

14 Даруга үрелгәнче...
Раилә Хәялиева



18 Театр яшәтә, яшәртә...
Гөлнур Хәсәншина



20 «Идеаль артист буласым килми...»
Чулпан Галиәхмәтова

22 «Сезне күрер өчен генә кайттым...»
Рамилә Яруллина-Йылдырым

Татар дөньясы



26 Олы йорт килене
Лилия Гәрәева




30 «Мишәрләрем...»
Гөлнур Сафиуллина

Мәдәни тормыш



36 Бүләк
Диләә Булгакова

Яшәеш



44 Үги әнкәйнең җылы йөрәге
Чулпан Галиәхмәтова



48 Карел иле
Чулпан Әхмәтова

Хуҗабикә

57 «Өченче ияк»тән котылып буламы?

58 Балалар бүлмәсе
Раилә Хәялиева



60 Сырлы котлет белән бәрәңге

АКТУАЛЬ ТЕМА

«ӘНИ, ЭЧМӘ!»



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

– 17 яшемдә төрмәгә эләктем... Үзем теләп... Өйдән кая булса да китеп олагыр өчен. Башкача болай яши алмаячагыбызны аңладым...
Каршымда утырган Розалия (*исеме үзгәртелде. – Ч. Г.*) әкрен генә куе кәһвә эчә. Карашы билгесезлеккә төбәлгән. Уйлары – балачагында. Ул чакларны искә төшерү җиңел түгел аңа. Хәмергә үрелгәнче, хатын-кызлар балалары хакында уйласын иде, бәлки, минем тарих кайберәүләрне кыек юлга кереп китүдән саклап калыр дип, үз язмышын сөйләргә ризалык бирде. Хатын-кыз эчкечелегеннән дә яман һәм куркыныч күренеш юк. Әгәр дә әниең сәрхуш икән, бу инде – фаҗига... Гаилә таркала, балалар әниле килеш ятимлек ачысында яши башлый.

Исерек әниле балачак

Казакъстанда узган балачагын сагына Розалия. Бер генә сәгатькә булса да кайтып килер иде шул чакка... Алар дүрт бала. Чибәр әнисе. Балалары, гаиләсе өчен үлеп торган әтисе. Менә әтисе эштән кайтып керә. Алар тезелешеп әтиләрен үбәргә чират торалар. Аннан бергәләп ашарга пешерәләр. Әниләре сменадан кайтып кергәнче, биш бүлмәле фатирның һәр почмагын җыештырып чыгалар. Әниләре кырыс: чисталык ярата. Өйдә һәрнәрсәнең үз урыны булырга тиеш. Берсеннән-берсе кечкенә балалар формаларын үзләре юып, үтүкләп кия. Әниләре шулай өйрәтте. Бик яхшы яши алар. Грециядән кайткан киемнәр генә кияләр. Әниләренең һәр күлмәгенә аерым туфлиләре бар. Үзен карарга, дус кызлары белән аралашып яшәргә ярата. Әтисе моңа каршы бер сүз әйтми. Чикләрне белмәгән хатын-кызга ирек куярга, артык йомшак булырга ярамый икән... Тормыш тәҗрибәсе туплаган Розалия хәзер шундый фикердә. Әнисе калыпка керергә яратмады, чикләрне дә санга сукмады. Үзенчә яшәде...

90 нчы елларда әтисе туган якларына тартыла башлый – Татарстанга кайтып китә. Аның артыннан дүрт баласы белән хатыны да кайта. Эштән курыкмаган әтиләре район үзәгендә ике катлы йорт сала. Әниләре монда да иркен һәм иректә тормышта яшәргә омтыла. Тиз арада иптәш кызлар табыла. Әмма монда бәйрәм итү башка төрлерәк икән бит – эчеп күңел ачуга корылган. Әниләре салмыш булып кайта башлый. Дөрес, әтиләре сиздермәскә тырыша. Күңел ачып кайткан хатынын балалары күз уңыннан качыра, тизрәк йокларга яткыра. Кечкенә энеләре сизмәсә дә, апасы белән Розалия сизенә-сизенүен. Кечкенә булгангамы, моны фаҗига дип кабул итмиләр. Якларга, назларга әтиләре бар бит! Әмма көннәрдән бер көнне әтиләренә инфаркт булып үлеп китә. Ул көнне хәзер дә хәтерли Розалия. «Минем өчен тормышның мәгънәсе бетте. Үләсем генә килде», – дип искә ала. Әнисе бөтенләй сына... Башын җуеп эчә башлый.

– Әнинең, күрәсең, проблемалардан качасы килгәндер. Әмма проблема беркая да китми! Ярар, бүген эчтең дә онытылып ятып йокладың ди. Иртәгә иртән уянасың, ә проблема шул ук, җитмәсә, үзеңә дә оят. Аны барыбер хәл итәргә кирәк. Бераз эчкәч хәл булып китә диючеләр дә бар. Әмма төрле кешенең организмы төрлечә. Кемдер туктый ала, ә кемнәрдер чикләрне белми. Ул – кешенең җаваплылык хисе ни дәрәҗәдә булуыннан торадыр. Балалар бар. Аларның бер гаебе дә юк бит. Шуңа күрә иң элек алар турында уйларга, балаларга иң яхшысын гына бирергә тиешбез. Ә моның өчен аек акыл белән яшәү зарур.

Розалиянең әнисе балалары хакында уйламый. Үсмерлек чорына кергән Розалия исерек әнисе янына килгән шешәдәш «дусларына» каршы чын көрәш ача. Алар белән кычкырыша, сугышып булса да куып чыгарырга тели. Соңыннан туеп, кул селтәп. «Эчсеннәр, аның каравы, безгә ирек», – дип, апасы белән өйдән чыгып китү ягын карыйлар. Шушы тормышына күнегә башлый кыз.

– 90 нчы еллар ахыры бит ул. Беркем беркемгә кирәкми торган заман. Упкын читендә үзебез генә басып калдык. Социаль опекадан килделәр килүен. «Әнидән аерылмыйбыз», – дип нык тордык. Нинди булса да, ул бит безнең әни! Алар шул җавап белән ризалаштылар, күрәсең: безне социаль яктан начар булган гаилә дип исәпкә бастырдылар да оныттылар. Хәзер социаль опека нәтиҗәле эшли: эчкән аналардан балаларын алып китәләр. Бәлки, мондый алым кирәктер дә. Бала белән аерылуын аңлагач, күпләр акылларына килә. Әни безне югалтудан курыкмады, шуңа эчүен ташлау турында уйламады да. Кара эшче булып эшләп йөрде. Ашарга булмаган вакытлар да бар иде. Әтинең пенсия акчасына яшәдек. Ул акчаларны да эчә башлагач, килгән пенсияне күршеләрдә сакладык. Әз-әзләп кенә тоттык: үзебез азык-төлек, киемнәр сатып алдык. Авылда исерекне упкынга тибеп төшерергә генә торалар. Тирә-яктагы күршеләр әни өйдән алып чыгып киткән әйберләрне бер шешә аракыга сатып алалар иде. Хәтта исерек әнидән безнең киемнәрне дә аракыга алыштырудан чирканмадылар. Айныган вакытларда әни баштарак гафу үтенә иде, аннан ул да онытылды. Әмма ничек кенә яшәсәк тә, өйдә һәрвакыт чисталык булды. Үзебез җыештырдык, ашарга пешердек. Әни берәр атна баш күтәрми эчә дә, ике атна аек йөри. Ул вакытларда өйне ялап чыгара, безне карый. Энеләрем әнине бик ярата иде, бездән сүз дә әйттертмәделәр. Эчкәч, балаларын мыскыл итеп, урамга куып чыгарган әниләр турында ишетәм хәзер. Безнең әни алар белән чагыштыргандa бик яхшы булган икән дип уйлыйм. Ул хәтта миннән курка да иде...

Буй җиткән кызлар әниләреннән оялалар, әмма кешедән аңа начар сүз әйттертмиләр. Тик артык ирек, олылар игътибары булмау Розалияне кыек юлга кертеп җибәрә. Тугызынчы сыйныфтан соң укуын ташлый. Укытучылар артыннан ялынып килсә дә, мәктәпкә аяк атламый. Кара эшче булып ялланып эшли. Тәмәке тартырга өйрәнә, дуслары белән бәйрәм итәргә дә ярата. Айныган вакытларда әнисе тәрбияләргә тырышып караса да: «Син башта үзеңне тәрбиялә», – дигән сүз ишетә. Әниләре үзе кебек үк эчкече ир белән яши башлый. Айныган вакытларында гына балалары янына кайта. Апасы башка районга укырга китә. Розалия ике энесе белән үзе генә кала.

Өлкәннәр игътибары булса, бәлки, ул 13 яшендә гомер буена сузылачак тагын бер психологик яра да алмаган булыр иде. Аны көчлиләр... Бик тә мотоциклда йөрергә өйрәнәсе килә аның. Бер ир кисәге өйрәтергә тәкъдим итә. Утыртып алып китә дә көчли... Бу хакта Розалия беркемгә дә сөйләми. Ул аның гомерлек сере булып кала. «Әнигә әйтүдән файда юк иде. Милициягә бармадым. Балаларын жәлләдем. Үзе белән очрашмаска тырыштым, чөнки үз-үземне кулга ала алмаган булыр идем. Аңа минем күз яшьләрем төште. Ул күптән үлде инде», – ди Розалия...

Барысын да айныткан вакыйга булмаса, тормышлары ничек дәвам иткән булыр иде икән?!. 17 яшендә Розалияне кеше үтерүдә гаепләп, төрмәгә утырталар. Өйләренә исерек ирләр алып килгәне өчен әнисенең бер шешәдәш хатыны белән сугышып чыгып китә. Кире кайтып кергәч, шул хатынның мәетенә тап була. Үтермәдем дип акланып та тормый. Аны өч ел ярымга ирегеннән мәхрүм итәләр. Башта балигъ булмаганнар колониясендә утыра, 18 яше тулгач, Белгородка хатын-кызлар төрмәсенә җибәрәләр. Розалия төрмәгә утыргач, әнисе эчүен ташлый. Өч ел буе кызы белән күрешергә йөри, посылкалар сала, елый, гафулар үтенә... «Төрмәгә эләгүемә үкенмим, – дип искә ала ул елларны Розалия. – Анда эләкмәгән булсам, хәзер ни рәвешле яшәр идем икән, бәлки, исән дә булмас идем...»

Төрмәдән Розалия башка кеше булып чыга. Дуслары белән күңел ачудан ямь тапмый. Аның башкача яшәп карыйсы килә. Кечкенә чактан ук үзен яратып йөргән егеткә кияүгә чыга. Яратырга рөхсәт итә. (Розалиянең яратып караганы юк. Хәтта бе-



Гүзәл ГЫЙЛӘҖЕВА, Республика наркологик диспансерының икенче хатын-кызлар стационарының бүлек мөдире.

Алкоголизм – күп факторлы авыру. Нәселдәнлек тә, шәхес тибы да, тәрбия шартлары да, мохит тә роль уйный. Моннан кала, хатын-кызларга психологик фактор да тәэсир итә. Бигрәк тә озакка сузылган депрессияләр шешәгә үрелергә мәҗбүрили. Алкоголизмнан дәваланганнан соң кабат яшел елан белән дуслашу сәбәпләрен менә болай аңлатыр идем. Пациентларның кайберләре дәвалануны формаль рәвештә генә уза, «организмны ял иттерү өчен» генә дигән максат куя. Бераз «ял»лардан соң үз теләге белән элекке тормышына кайта. Башкалары табиб киңәшләрен тотмый, үзенә, ихтыяр көченә артыгы белән ышана. Бары тик дәваланучы хатын-кызларның бер өлешендә генә терелү өчен мотивация була. Алар табиб ярдәме белән озакка сузылган ремиссиягә китә. Алкоголизмны бөтенләй дәвалап бетереп булмый, ул хроник авыру. Әйткәнемчә, бары тик озакка сузылган ремиссия генә бар. Дәвалану берничә этаптан тора, ул озак вакыт һәм күп көч сорый.

Фото: www.pixabay.com

ЗАМАН һӘМ БЕЗ



ренче мәхәббәте дә булмый. Әтисе кебек ир-ат очрата алмый ул.) Ике бала таба. Төрмәдә тегүчелек һөнәрен үзләштергән Розалия эшкә керә. Әмма җанына ятмый. Аның бит кечкенәдән үк хыялы – тортлар пешерү. Башта кулинар рецептлар буенча, аннан соң интернеттан карап, әкренләп торт пешерү серләренә төшенә. Заказлар кабул итә башлый. Бүгенге көндә аның төп кәсебе дә шул. Бу һөнәре аңа тормышны алып барырга, балаларын ашатырга ярдәм итә. 15 ел яшәгәннән соң ире белән аерылыша.

– Исерек әнидән китеп, тагын исереккә барып эләктем. Башкача түзә алмадым – аерылдым. Әйе, гаиләмне саклап кала алмаганыма балаларым алдында үземне гаепле хис итәм. Әмма алар исерек янында үсәргә тиеш түгел дип уйладым, – ди Розалия. – Заказлар күп җыелып, тәүлегенә икешәр генә сәгать йоклаган вакытларым була. Кирәкле ингредиентларны Казаннан килеп алам. Казанга күрше авылга йөргән кебек кенә барып кайтам. Ике-өч көн заказ булмый икән, интернеттан шабашкалар эзли башлыйм. Ике баламны аякка бастырырга кирәк. Безнең белем алыр өчен акылыбыз да, тырышлыгыбыз да бар иде, әмма тәрбияләүче, кайгыртучы кеше булмады. Әгәр әни эчмәгән булса, әти дә исән булыр, без дә укып кеше булган булыр идек, тормышыбыз да башкача булган булыр иде. Минем балалар институтта белем алырга тиеш. Алар белемле булсын өчен барысына да әзермен, хәтта идән юарга да. Алар минем бәхетсез балачагымны кабатларга тиеш түгел...

– Әниегезгә үпкәгез зурдыр?..

– Әниләр төрле була. Безгә менә шундый әни язган. Язмыш эшедер. Ничек үпкә булмасын инде?! Хәзер аралашып яшибез, әни балаларымны карарга ярдәм итә. Моның өчен бик зур рәхмәтлемен аңа. Әмма арада җылылык юк. Гафу иттем мин аны, әмма йөрәк яралары төзәлми икән ул. Аңлыйм: бәлки, ул гаепле дә түгелдер. Алкоголизмга нәселдәнлек факторы да тәэсир итә, диләр. Әнинең әтисе сәрхуш булган. Әмма шулай да ул җавапсызлыктан килеп чыгадыр дип уйлыйм. Хәзер дә ачуым килгән чакларда балачак елларын әнинең исенә төшерәм. Елый, бик үкенә, әмма терсәк якын, тешләп булмый шул. Ул вакытларда безгә килеп йөргән кешеләрне күреп таныcам, йөрәгем сикерә башлый. Аларга нәфрәт белән карыйм. Яннарына килеп: «Менә сине кем дип атарга инде? Кечкенә балалар яшәгән йортка эчеп күңел ачарга килә идең. Синең аркада чыгып китә идек. Безгә ябыша да идең. Үземне, апамны яклап сугышкан вакытларым да булды», – дип әйтәсем килә кайчак. Шул йөрәк яралары нәтиҗәседер инде: кешеләрне яратмыйм. Читтәрәк булырга тырышам. Әйе, ярдәм сорасалар, кулымнан килгәннең барысын да эшлим, әмма күңелемне бервакытта да ачып салмыйм. Бәлки, кабат яра салынудан куркамдыр... Мәктәптә Әниләр көне бәйрәмнәренә чакыралар. Әлбәттә, берсен дә калдырганым юк, барам. Шунда әниләр турында җырлар тыңлаганда туктый алмый елыйм. Әниемә бит шундый җырлар җырлый алмадым. Мәктәптән открыткалар ясап алып кайтып кулына тоттырмадым. Шатланганын күрмәдем. Бик авыр балачак булды.
Күп ялгышлыклар эшләдем, бу хакта балаларым да белә. Алар мине аңлады. Балаларыма әйтәм: «Кеше ялгышмый калмый, әмма болар киләчәккә сабак булырга тиеш...» Эчкән әниләр киләчәгенә балта белән чаба, шул хакта уйлансыннар иде. Бала янда калырга мөмкин, ләкин югалган җылылыкны кайтару бик авыр.
Ә көлдән кеше булуы – икеләтә...

Барысы да аруны басудан башланды

– Мин шәхес типы буенча – күгәрчен. Артык киң күңеллемен, кешеләргә юк дип әйтә белмим. Эчүгә сабышуымның сәбәбен психологлар шулай дип аңлатты, – ди ике бала

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Алсу ХАННАНОВА, психолог

Алкоголизмның сәбәпләре күптөрле: үзеңә ышанмау, курку, уңышсызлыкка очрау, кешеләр белән мөгамәлә кора белмәү. Ә хәмер чикләрне юа. Кешенең дөрес итеп ял итә белмәве дә сәрхушлеккә китерергә мөмкин. Бары тик спиртлы эчемлекләр эчеп кенә ял итә алам дип уйлау – зур ялгышлык. Якыннарыгыз хәмер белән дуслаша икән:

■ Иң элек аның белән утырып сөйләшегез. Максат: әрләп акылга утырту түгел, ә аны аңларга тырышу булсын. Сөйләшү барышында эчә башлау сәбәпләре ачыкланырга мөмкин.

■ Әгәр дә сөйләшү барып чыкмаса, аның өчен абруйлы булган кеше белән сөйләштереп карагыз. Һәркемнең хөрмәт иткән кешесе булмый калмый.

■ Алкоголизм – авыру. Психика бозылуның бер төре. Яман шешне өйдә дәвалап булмаган кебек, эчкечене дә белгечләргә күренмичә аякка бастырып булмый. Авыру белән психолог, наркологка бару мөһим. Үзе кебек үк авырулардан торган төркем белән бергә терапия алу дәвалануда уңай нәтиҗәләр бирә. Төркемдәшләр бер-берсенә теләктәшлек белдереп, дәвалану курсын яхшырта гына. Әгәр дә белгечкә барырга теләми икән, ультиматум куегыз. Бу – авыруны сагайтачак.

■ Әлбәттә, авыруның ихтыяр көче булуы – мөһим компонент.

■ Спорт йә иҗат белән шөгыльләнә башлау дәвалануда ярдәм итә. Җанга якын хобби табып, алкогольне онытып торырга мөмкин. Аннан соң иҗади күзаллау эчәсе килү теләге тудыра торган сигналларны баса. Бу – белгечләр тарафыннан расланган факт.

■ Әлбәттә, аралашу мохитен үзгәртү. Шешәдәшләр белән аралашуны туктату, чөнки алар кабат упкынга өстериячәк.

■ Дәвалану узганнан соң, авыру кабат шешәгә үрелергә мөмкин. Моңа әзер булырга һәм фаҗига ясамаска кирәк. Авыру белән кабат эшли башлау зарур. Онытмыйк: алкоголизм – хроник чир.

анасы 35 яшьлек Камилә. Өстәвенә, ата-анасы да эчкече була. Баласын югалткач кына акылына килә ул.

Кияүгә чыгып бала таба. Ире ярдәм итми. Кулында – күкрәк баласы. Җитмәсә, әнисендә Альцгеймер авыруы. Кичләрен, баласы йоклагач, «ял итү» гадәткә кереп китә. Көнне сыра эчү белән тәмамлый. Башын югалтып эчми дә ул, алкогольсез яши дә алмый. Җиде елдан соң тагын бер бала таба, аннан – тагын берне. «Алар барысы да бер әтидән. Шуның белән горурланам. Өч баласы өч ирдән булган иптәш кызларым бар. Мин алай йөрмәдем, әмма, кызганыч, эчтем», – ди Камилә. Кечкенә балаларын олы кызына карарга куша да, кухняга ябылып бәйрәм итә. Кызы киреләнә башласа, кибеттән тәмле әйберләр алып биреп юмалый. «Бу – иң җайлы алым. Балалар да тыныч, син дә үз көеңдә. Шулай итеп балаларның күңелен күрдем дип уйлыйсың. Ә бит аларга тәмле әйбер түгел, бергәләп утырып уйнау кирәк. Мин моны хәзер генә аңлыйм», – ди ана. Үсә төшкәч, үсмер кызы ризасызлык белдерә башлый. Низаглар чыга. Ире белән дә мөнәсәбәтләре начарлана. Шундый көннәрнең берсендә төнлә өйләрендә янгын чыга. Абыйсының тәмәке төпчегеннән ут каба. Әнисе, абыйсы, ә иң аянычы – яшь ярымлык баласы төтенгә тончыгып үлә. Ярый әле ике кечкенә баланы уятып коткарырга өлгерә Камилә. Шул төнне дә «бәйрәм иткән» булалар... Гаиләләре балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе күз уңына эләгә. Социаль яктан начар гаилә дип, исәпкә куялар. Балаларны тартып алу мөмкинлеген дә сиздерәләр. Казан шәһәренең Совет районы администрациясе фатирларын төзекләндерергә булыша. Социаль яклау идарәсе Камиләгә республика күләмендә гамәлгә ашырылган «Аеклык ноктасы» проектында катнашырга тәкъдим итә. «Мин сәрхуш хатын түгел», – дип баш тарта. Озак үгетләгәннән соң ризалаша. Атна саен психологлар белән очрашуга бара. Үзе кебек хатыннар белән таныша. Камилә җөмлә саен психологлар сүзен әйтеп сөйли. Һәр адымына алар карашы буенча бәя бирергә тырыша. Эчми башлаганына бер елдан арткан. Нәкъ бер ел элек аңа махсус укол кадаганнар. Кыйммәтле процедураның бушка ясалганын аңлый ул. Шуңа да өметләрен аклыйсы килә. Аннан соң курка да. «Бер бәйрәмдә шампан шәрабы кабып карадым, башым бик нык авыртты. Үлүдән куркам. Балаларымны кем карар», – ди ул. Элекке тормышы өчен үкенә. Сабые үлемендә абыйсы гаепле дип санаса да, күңелендә үз гаебен таный кебек. Әйтми генә. «Хатын-кызны эчүдән беркем туктата алмый. Ул үзе генә моңа нокта куярга мөмкин. Янәшәдә тиргәүчеләр түгел, ярдәм итүчеләр булса, котылу җиңелрәк», – ди. Программа буенча дәвалау узганда аны беркем шелтәләми, ярдәм итәргә генә торалар. Әлеге программага эләгүенә шатланып бетә алмый. Балаларына чупа-чупс түгел, ә ана назы бүләк итә хәзер. Үсмер кызы һәм ире белән мөнәсәбәтләре яхшыра. Белә: әле ул эчүдән тыелып кына тора. Ул теләк бөтенләй бетсен өчен, бик күп эшләргә, күп вакыт узарга тиеш. Ихтыяр көче генә җитсен.



Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокуклары буенча Республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе Илсөяр ГАРИФУЛЛИНА *«Аеклык ноктасы» проекты социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелгән».*

Аеклык ноктасы

Республикада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән 2015 елдан бирле «Аеклык ноктасы» социаль проекты эшли. Бу проект кысаларында, нигездә, ана булу хокукыннан мәхрүм ителү мәсьәләсе каралган балигъ булмаган балалары булган хатын-кызлар алкоголизмнан дәвалана. Билгеле, мәҗбүри түгел. Әлеге карарны хатын-кыз үзе кабул итәргә тиеш. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокуклары буенча Республика комиссиясенең җаваплы сәркатибе Илсөяр Гарифуллина әйтүенчә, проект гамәлдә булган дүрт ел эчендә 246 кешене җәлеп иткәннәр. Аларның 82 проценты тулы дәвалану курсы узып, программаны тәмамлаган. Бу 472 баланы социаль ятимлектән йолып калганнар дигән сүз. Балалар ана назыннан, гаилә җылысыннан мәхрүм булмый калган, киредән әниләрен «тапкан». Проект пациентлары дәвалану курсларын узып бетергәч тә психиатр-нарколог күзәтүе астында кала. Тулы курс үтүчеләрнең барысында да уңай динамика бар. 2019 елда республиканың 17 районыннан 77 атаана, шул исәптән, ун пар гаилә проектта катнашырга җибәрелә. 58 кеше проектны уңышлы тәмамлый.

«Аеклык ноктасы» проектын гамәлгә ашыруга «Под крылом семьи» Республика иҗтимагый оешмасы да кушылды. Хәмер парыннан айнып, яңа тормыш корырга тырышып яшәгәннәргә ярдәм итә ул. Республика буенча оешманың 13 филиалы булдырылган. «Шул рәвешле 2018–2019 елларда дәвалану курсы узган 36 гаиләгә булышалар», – ди Илсөяр Гарифуллина. Республикада быел да «Аеклык ноктасы» проекты дәвам итәчәк. Моның өчен казнадан ун миллионга якын акча бүлеп бирелгән. Димәк, яңа этапта тагын 80 кеше катнаша алачак. Якынча 150 баланың балачагы Розалиянеке кебек узмас, аның өлешенә төшкән авырлыклар аларны урап үтәр дигән өмет уята. Һәр бала бәхетле булырга тиеш ту бу җиргә. Ә дөньяга күзләре ачылган мәлдә аны бары тик гаиләсе генә бәхетле итә ала, бигрәк тә иң якын кешесе – әнисе...

«БАШКАЧА ЯШИ БЕЛМИМ...»



Эльмира ЗАКИРОВА

Минем өчен ул һәрьяклап кызыклы: балачакта нинди булган, кем булырга хыялланган? Гөлзадә Сафиуллина кызы булу рәхәтме, кыенмы? Шәрык дөньясына, Гарәп илләренә тартылуының сәбәбе нидә? «Мин татарча сөйләшәм!» проектын ничек уйлап тапкан? «Илаһи моң»га кемнәр килә? Студентлары өчен нindирәк укытучы? Кыен чакларда кемнәргә таяна? Резеданың бәхетле хатын-кыз формуласы нинди? Аның өчен хатын-кыз идеалы кем? Һәм башкалар, һәм башкалар...

Резеда Сафиуллина турында галимә, журналист, вуз укытучысы, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, диләр... Резеда диюгә, «Татар яшьләре көннәре» (90 нчы елларда Резеда Сафиуллина аны оештыручы, башлап җибәрүчеләрнең берсе булды!), «Сөембикә варислары», «Илаһи моң» фестивальләре, «Үзебез» татар яшьләре хәрәкәте, «Мин татарча сөйләшәм!» акцияләре, Казан федераль университетында заман таләпләренә җавап бирә алырлык дин әһелләре әзерләү максатыннан мөселман лидерлары мәктәбе «Мәхәллә» проектын оештырып йөрүләре искә төшә. Барысы да аныкы бит! Менә шуларның оеткысы кайчан, ничек салынды икән? Милләткә, халкыңа хезмәт итү аңа каян күчкән? Үземчә җавап та бирәм: татар зыялыларының, татар дөньясының күз уңында, зур шәхесләр даирәсендә үскән кыз булсын да!.. Күпләр аны, әлбәттә, атаклы җырчы Гөлзадә Сафиуллина кызы буларак белә. Әмма Резеда үзе дә яшьтән үк шәхес иде инде! Университетның актив студенты, Яшьләрнең һәм студентларның Кореяда узган Бөтендөнья фестивале делегаты... Татарлыгы шунда да чагыла аның: милли күлмәк, калфак, чулпылардан, чәчен ике толым итеп үреп салып, йөзек кашы кебек балкып йөри!.. «Нечкәбил» бәйгесендә «Иң зирәк нечкәбил» булып таныла... Резеданы төрле ситуациядә, төрле холыкта, төрле сурәттә күргәнем бар.

Әнә, ул Гөлзадә Сафиуллина концертларында җырлый... Әнә, бер айлык Мурадын сумкага салып, Кырымга, «Сөембикә варислары» фестиваленә очып килә. Әнисе уйлап тапкан фестиваль булса да, ул бит анда алыштыргысыз оештыручы! Алтын Урда чорында формалашкан халыкларның мәдәни мирасы шул фестивальдә чагылыш табарга тиеш! Миркасыйм Госманов кебек зур галимнәр белән бергәләп төрки-татар балалар фестивале дигән исемне концептуаль яктан дәлилләде ул! Ялтада балаларны курай тавышы уяту да, малайларның тальян гармунда «Алмагачлары»н уйнап, колгага сөлгеләр бәйләп, Сабантуйга бүләк җыеп йөрүләре дә, кечкe уенда такмак әйтешле, йөзек салышлы уйнаулар да – барысы да башта Резеда хыялында бөреләнде. Татарстан, Башкортстан, Казакъстан, Әстерхан, Себер, Кырым татарлары балалары өчен нинди зур җыен булды – Ялта ике атна буе татарча җырлап торды!

Әнә, балалары Аммар, Ширин, Мурадны ияртеп, Кырым белән хозурланып йөри: өстә – таулар, аста – диңгез... Яулыклы Резеда менә бу юлы спорт киемнәреннән. Рульдә барганда ни булмас: машина көпчәкләрен алыштыра алмасаң, йөгереп барып автобуска утыруың да бар. Кайнар, хисле, үз фикерен өздереп әйтер, бәхәсләрдә баш бирмәс, бөтерчек кебек тиктормас, бертуктаусыз яңа эшләр уйлап табар һәм шуларны тормышка да ашырырга керешер. Әле институтта, әле университетта, әле Фәннәр академиясендә ул... Үзен аңлый торган җитәкчеләр – затлы-зыялы шәхесләр кул астында эшләү ошый аңа!

Әнә, интерактив формада студентларына дәресләр үткәрә. Сораулар биреп, көлдереп, мисаллар китереп... Россия Ислам университетында мөселман мәгарифе тарихы музее аның инициативасы белән Каюм Насыйри музее директоры Рушания Шәфигуллина кебек милләтпәрвәрләр ярдәмендә оештырылган иде инде. Хәзер шуның альбом-каталогын әзерләп йөриләр. «Татарларда ислам дине» тәгълиматы дигән дистанцион курсының лекцияләрен видеога яздыра. Күптән түгел «Татар телле мөселман журналистикасы тарихы» дигән китабы дөнья күрде. Хәзер менә тагын бер дәреслек әзерләп ята. «Илаһи моң»га мөнәҗәт, дастан, зекер, мәүлет башкаручылар, татар мәкаме белән Коръән укучылар, «Кыйссаи Йосыф»ларны, «Сак-Сок» бәетләрен башкаручылар җыела дип канатланып йөри. Күп кешеләр белән эшләгәч, дипломат та, сизгер психолог та булырга туры килә. Менә шундый ул Резеда... Үзен «кризисный менеджер» дип атый. Нәрсәдер барып чыкмый, яна, ситуацияне коткарырга кирәк икән – тиз-тиз карарлар кабул итүче зирәк Резеда...

Ә Резеда, әнә, һәр гамәленнән, һәр башлаган эшеннән, холкыннан, хыялларыннан, уңышларыннан, югалту-табышларыннан һаман да шул сүз башындагы «оеткы»ны эзли. Ул әле көлеп, әле моңсуланып-сагышланып, әле тирән фәлсәфәгә чумып сөйли...

Әни, балачак, хыяллар...

Минем әни – көчле, балкып торган шәхес ул! Үзе матур, үзе булган! Ветеринария институтын тәмамлагач, казакъ далаларында практика үткән, Үзбәкстанда кошчылык фабрикасында врач булып эшләгән... Белмәгән эше юк: ир-ат эшенә дә, хатын-кызныкына да батыраеп тотына... Әни минем өчен гомергә идеал булды! Аны кечкенәдән сагынып яшәдем. Минем өчен иң бәхетле чак – әни янында булу. Хәтта сочинениеләрне «Минем кумир – әни!» дип яза идем. Андый кеше баласы булгач, планка да югары. Мин аңа лаек булырга тиеш! Шул лаек булу төшенчәсе гомер буе озата мине. Миңа кечкенәдән салынган ул программа. Оеткысы шулдыр, бәлки... Минем амбицияләр хәттин ашкан иде! Үземне йолдыз сыман хис итеп үстем, ләкин масаймадым. Һаман шул «Мин лаекмы?» дигән сорау үзен гел сиздереп торды.

6 яшьтән «китап корты»на әйләндем. Кая гына гастрольләргә барсак та, чемодан төяп китап алып кайтабыз. Дөнья классикасы, рус әдәбияты, заманча әдәбият, шәрык классикасы, шигърият... Мәктәпкә 10 яшьтә генә бардым. Аңынчы әни белән гел гастрольләрдә йөрдем. Мәктәптә язучыларның биографияләрен укыганда, кайчан да булса минем биографиямне дә өйрәнерләр – язучы булам дип хыялландым. Концертларда 6 яшемнән татар, үзбәк, һинд, чегән биюләрен шәп биегәч, балерина буласым килә башлады. Пермь хореография училищесында мине халык биюләре бүлегенә генә аласыларын белгәч, күз яшьләре белән еладым. Мин бит болай да биим! Зур-зур сәхнәләрдә! Уфадагы музыка буенча интернат-мәктәпкә имтиханнар тапшырып, шунда укый башладым. Тәрбиячем Сәвия Исламовна Усманова таныштырганда: «Әти-әнисе – артистлар. Куйбышев филармониясендә эшлиләр», – диде. Әни кебек булды ул минем өчен. Хатларымны саклый, хәзер дә тормышым белән кызыксынып тора.

Бөтен Советлар Союзы буенча гастрольләрдә йөрдек. Куйбышев филармониясендә бердәнбер татар группасы иде ул. Мин әниләр белән шулай кайнап яшәргә, авырлыкларны җиңәргә өйрәнгән – башкача яши дә белмим. Оеткысы шул инде аның... Әти – Риф Сафиуллин – үз әтием түгел. Минем әти Әбүбәкерев Хаҗинур булган. Ләкин мин кечкенә чакта ук әни белән аерылышканнар... Бакыйлыкка күчкәненә дә шактый вакыт. Хәзер аның икенче хатыныннан туган кызлары белән аралашабыз... Ә Риф абыйны мин гомер буе үз әтием итеп яраттым. Фамилиям дә, отчествам дә – аныкы! Мине үз баласы итеп кабул итте ул! Уфада укырга калдырып саубуллашканда, аның: «Кызым, туган телеңне сакла, онытма», – дип әйткән сүзләре әле дә күңелемдә яңгырап тора. Искиткеч баритон тавышлы! Инглизчә, итальянча җырлый, консерватория тәмамлаган, опералардa җырлаган, җиде кыллы гитарада уйный... Кулыннан килмәгән эш юк. Без бөтенләй башка дөньяда яшәдек.
Миңа 10 яшь булганда инфаркттан үлеп китте.

Мин даһилар белән аралашып үстем. Әти үлгәч, әни нишләргә белмәде. Кире ветеринариягә кайтырга җыенган чаклары да булды. Без Куйбышевта (Самарада) яшә-


Фото: Анна Арахамия

PRESSA

гәндә гастрольләр белән Илһам Шакиров килде. Әни концертка баргач, Илһам абый янына килеп: «Мин Риф Сафиуллинның хатыны, аны беләсезме?» – дип сорый. «Белмичә! Кая гына гастрольгә барсак та, әле генә Сафиуллин булып китте, дип каршылыйлар иде», – ди Илһам абый. Ул көнне концерттан соң Хәмдүнә апа белән Илһам абый без яшәгән баракка кунакка килделәр, сөйләшеп утырдылар. Илһам абый әнине үз бригадасына алды. Мин Илһам абый белән бер төркемдә йөрдем! Көн дә һәр концертны башыннан ахырынача карап утырам. «Һәм әйтте Чулпан...» дип җырлаганда, Илһам абыйның кул хәрәкәтләрен, башын ничек боруларын, һәрбер интонациясен яттан беләм. Һәм һич туймыйм бит шуннан! Мин шул дөньяда йөзә-ә-әм! Мондый бәхет кемгә эләккән әле ул! Аннары Әлфия апа белән йөрдек әле. Аның күңел киңлеге, кешелеклелеге... Легендалар сөйләрлек! Ә Хәмдүнә апа?! Мине күрсә: «Әй, бу бит безнең «дочь полка» – гастрольләрдәге балабыз!» – дип кочаклап алыр иде!.. Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт гаилә дусларыбыз иде. Фәнис Яруллин, Мөхәммәт Мәһдиевләр белән аралашып яшәргә туры килде. Менә шушы оеткы түгелмени?!

Төне дә, көне дә – мин генә...

Миндә кечкенәдән идеаль бер калып формалашты. Әни әтине бик ярата иде. Аларның олы мәхәббәтен күреп үстем. Минем тормыш та шундый булыр дип хыялландым. Ирем миннән күп яшькә олы булачак. Хәрбиләрне яратмыйм. Ул татар кешесе булачак, әлбәттә! Һәм... менә сиңа мә! Тормышта нәкъ киресе булды! Университетта укыганда бик актив идем. «Каз канаты» бию ансамбленә йөрим, интернациональ дуслык клубына чакырдылар. Шунда оештырылган бер чарада Төньяк Йәмәннән килгән бер егет миңа күз салды. Казанда хәрби училищеда укый икән. Намаз укый бу! «Әлхәмдүлилләһ» дип сөйләшә, «иншаллаһ» дип куя. Әни эреп китте гел. Мин дә йомшардым инде.

«Бу сезгә бәхет китерер». Әнә шулай дип, Яңа ел каршыларга Коръән китабы күтәреп килде ул. Без моңа әүлия итеп карыйбыз. Өстәлдә – шампан шәрабы. «Юк-юк, әчмим, минем беркайчан да эчкәнем юк», – ди. Тагын намаз укый, әнисе турында сөйли. Үзе шундый тәртипле. Безгә ул башка дөньядан килгән кебек тоела башлый. Беренче килүендә үк әнигә: «Сезнең кызыгызга өйләнергә телим», – диген. Башкача кыз өенә килмиләр икән аларда. Шулкадәр игътибар, ярату, кайгырту белән урап алды ул мине... Тормышында төнен дә, көнен дә мин генә! Ә мин менә шуңа мохтаҗ булганмын! Ул туган иленә кайтып, әнисенең ризалыгын алды. Якын туганнарны чакырып, көзен никах укыттык. Телевидениедә эшләгәндә никахлы идем, аны күпләр белмәде дә. Бу да дөрес булмаган. Никахны бөтен кеше белергә тиеш аны. Никахның бөтен мәгънәсе: без – ир белән хатын дип игълан итү, җәмәгатьчелеккә җиткерү. Улыбыз Аммар туды. Кызыбыз Ширинне Йәмәндә яшәгәндә таптым.

Бу язмыш сынавы булган. Үткән, үзгәртеп булмый торган гомер. Яшьлек ялгышлары. Чит ил кешесенә кияүгә чыгарга теләгән яшь кызларга мин ялгышмаска киңәш итәр идем. Бу сынауны үтү бер дә җиңел түгел.



Еракка китеп карап...

Балаларым белән гел татарча гына сөйләшәм. «Әлифба», татарча шигырь китаплары төяп килдем Йәмәнгә. Ник татарча сөйләшәсең, монда беркем аңламый бит, диючеләргә җавабым әзер: «Мин өйрәтмәсәм, кем өйрәтсен?! Мин бит аларның әнисе!» – дип әйтә идем. Казанга кайтканда, алар татарча сөйләшә иде инде. Минем өчен бик мөһим иде ул байлыкны балаларга бирү! Тел, тамырлар, үзеңнең кем икәнеңне белү... Бабамның белмәгән эше юк иде. Ул доктор да – сынган сөякләрне ялгый хәтта! Ул чана ясый, йорт сала, беренчеләрдән булып алмагачлар утырта... Менә болар бөтенесе – оеткы, байлык. Шул тамырларымнан әз генә өзелә башласам, бетте – мин үләм, миндә депрессия!

Студентларыма кыйблаларын табарга ярдәм итүне вәкаләтем дип саныйм. Хәтта бу миссияне агрессив үтим кебек. «Ни өчен монда укыйсыз? Кем булырга телисез? Әти-әниегезне тыңлап кына, диплом булсынга гына йөрмисезме? Теологиянең сезнеке түгел икәнен сизәсез икән, башкасын эзләгез!» – дип кабатлап торам. Киләчәктәге урыныңны билгеләр өчен, хәзерге урыныңны аңларга кирәк. Хәзергесен аңлар өчен, каян килгәнеңне белергә кирәк. Әти-әниең, әби-бабаң кем? Кайсыгыз җиде буынын белә? Ничек инде кайсы төбәктән чыкканыңны белмәскә мөмкин?! Ул бит сезнең гаиләдәге традицияләрдә, ризыкларда, сөйләшү манерасында чагыла. Әти-әниегез кавышып, ике дөньяны, ике байлыкны кушканнар. Ул рухи да, психологик та байлык. Күзгә күренми торган эчке дөнья бу. Студентларым рәхмәт әйтә.

Шәхси тормышым гарәп дөньясы белән бәйле булу очраклы түгелдер... Әбием белән бабам да, әнием дә кечкенәдән догалар өйрәтте. Әти үлгәч, беренче тапкыр дини тәгълиматка якын килдем. Әбиләр, җыелып, Коръән укыганны хәтерлим. Нәрсә укыйлар соң алар дип аптырый идем. Бакый Халидовның рус телендә басылган гарәп теле дәреслеген таптым өйдә. Шуннан гарәп хәрефләрен үзлегемнән өйрәнеп, әбиемә хатлар яза башладым. Университетның журналистика бүлегендә укыганда Лена апа Кәлимуллинага гарәп теле дәресләренә йөри башладым. Аспирантурага кергәндә фәнни җитәкчем Әбрар Кәримуллинга ислам дөньясына, гарәп мәдәниятенә тартылуымны әйттем. Шулай итеп, «Татарларда гарәп телендә булган басма китаплар тарихын өйрәнү» темасына чумдым. Кандидатлык диссертациямне дөньякүләм

танылган гарәп кульъязмалары тарихы белгече Әнәс Бакый улы Халидовның фәнни җитәкчелегендә тәмамларга насыйп булды. Бала чагымда кулланган беренче гарәп теле дәреслеге авторы Бакый Халидовның улы ул – менә бит язмыш! Гарәп илләрендә яшәргә дә насыйп булгач, ул дөньяны тирәннән күрдем. Аларда гаилә ныклыгы, ерак туганнарны да белү, нәсел-нәсәпне тану көчле. Аммар улым шул элемтәне аеруча нык тоя...

Туган җирнең кадерен белер өчен еракка китеп кара икән шул. Мин авылда да, Чиләбедә әтинең – Риф Сафиуллинның әнисендә дә, Уфада да яшәдем. Гастрольләр белән читтә күп йөрдек. Казан безнең өчен һәрвакыт кыйбла булды. Зур авырлыклар белән, икешәр алмашу ясап, Куйбышевтан Казанга күчүләребез... Әни Киров районыннан «хрущевка»дан кечкенә генә бер фатир тапты. Иң бәхетле чагыбыз булгандыр ул көннәр! Гарәбстанда яшәгәндә дә төшләремә керә иде Казан! Анда бит чүл дә чүл, кара да соры... Сагынуга түзәлмичә кире кайттым. Ә хәзер җаным авылга тарта. Шекәдә туганнар тырышлыгы белән әби-бабай нигезендә яңа йорт салынды. Җәй чыгу белән рәхәтләнеп шунда кайтам.

Милләт язмышы

Милләт турында фикер йөртү каян барлыкка килә? Шул милләтнең вәкилләренә карап. Татарның нинди милләт икәнен үз мисалыбызда күрсәтәбез. Шуңа күрә кая барсам да, җаваплылык сизәм. Кем икәнеңне белү, тамырларыңны белү – бу минем тема.

Алга таба нишләргә? Татар телен, татар мәдәниятен нинди язмыш көтә? Берчак Хәтер көнендә шул сорауларга җавап эзләп йөрдем. Нинди азатлык даулыйлар, кемнән даулыйлар соң болар, дим. Кем комачаулый сезгә татар булырга, балаларыгыз, оныкларыгыз белән авыз тутырып татарча сөйләшергә? Шул ук татар язучылары, галимнәр, артистлар балалары белән русча сөйләшә. Татар классик язучыларының оныклары туган телне белми! Әти-әниләр балаларын татар мәктәпләренә бирергә теләми. Татар теле укытучылары балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияли алмый. Минем балалар татар балалар бакчасында русчага өйрәнделәр. Татарстан кысаларында күпмедер китап чыгарып, газета-журналлар бастырып кына, татар театрыбыз бар дип тынычланып, биеп-җырлап, кәләпүш, өчпочмак... Нәрсә, шул гынамы инде татарлык? Татар теленең куллану даирәсен киңәйтер өчен нәрсәдер үзгәртергә кирәк! Үзебездән башларга! «Үзебез» хәрәкәтен әнә шулай башлап җибәрдек.

«Мин татарча сөйләшәм!» Телгә кызыксыну уяту теләгеннән шундый бер акция уйлап таптык. Тукаебызның туган көнендә, Бауман урамында елына бер тапкыр бәйрәм үткәрергә. Заманча татар музыкасы яңгырап торсын. «Мин татарча сөйләшәм» дигән язулы футболка кигән яшьләр халык белән туган телдә аралашсын. Татарча сөйләшә белгән кешеләргә күкрәк тамгасы тапшырабыз. Ә инде сөйләшә белмәгәннәренә «Минем беренче татарча 100 сүзем» дигән сүзлек бүләк итәбез. Ул сүзлекне төне буе улым Аммар әзерләгән иде. Иң кулланылышта булган татар сүзләрен, сүзтезмәләрен җыеп утырды, 100 генә түгел, 150 сүз тупланды анда. Кайсы дәүләт оешмалары, иҗтимагый оешмалар татарча хезмәт күрсәтә, игъланнары бар, татарча мәгълүмат урнаштыра – шуларга дипломнар бирәбез, ә кемнәрдә бөтенләй юк – «плохо с татарским языком» дигән антирейтинг булдырдык. Ел саен дәвам итә бу акция.

Мин бәхетле булачакмын!

Әни кеше булу – минем өчен беренче урында. Минем өчен иң мөһиме – балаларымның бәхетле булуы. Кызым Ширин Америкада, Вашингтонда музыка белән дәвалау буенча укып, шушы көннәрдә соңгы имтиханнарын тапшырды. Берничә урынга эшкә чакыралар үзен. Татарстанга кайтып, милләткә, халкыбызга хезмәт итәр дип бик өметләнәбез инде. Олы улым Аммар өйләнде, оныгым үсә. Яшь ярым инде аңа. Ул Аммарның миңа, хатынына, дәү әнисенә, сеңлесенә, энесенә булган ихтирамы, ярдәмчеллеге!.. Кече улым Мурад 11 нче класста укый, рэп җырлар яза... Минем балаларым – искиткеч!

Булдыра алмыйм дигән сүз юк ул бездә! Әни кечкенәдән шулай тәрбияләде. Бер әйбер искә төшә. Паркта җирән клоун кешеләрнең күңелен күреп, шамакайланып йөри икән. Кемгә күңелсез, шул клоунга бара, ди. Ә бу дөньяда иң бәхетсезе – клоун икәнен берәү дә белми, ди. Юбилейлар, туйлар үткәргәндә, гел шуны искә төшерә идем. Аерылышканнан соң ялгыз калган чагым, балалар кечкенә, хәлем юк... Ә миндә бит установка – сер бирмәскә! Бүген ул авырлыклар артта калып, яраткан ир хатыны булсам да, вакыт-вакыт элекке гадәт буенча һаман көчле булып маташам.

Башта намаз, әлбәттә. Ирем Әнвәр белән бергә укыйбыз. Аннары шулай ук бергә йога, сулыш практикасы, медитация... Минем өчен бик мөһим әнә шулай иртән хәрәкәтләнеп алу. Болар һәммәсе чиста, нечкә көч бирә.

Хатын-кыз идеалымы? О-о! Шәхсән минем өчен әни идеал иде. Хатын-кыз идеалы ул – йомшак, сабыр, сыгылмалы булу, күп очракта сүзсез кала белү, шулай да үз дәрәҗәңне белү... Балаларымның атасы белән аерылганга алар алдында үземне гел гаепле сизә идем. Ә улым: «Әни, ир кешедән дә күп нәрсә тора», – диде. Һәм менә ул үзе аңлаганча гаилә корды. Аларга шатланып туя алмыйм. Менә мин киленем Әдинәне шундый хатын-кыз идеалы итеп күрәм. Анда шундый потенциал бар!

Бәхетле хатын-кыз формуласы – үзеңне ярату, үзеңне кайгыртып яшәү ул. Психологлар тренингларда шундый күнегүләр тәкъдим итәләр. Иртә белән уянгач, башта көзгегә, көзгедә чагылган күзләреңә карыйсың да: «Мин сине шундый яратам!» – дисең. Хатын-кызларның күбесенә тәкъдим итәр идем. Миңа, мәсәлән, бик булыша. «Син бәхетле булачаксың!» – дип, үзеңә гарантия бирәсең. Күз яшьләре ага башлый. Әллә нинди халәт бу! Чөнки без үзебезне яратырга өйрәнмәгән. Үзебезгә шундый мөнәсәбәт булдыра белмибез икән, ничек аны якыннарыбызда, балаларыбызда булдыра алыйк ди! Үзеңнән башларга кирәк! Хәзерге тормышым – бөтен, түгәрәк, Аллага шөкер. Янәшәмдә ышанычлы таяныр кешем бар! Шул буладыр инде ул бәхет!

Тулысынча укыгыз »



PRESSA

ДАРУГА ҮРЕЛГӘНЧЕ...



Фото: www.pixabay.com



Раилә ХӘЯЛИЕВА

Сыйфатсыз кытай уенчыклары, трансген майлар, илдәге кризис, гаделсез законнар... Дөньяда балаларга куркыныч яный торган сәбәпләр бигрәк күп сыман кайчак. Ә менә якын кешеләренең гамәлләреннән дә балага куркыныч янарга мөмкинлеге хакында уйлап караганыгыз бармы?!

Психосоматика төшенчәсе колакка яңа керә башласа да, ул инде XIX гасырда ук барлыкка килә. Психосоматика – җан һәм тән берлеген аңлата. Ягъни психологиянең, хисләрнең, эмоцияләрнең тән авыруларына тәэсирен өйрәнә торган юнәлеш дип аңларга кирәк аны. Ә безнең тормышка ни катнашы бар аның диярсез. Хәзер барысын да тәртип белән аңлатырга тырышам. Ә сез яңа технологияләр, дарулар, витаминнар хакында, кәттә уку йортларын тәмамлаган супер белгечләр яшәгән заманда поликлиникалардагы чиратлар, бернинди дәвага да бирешми торган бетмәс-төкәнмәс балалар авыруларының каян килеп чыгарга мөмкин икәне турында уйлый торыгыз әле.

Күпьеллык экспериментлар, күзәтүләрдән соң, нейропсихологлар баланың психологик халәте туганнан алып үсеп җиткәнчегә кадәр әнисенеке белән тәңгәл булуын ачыклаган. Йөрәк тибеше, күз алмасының киңәю-тараюы, тавыш тембрына кадәр бездән балага күчә икән! Кечкенә баланың яшәү инстинкты – ашау-эчү, йокы, җылылык, дәвалану – барысы да янындагы олы кешегә бәйле. Табигатьтән салынган механизм шундый: баланың эчке кичерешләре әни кешенең гормональ процесслары белән бәйле. Биләүдәге сабый үсә төшкәч, тәпи киткәч, сөйләшә, мөстәкыйль гамәлләр кыла башлагач та әни кешегә бәйле булуын дәвам итә икән әле. Менә шуны аңлап, баланы нинди хисләргә «төреп» үстерү турында әни кеше ешрак уйлансын иде, дип чаң кага психологлар.

Белгечләр әйтүенчә, бүгенге көндә 40% (күбрәк саннар күрсәтүчеләр дә бар) авыру психосоматик характерга ия. Олыларның бер яраткан сүзе бар: «Барлык авырулар да нервлардан!» Моның шулай икәнен табиблар да раслый. Дөньяны эмоцияләр аша кабул иткән балалар олы кешегә караганда, психосоматик авыруларга ешрак бирешә торган була. Чөнки аларга үзләренең борчулары, көндәлек стресслар белән көрәшү бик авыр бирелә.

Кайвакыт яңа туган балада да психосоматик авырулар очрый икән. Яшь әнинең бала көткән вакыттагы

эмоцияләренә, әти кеше белән мөнәсәбәтенә бәйле күренеш бу.

Бу урында тормыштан бер мисал язып үтим әле. Әминә исемле танышымның кечкенәдән бөерләре авырта иде. Бала чагында әнисе төрле санаторийларга, минераль су чыганакларына йөрткән аны. Мәктәп чорында да бөерләренә еш салкын тиеп аптыраган. Табиблар әллә ни куркыныч симптомнар күрмәсә дә, гел бөерләре авыртудан зарланды ул. Психология белән кызыксынып, авыруын төптән өйрәнә башлагач кына сәбәбенә төшенде. Әнисе Әминә белән җиде айлык көмәнле вакытта әтисе, каты тавышланып, әнисенә кул күтәргән булган икән. Курку хисе, гадәттә, бөерләргә утырып кала, дип аңлатканнар аңа. Әминәне җәфалаган авыру, карында чагында ук салынганлыгы ачыкланды. Хәзер инде ул психологик алымнар белән бу проблемадан арынырга тырыша.

Бала белән әни һәрвакыт бербөтен. Биләүдәге бала иң элек безнең белән тәне аша аралаша. Тәндәге кызарулар, температура күтәрелү, ашаганын кире чыгару, артык еш көйсезләнү... Димәк, бала белән бар да җайлы түгел, шул рәвешле ул безне кисәтергә тели. Хәтта теле ачылган балага да үз хисләре турында сөйләү, ниләр кичергәнен ачык итеп аңлату катлаулы бирелә. Һәм аның сәламәтлеге какшый башлый. Табибтан табибка йөреп, алмаган дару, үлән төнәтмәсе калмый. Таныш-белешләр биргән киңәшләр, интернеттагы чатлар, Комаровский... Кайларга барып бәрелергә белмәгән чаклар була. Бала исән генә булсын!

Менә бу мисалны мәктәптә эшләүче психолог ханым сөйләгән иде. 9 яшьлек Илнур аллергик дерматит белән җәфалана. Интеллигент, укымышлы әнисе улын идеаль бала итеп тәрбияләргә тырыша. Көндәлек режимны төгәл үтәвен таләп итә. Улының тәне кызара башлагач та, табиблар киңәшеннән чыкмый, малайның көндәлек режимы тагын да кырысланa. Ә Илнурның хәле авырая гына бара. Әмма ханым эмоцияләр дигән әйберне бөтенләй танырга теләми, «малайлар хисчән булмый!» дип кенә җавап бирә. Илнурны әнисенең кырыслыгы, план буенча гына яшәү ардырган, ул әни назына, аның җылы кочагына мохтаҗ. Ләкин бу турыда әнисенә әйтергә курка. Малайның әнисе белән мөнәсәбәте аның тән авыруында чагыла. Әни җылысы белән тулы кайгыртуга мохтаҗ ул.

Хәл ителмәгән, «эчкә йотылган» психологик проблемалар тән авыртулары аша үзен белгертергә сәләтле.

Җитди сәбәпләре дә күренмәгән, әмма дәвалап-дәвалап та узмаган авыруларга, гадәттә, психосоматик симптом хас була, авыру аша бала организмы ярдәм сорый, ди психологлар.

Балаларда психосоматик сәбәп аркасында килеп чыккан авырулар: еш салкын тию, герпес, эч авырту, аллергия, тире авырулары, ангина, аденоид, ринит, бронхит, анемия, баш авырту, калкансыман биз, йокы бозылу, конъюнктивит, тотлыгу...

Гадәти күренеш бит: мәктәп балаларының күбесе күкрәк тирәсе авыртудан зарлана. Кардиологик үзгәрешләр дә сизелми, ә авырту бар. Мондый очраклар уку процессындагы стресс белән бәйле, дип аңлата психосоматика белән шөгыльләнүчеләр. Укучы бала укытучылардан курка, начар билге өчен борчыла. Бу хисләр оялу һәм йөрәк турысындагы авырту буларак тышкы якка чыга икән.

Әниләргә таныш хәлдер инде, контроль эш яки сәхнәдәге чыгышы алдыннан кайбер баланың эче авырта башлый. Көчле стресс кичергәндә эчәклекләрдә тоз кислотасының артык күп бүленеп чыгуы ачыкланган.

Тискәре эмоцияләр һәрвакыт тышка чыгарга тиеш, диләр. Әмма безгә башкача тәрбия бирделәр, тыйнаклык, сабырлык хакында кисәтә килделәр. Тик эчтәге негатив яшергәннән генә юкка чыкмый. Травма ясый торган, тискәре эмоцияләргә китерә торган ситуацияләр еш кабатланганда, ул хисләр (үзебездә дә, балада да) җыелып бара һәм вакыты җиткәч, физик авырту булып тышка чыга.

Балада еш очрый торган психосоматик күренешләр

Гаиләдәге катлаулы мөнәсәбәтләр, әти-әнисенең еш сүзгә килүе. Мондый очракта бала үзенә «коткаручы» ролен алырга тырышачак. Мин авырсам, әти белән әни дуслашачак, һәм без бергә булачакбыз дигән программа кабына анарда. Чыннан да, бала авырганда әти белән әни бер булып кайгырта башлый, аңлашылмаучанлыклар онытылып тора. Бала терелгәч, гаиләдәге каршылыклар кабат башлана. Һәм балага янәдән «авырып китәргә» туры килә. Әти-әни конфликты аркасында килеп чыккан авыруларның күбесе сулыш юллары (ангина, отит, ринит) белән бәйле дип күрсәтә белгечләр.

Эмоциональ тетрәнүләр (әти-әнинең аерылышуы, якын кешеңне, яраткан йорт хайванын югалту). Балага кайгы хисе белән көрәшү бик авыр. Еш кына ул эчтән үзен гаепле саный башлый. Бу хис тышкы яктан тыныч булып күренгән баланы эчтән кимереп яшәргә, ахырдан ниндидер авыру булып килеп чыгарга мөмкин.

Әнинең тагын бер бәби алып кайтуы. Еш кына беренче бала сеңелкәш яки энекәш алып кайтуга бөтенләй әзер булмый. Ул кинәт кенә «зур үсеп» куя, әнинең бәбигә күбрәк кирәклеге ачыклана һәм иң куркынычы: элек аныкы гына булган бүлмә, уенчыклар, наз белән бүлешергә туры килә бит әле! Баланы үпкә, читкә этәрелү, кирәксезлек тойгысы биләп ала. Һәм әнине үзе янында тотып тора торган авырулар баш калкыта...

Әни белән мөнәсәбәт. Игътибар җитмәү генә түгел, кайвакыт гиперопека да комачаулый балага. Һәр адымын контрольдә тотарга тырышканда, артык күп игътибар биргәндә баланың «сулышы кысыла» башлый, һәм сулыш органнары белән бәйле авыруларның еш кабатлануы белән җавап бирә бала.

Һәр авыруның психологик сәбәбе бар, иң беренче шуннан арынырга кирәк.

Балалар бакчасына, мәктәпкә ияләшү чоры. Яңа коллективка, мохиткә кереп китү дә балага авырлык тудырырга һәм иммунитетның көчсезләнүенә китерергә мөмкин.

Эмоцияләрне «басып тору». Балага хисләрен белгертергә ирек куймау, аларны төрле стереотиплар аша тәрбияләргә тырышуның («Тәртипле кызлар үзләрен алай тотмый», «малайлар еламый!», «башка балалар алай эшләми») нерв системасы белән бәйле авырулар китереп чыгара.

Әлбәттә, барлык авырулар да психосоматикадан гына килеп чыга дип уйларга ярамый. Һәр авыруның сәбәбен аңлар өчен, беренче чиратта, табиб күзәтүе астында булырга, медицина тикшеренүе узарга кирәк. Бу таләпләрне беркем дә читкә какмый. Җитди тайпылышлар сизелмәсә, дарулар ярдәм итмәсә, авыру симптомнары еш кабатланса, инде әти-әниләргә бала белән бәйле психологик сәбәпләр турында да уйланырга кирәк, димәк.

Ярар, авыруның психосоматика белән бәйле икәнен аңладык ди. Инде нишләргә?

Бу сорауга балалар һәм әти-әниләр белән эшләүче психолог Галия ГЫЙМАДИЕВА җавап бирә:

– Баланың гадәтләрен игътибар белән күзәтегез, тормышыгызны анализлап карагыз. Чир балага ничек ярдәм итә, «авыру» аның өчен ник файдалы булуын ачыкларга тырышыгыз (авырыйм, димәк, мәктәпкә, бакчага бармыйм, авырыйм – миңа игътибар күп булачак, контроль эш алдыннан эч авырта, укышта һәм башкалар). Үзегезнең гамәлләр турында уйланыгыз. Авырып китүе белән бала сезгә ни әйтергә тели икән? (Наз җитми, сезне югалтудан, үз яныннан җибәрүдән курка, үзенә игътибар сорый...) Әлбәттә, барлык сәбәпләр турында да сөйләп бетереп булмый. Һәр балада психосоматик симптомнар төрлечә уза. Әмма кризис чорын (1–3, 13–17 яшь) кичергән балаларга ул ешрак кагыла. Кайвакыт гаиләдәге тәртипләрне, фикерләү рәвешен үзгәрткәндә, даруларга бирешмәгән авырулар уза, бала савыга – мондый очраклар да аз түгел.

Хроник авырулар булганда дарулар белән дәваланудан тыш, параллель рәвештә психолог яки психотерапевт белән эшләргә киңәш итәр идем. Психологик моментларны алып ташламыйча, авыруның сәбәпләре бетмәячәк. Әлбәттә, барлык авыруларны да психосоматика белән бәйләп карарга ярамый, төрлесе бар. Кайвакыт кире очраклар да була. Авыру симптомнары психологик халәт белән бәйле булганын аңлагач, үзе узар әле дип, әниләр артык игътибар итми башлый. Әмма тәндәге киеренкелектән арынмыйча, уңай үзгәрешләр булуы икеле. Яхшы белгеч табып, балаларга ярдәм итәргә тырышыгыз!

Ләйсән исемле яшь әни үзенең тәҗрибәсе белән бүлешә: «Узган кыш көтмәгәндә улыбыз Булат авырып китте. Кинәт кенә температурасы күтәрелде, буыла башлады. Ашыгыч ярдәм чакырттык. Улыбызны хастаханәгә китереп, ике сәгать узды микән, ул комага китте... Шул мизгелдә минем ниләр кичергәнемне белсәгез икән! Яшәү кадере, якыннарымның исәнлеге һәм бер минутта барысының да өзелүе, юкка чыгарга мөмкин икәнлеген аңладым реанимация ишеге төбендә утырганда. Тормышка булган дәгъвалар, канәгатьсезлекләр аркасында, яныбыздагы бәхетле мизгелләрдән мәхрүм калып йөрибез икән... Аллага шөкер, улым иртән күзен ачты. Табиблар куркыныч диагноз куйсалар да, ике атнадан чыгардылар безне. Хәзер барысы да әйбәт, шөкер. Ике ай элек, психосоматика белән шөгыльләнүче бер блогерның туры эфирын тыңлаганда узган кышта улым белән булган хәлнең асылын аңладым. Ул вакытта бит минем бар дөньядан канәгатьсез булып, сулыйсым да, яшисем дә килми торган чагым иде. Минем халәт улымда чагылган булса кирәк...»

Тагын бер мисал: Декрет ялыннан соң иҗади күңелле Римма документлар белән эшли торган офиска урнаша. «Иҗат кешесенә коры фактлар белән эшләү җан газабы икән. Бертуктаусыз саннар, исем-фамилиясе генә үзгәргән стандарт хатлар язу... Ә күңелнең иҗат итәсе килә. Кая анда утырып нидер язарга, үземне карарга да вакыт юк. Беренчедән эш күп; икенчедән, эшкә кереп ике ай вакыт та узмады, кызым авырып йөдәтә башлады. Әле аллергия, әле тамагы, өченчесендә бронхит куйдылар. Эшемә ияләшә алмыйча бәргәләнгән саен, балам ешрак авырый кебек тоелды. Югыйсә дәү әнисе белән өйдә утыра бит инде, бакчага да бирмәдек. Ярты елдан эштән китәргә туры килде. Кызымның авырулары да узды. Гаҗәп бит, әйеме? Әни кешенең күңелендә гармония булмау да балада чагыла икән. Хәтта эш мәсьәләсендә булса да! Баламны балалар бакчасына урнаштырып, редакциягә эшкә чыктым. Мин дә бәхетле, кызымның да әлегә авырганы юк, тфү-тфү!»

Күптән түгел кулыма Валерий Синельников китабы килеп керде. «Бала сәламәтләнсен өчен, дару төймәләренә үрелгәнче әти-әнигә тормышка карашларын үзгәртү дә җитә кайчак». «Баланың авыруы – «үзгәрегез!» дигән чаң ул. Әмма әниләр бу турыда уйланмыйча, даруханәгә йөгерә» дигән фикерләрен озаклап уйлап йөргән идем.

Психология белән бик озак еллар шөгыльләнгән Луиза Хей һәм Лиз Бурбо авырулар һәм аларның психосоматик сәбәпләре язылган таблицалар булдырган. Аларны интернеттан табып карарга да була. Ә иң мөһиме: белгечләрнең бала сәламәтлегенә карата уртак фикере шундый – бала сәламәтлеге әти-әнинең принциплары, үз-үзләрен тотышы, ялган тормыш законнары һәм балага карата наз, мәхәббәт һәм агрессиягә бәйле.

Ә сезнең балагызның хәлләре ничек? Авырмыйсызмы?

НИЧЕК БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА?



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

Һәртөрле очрашулар вакытында миңа төрле сораулар яудыралар, мин җавап тапкан булам, ә ахырда җыелган халыкка үзем дә берәр сорау бирәм. Бервакыт юри генә: «Нәрсә ул бәхет?» – дип сорадым. Иң алда утырган сиксән яшьләрдәге әби иңнәрен генә сикертеп куйды. Шушы яшькә җитеп тә бәхетнең ни икәнен белмәгәч, әйбәт тә түгел бит инде... Башкалар да рәтле җавап таба алмады. Берничә очрашуда шушы хәл кабатланганнан соң, шуны ачыкладым – бу сорауга җавапны үзем дә белмим икән бит.

Без бәхет дигән төшенчәгә әллә никадәр фәлсәфи төсмерләр бирәбез. Аны барлык теләкләрнең берьюлы кабул булуы, бөтен уңышларның, бөтен рәхәтлекләрнең иң югары ноктасы диебрәк кабул итәбез. Тагын хыялыбыз ирек биргән дәрәҗәдә әллә ничекләр катлауландырып бетерәбез һәм шул хыяллар арасында үзебез дә адашып калабыз. Нәтиҗәдә, бәхет үзе дә бер хыялга әверелә. Һәм бу бәхет бар, кайдадыр бик якында гына, әмма аңа ирешү берничек тә мөмкин түгел кебек тоела. Бераз куркыныч та. Соң ул бәхеткә ирешкәннән соң тагын ничек яшисең? Нәрсә эшлисең, кайда омтыласың? Бәхеткә ирешкән кеше иң биек кыяның иң очына менеп төшәлми утырган бәндә кебегрәк тоела. Дәлше менәр хуты юк, ә төшү – куркыныч. Шушы курку безне бәхетле булудан тыеп кала. Аны кичектерәбез. Без бәхеткә омтылырга гына тиеш, ә аңа ирешү мөһим түгел дип уйлыйбыз.

Әле «халык бәхете» дигән сүз дә бар. Монысы инде бөтен кешеләрнең уртак теләкләре кабул булу сыманрак нәрсәдер. Әйтик, бөтен кеше тук яшәргә тели, теләкләре кабул була. Алар бәхетле.

Менә бүгенге чор. Кеше бай яши. Узган гасыр авылында күтәрмәле чабата кигән кеше бай булып саналса, бүген иң соңгы хәерче дә чабата кими. Ашау-эчү ягы да ничава. Әмма беркем дә үзен без бәхетле халык дип әйтергә ашыкмый һаман...

Миңа кайчагында болай тоела. Кеше бүген үзенә килгән уңыштан бигрәк, күршесенә килгән уңышсызлыкка ныграк шатлана. «Әһ-һә, әлләкем булырга теләгән идеңме, бернәрсәң дә барып чыкмады. Ярык тагарак алдында калдың. Вәт шул кирәк сиңа!» – дип сөенә ул, әйтик, банкротка калган күршесенә карап. Бу тойгы һәркемдә дә диярлек бар. Һәркем эченнән генә күршесенең (көндәшенең, дошманының, дустының) уңышсызлыкка ирешүен тели. Тегеңә килгән фәкыйрьлек фонында үзе бай булып күренер кебек тоела.

Ә хәзер күз алдына китереп карыйк. Кешеләрнең шушы уртак теләкләре тормышка ашты, ди. Бөтен кешенең күршесе үзеннән фәкыйрьрәк, ди. Ну?..

Гомумән, «халык бәхете» дигән сүз ничектер сәер яңгырый. Бәхетле халык ул бәхетле кешеләрдән тора ич инде. Ә бәхетне һәр кеше үзенчә аңлый яки аңламый. Син, әйтик, бер ыштан алып киясең дә сөенәсең. Ә ул ыштан миңа ярамый – размеры туры килми, тегелеше ошамый, материалы бүтән һәм, гомумән, ул хатын-кызныкы. Бәхет тә шулай. Сиңа килгән бәхет миңа ярамый – размеры туры килми... Шул рәвешле, «халык бәхете» дигән төшенчә бөтен кешегә бертөрле ыштан кидергән сыманрак төсмер ала.

Фәлсәфи яктан караганда, бәхет турында гомер буе язарга, гомер буе сөйләргә һәм бер карарга да килмәскә мөмкин. Монда артык сүз куерту түгел, ә математик төгәллек кирәк. Математика ярдәмендә бөтен нәрсәне дә аңлатып була. Әйтик, бер сәясәтче халык тормышы, гаделлек, намус турында фәлсәфә сата. Без аңа ышанып, бу бик гадел кеше икән, бик акыллы сүзләр сөйли дип утырабыз. Ә бухгалтер математика ярдәмендә тегенең барлык керем-чыгымнарын чутлап күрсәтә – һәм сәясәтчебезнең чын йөзе ачыклана. Сан янында сүз көчсез.

Бәхет ул – канәгатьлек тойгысы. Шөкер итә алу. Бу нәкъ менә укытучы куйган билге сыман. Канәгатьләнү – «өчле», шатлану – «дүртле», бәхетле булу – «бишле». Һәм бу билге – тормышның һәр соравына тоткан җавабың өчен. Һәм иң мөһиме – бу билгене син үзең куясың. Буш амбицияләрдән, артык югары таләпләрдән арынган саен, бәхеткә ныграк якынаясың.

PRESSA

ТЕАТР ЯШӘТӘ, ЯШӘРТӘ...

...1991 елда Зилә Казан педагогика институтына читтән торып укырга керә. Кулында өч кечкенә бала белән! (Югары белем турындагы хыялны бер чынга ашырырга бит инде!) Группадашы Галия исемле ханым, аның Нагорный бистәсендә яшәвен белүгә: «Әйдә безгә, театрга!» – дип чакыра. «Киләм!» – ди Зилә. Дәрвишләр бистәсендә урнашкан С. Сәед-Галиев исемендәге мәдәният сараенда эшләүче халык театрына шулай килеп эләгә ул. Театрның гөрләгән чагы! «Зәңгәр шәл»не куярга әзерләнеп яталар. Уйнарга теләүчеләргә роль җиткерә торган түгел! Мәдәният сарае – сугыш вакытында Ленинградтан Казанга, Дәрвишләр бистәсенә эвакуацияләнгән хәрби заводныкы санала. Аның архитекторы Кудвинский да – Төньяк башкаладан. (Менә ни өчен биредә үзеңне «Кышкы сарай»да кебек хис итәсең! Колонналар, люстралар, төсләр – барысы да кабатлана.) Театрның артистлары – башлыча завод эшчеләре: гөрләшеп эштән туры бергә киләләр, бистә урамнарын тутырып, җырлашып кайтып китәләр. Барысы да диярлек парлылар: күпләр шушы театрда танышкан, кавышкан – балалары шушында үсә... Режиссерлары кем диген?! Һидият ага Солтанов, Ленинградта театраль белем алып кайткан Шамил Галиуллиннар! Соңарып килеп кушылган Зиләгә дә кечкенә генә булса да роль эләгә. Әмма спектакль инде чыга дигән көннәрдә, кинәт йөрәк өянәге белән Зиннур Сафиуллин үлеп китә. Мулла роленә аны алыштырырдай башка кеше тапмыйлар... Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» спектакленә тотыналар. Зилә – комсыз, акча яратучы Расиха. Ул арада дөньялар үзгәрә. Күпләрдә театр кайгысы калмый. Аңарда да. Ире белән юллары аерыла – ялгызы гына өч баланы үстерәсе бар...

– Мин кабат театрга бик күп еллардан соң гына килдем. Ике кызым, улым инде аякка баскач кына. Тормышымда шундый авыр чор иде ул... Үз-үземне ничек тә авыр уйлардан коткарырга кирәк иде... Әмма театрдан китсәм дә, коллективтан бөтенләй аерылмаган идем бит: яннарына кереп йөрдем, премьераларын калдырмадым. Берсендә спектакльдән соң чәй эчү мәҗлесенә эләктем. «Безгә яңа режиссер – Рафис Фазылҗанов килде», – диләр. Ул миңа бик өметле күренде... Шуңа да театр ишеген кабат ачып керергә тәвәккәлләгәнмендер...

Рафис аңа «Ай булмаса, йолдыз бар» спектаклендә... Мәдинә ролен бирә. Башта югалып кала Зилә ханым: япь-яшь Мәдинәне уйный алырмы? Әмма нинди генә очракта да гел алга атларга күнеккән кешене бу гына туктатмый, билгеле.

– Машинасыз калган вакытым иде ул минем. Репетицияләр соң бетә. Көлсәеткә җәяү кайтып җиткәнче кайчак төнге сәгать унике була. Үз йортымны салып кергән идем инде... Ике бистә арасында йөри торгач, премьерага кадәр шактый ябыктым, сылуландым. Сәхнәдәге Мәдинәмә 20 яшьтән артыкны бирмәгәннәрдер...

Бар мәшәкатен, чыгымнарын дәүләт күтәргән театр түгел инде алар. Сәхнә костюмнарын, декорацияләрне беркем дә китереп бирми. (Ярый әле режиссерларының кулыннан бөтен эш тә килә: үзе рәссам, үзе тегүче.) Мәдинәгә күлмәкне Зилә ханым исә үзе тегә.

Тамашачылар арасында Туфан ага Миңнуллин үзе дә утырганда каушаткандыр, билгеле. (Беренче җөмлә юкка онытылмаган бит инде ул!) Әмма күренекле драматург аларга рәхмәт әйтеп китә. Мәдинә роле Зилә ханымның үзенә дә тормыш сындыра язган җирдән кабат тураеп басарга ярдәм итә.

«Әни килде» (Шәриф Хөсәенов), «Кызлар капкыны» (Данил Салихов), «Без бит авыл малае» (Туфан Миңнуллин), «Безне онытмагыз» (Фәүзия Бәйрәмова)... Зилә ханым Идрисова катнашкан спектакльләрнең саны гел артып тора. 60 ел буе ремонт күрмәгән С. Сәед-Галиев исемендәге мәдәният сарае да, ниһаять, яңартылган менә. Артистлар өчен дә яңа мөмкинлекләр тудырылган: сәхнә әйләнә, оркестр чокырына кадәр бар. Театрны яшәтү, аңа яңа кешеләр тарту гына елдан-ел авырая бара.

– Башка пенсионерлар кебек өйдә, капка төбендә генә утыра белмимдер... Театр – ул миңа ризык кебек. Рухи ризык! Театр мине яшәтә! Соры дөньядан качып килеп кердем бит... Әйе, театр яшәртә дә! Премьера якынлашса, үзеңне кулга аласың, диетага утырасың... Спектакль тәмамлангач, чәчәкләр күтәреп, сәхнәгә оныклар менә. Мәдәният сарае яныннан узганда алар һәрвакыт: «Әбекәй театры!» – диләр...

Зилә ханымны театр гына түгел, спорт та яшәтә. Ул балачактан бирле чаңгыда йөри, хәзер менә тау чаңгысында шуу белән мавыга. Чын-чынлап! «Инструктор алдым, шунсыз булмый: миңа тау чаңгысында шууның техникасына яхшылап төшенергә һәм онықларыма да өйрәтергә кирәк», – ди ул. Ә өстәл теннисында аяктан егылганчы уйный ала! Каракаршы уйнарга партнер гына булсын!

Хыялларга күчәбез...

– Хыяллар! Ничек инде алар миндә булмасын?! Парашюттан сикермичә калдым. Хәер, калдым дип әле... Тәвәккәлләп бер барган да идем, ул көнне эшләмәделәр. Гармунны мәктәптә укыган чагымнан бирле шыгырдатам – үземә кирәк бөтен көйне чыгарам... Гитарада уйныйсы килә менә... Анысына ничектер акча җиткерә алмадым. Әмма әле соң түгелдер дип уйлыйм... Укытучылар нәселе без – бер эшкә тотынсак, башаяк белән чумабыз. Балалар бакчасында эшләгәндә татар төркеме ачтык. Мин аны республика күләмендә үрнәк итеп күрсәтерлек дәрәҗәдә күтәрелүенә ирештем. Нинди генә чара уздырсам да, төркемдәгеләргә маскаларны үзем ясадым. Кайсы көнне үземнең балалар белән бакчада кунып кына кала идек... Яңалыктан курыкканымны хәтерләмим. Теләк булып та, тотынырга өлгермәгән эшләр байтак анысы. Үз-үзеңне мотивацияләргә өйрәнсәң – идән, кер юу кебек ашыгыч эшләрне мөһим эшләр рәтенә кертмәсәң, барыбер күпкә ирешәсең. Бер нәрсәгә сөенәм: вакытында намазга бастым. Оныклар үсеп китеп, намазсыз калса, үземне кичермәс идем...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

– «Ай булмаса йолдыз бар»ның премьерасы. Мин – Мәдинә ролендә... Исегездә булса, спектакль башланганда Мәдинә авырып яткан әнисенең караваты янында, тамашачыларга арты белән басып тора. Бөтен күзәнәкләрем белән пәрдәнең инде әкрен генә ачылуын сизәм. Менә-менә музыка туктаячак... Һәм шул минутта сүзләремне онытканымны аңлыйм... Берни хәтерләмим! Ана ролен уйнаучы Мәдинә апага: «Сүземне оныттым, мин нәрсә әйтергә тиеш әле?» – дим пышылдап. «Чыгып, Рафистан сора!» Күрсәгез иде... Шундый җитди итеп әйтте! Бездә моны әле дә мәзәк итеп сөйлиләр... Беренче дулкынлану узуга, рольнең сүзләре, әлбәттә, искә төшә ул чакта.

Фото: Анна Арахамия

«ИДЕАЛЬ АРТИСТ БУЛАСЫМ КИЛМИ...»

Аның тормышы бәйге-фестивальләр белән бәйле. «Созвездие-Йолдызлык», «Татар моңы-2016», «Усадьба Jazz Роза Хутор» фестивале (Сочи), «Үзгәреш җиле»... «Созвездие-Йолдызлык» фестивале аңа Мәскәүнең данлыклы ГИТИСына юл ача. КФУда социаль-философия фәннәре һәм массакоммуникацияләр институтында да укый. Казан музыка көллиятенең эстрада-джаз бүлеген тәмамлый. CheekLaWeek төркеме төзеп, альбом чыгарган Зәринә ВИЛДАНОВА – татар халык җырларына яңа сулыш өрүче.



Зәринә, журнал укучыларыбызга үзеңне ничек итеп таныштырыр идең?

– Ике ел элек татар музыкасына яңа сулыш кертүче буларак танылдым дип әйтер идем. Әмма... мәктәптә укыганда ук татар җырларын үзгәртеп башкара идем инде. Бу өлкәдә үземне беренче дип уйладым. Ләкин Мубай, Зөлфия Камалованы тыңлагач, ялгышканымны аңладым. Аннан татарча джаз белән кызыксына башладым. Монда да үземне чишмә башында торучы дип йөрдем. Үзем өчен Регина Сәйфи дигән бик талантлы җырчыны ачкач, ул фикеремнән дә кире кайттым. Хәзер үземне җырчы-экспериментатор дип саныйм.

Син татар халык җырларын этник, фолк, джаз стильләренә үзгәртеп җырлыйсың...

– Әбиемнең күңеле этәргеч бирмәде микән?! Әбием – бөтен урманчыларны җыеп тоткан бик тә гадел урманчы хатын иде. Өйдә җыелышып, баянда җырлашып утырырга яраттылар. Халык җырлары шуннан күңелемә кереп калгандыр. Музыка мәктәбендәге укытучым Ландыш Фәттахова белән әбиемә багышлап, укытучым белән «Олы юлның тузаны»н эшләдек. Аннан «Урманнарга керсәм», «Зәңгәр күлмәк»не чыгардык. Ул җырларның һәрберсенә шәхси фаҗигам салынган... Үзем дә җырлар иҗат итәм. Мин автор-башкаручы да.



« Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



Без, татарлар, калыплар яратабыз. Ярамыйлар күп. Ул татар җырларына да кагыла. Җырларга керткән үзгәрешләрне тәнкыйть итүчеләр булдымы?

– Булды, әлбәттә. «Халык җырларына тимә, аларны бозма» дигән шелтәләрне күп ишеттем. Берсе бик тә истә калды: «Татар халык җырларын алай җырлау ярамый. Аларны өстәл артында бергәләп кенә җырларга кирәк». Ни өчен тәнкыйтьләгәннәрен дә аңлыйм. Яңалыктан куркалар. Шунысы да бар: җыр тыңлап, мәгънәсе турында артык уйланырга да яратмыйлар. Ә мин тудырган иҗат – уйландыра, фикер уята. Бәхәсләшмим, җыр төрле булырга тиеш: гади дә, шаян да, фәлсәфи дә... Әмма шуны әйтер идем: фәлсәфәле иҗат та киң катлам тамашачыларга үтеп керә башлады. Шуңа да каршылыклар күптер.

Ә син аларга карамый алга барасың...

– Максатым: татар халык җырларын Россиядә генә түгел, бөтен дөньяга таныту. Шуның өчен Cheek-LaWeek төркеме җыйдым. Әмма минем төркемем дә бердәнбер түгел иде. Моңа шатланам гына. Татар җырлары актуаль булсын өчен, аның төрле жанрларда булуы шарт. Элвин Грейн татар җырларын тагын да популярлаштырды. Илгиз Шәйхразыев, мәсәлән – татарның Иван Дорны. Усал дигән җырчы татарча рэп укый. Шәп укый! Ләкин күпләр белми аларны. Ә без күрше Башкортстандагы альтернатив җырчылар белән таныш түгел. Үз сазлыгыбызда кайныйбыз. Шуның өчен төрле фестивальләргә йөрергә кирәк. Безнең музыкаль продукт шәп һәм сыйфатлы. Иҗат кешесе һәрвакыт эзләнүдә булырга тиеш, минемчә. Дөнья үзгәрә, яңа кысалар куртә. Бу кысаларны җимерер өчен яңалык дулкынында булырга кирәк.

Син ГИТИС тәмамлаган кеше. Театрда да уйныйсың...

– Мин драматик артист булмаячакмын. Әйе, төрле театраль проектларда катнашам. Алар гадәти түгел, хәтта акылга сыймаслык дип әйтер идем. Режиссер Резеда Гарипова белән сәхнәне башка яктан ачтым. «Сәйдәш. Йокысызлык» лабиринт-спектаклендә – Моң, «Карурман»да Бөек Каһин рольләре үземне эзләргә мәҗбүр итте. Резеда, төрле детальләр кертеп, стресслы ситуациядә калдырды. Ә бит стресс вакытында кеше үз асылын ача.

«Әлиф» иҗади берләшмәсенә кушылу да бердәнбер булуны эзләүме? Мондый иҗат төркеме татарда әлегә башка юк кебек.

– Нурбәк белән (Н. Батулла – биюче, берләшмәне оештыручыларның берсе. – *ред.)* Америкага фестивальгә баргач таныштык. Аның репетицияләре үзенчәлекле: медитацияләр, тынычлану өчен күнегүләр. Без бер-беребезне тоярга өйрәндек. «Сәхнәдә ирекле булырга кирәк. Иң мөһиме нәтиҗә түгел, ә процесс», – ди ул. Ягъни сәхнәдә нәрсә телисең шуны эшлисең. Моны кабул итү бик авыр. Үзең белән көрәш бара. Әйе, килешәм, бу иҗади берләшмә – бердәнбер.

Альтернатив музыка киң катлам тамашачысына үтеп керерме?

– Әлбәттә. Яңалык кертүчеләргә авыр, билгеле... Заманында Илһам Шакировка, Әлфия Афзаловага да шулай ук җиңел булмагандыр. Алар да бит эстрадага яңалык алып килгән җырчылар. Сузып җырлана торган озын көйләр дә, аларны яратып тыңлаучылар да калачак. Ансыз без яши дә алмыйбыз. Әмма шуны беләм: яңа сулыш өргәннән соң, күп яшьләр татар халык җырларын беренче тапкыр ишетте. Бу да татар җырын таныту түгелме?!

Зәринә, тормышта син нинди?

– Сәхнәдә мин үземә бик таләпчән. Идеаль булырга тырышам. Әмма ул позициямнән китәсем килә. Идеаль түгел, ә тере, чын булырга кирәк. Монда миңа Нурбәк белән Резеда ярдәм итә. Караокеда кычкыра-кычкыра җырларга яратам. Үземә дөрес итеп җырламаска ирек бирәм. Тормышымда үз-үземне табасым килә. Сәнгатьтә генә түгел, ә гаиләдә дә. Иҗатым гаиләмә зыян китерә башласа, гаиләмне сайлаячакмын. Ул – беренче урында. Минем иҗатым да гаиләмә багышланган. Әби-бабаларыма...

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ
Видеоны төшерүдә ярдәм иткән өчен Татарстан Милли китапханәсенә рәхмәт белдерәбез

«СЕЗНЕ КҮРЕР ӨЧЕН ГЕНӘ КАЙТТЫМ...»

Бакый дөньяга күчкән әниебез Яруллина Фәридә Габделхак кызы өстәлендәге китап-дәфтәрләрне барлаганда, сугыштан авыру булып кайткан әтисе турындагы хатирәләре килеп чыкты. 9 Май бәйрәме алдыннан оныклары үтенече буенча язылган бу истәлекләр, елдан-ел сирәгәя баручы сугыш чоры буыны кешеләре язмышын кабат күңелләрдә яңартты. Әйе, аерым бер шәхеснең – безнең әнинең генә түгел, канатлары каерылган тулы бер буынның…



1940 елның 9 июнендә Кайбыч районы Иске Чәчкаб авылында Хәлимә һәм Габделхак Закировлар гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә әниебез. Кеше гомеренең иң матур һәм бәхетле чоры булырга тиешле балачак һәм яшьлек еллары куркыныч сугыш тарафыннан имгәтелә: кечкенә кызның бик күп матур хыяллары җимерелә. Сугышның беренче көненнән үк аның да әтисе фронтка китә, әнисе, әби-бабасы ут йотып яши башлый. Өйләре хәрби штабка әйләндерелгән, командирлар аларда кунып кала торган була. Төне буе эчеп, күңел ачып чыгу сәбәпле, иртән уяна алмаганнар. Окоп казырга әмер алу өчен килгән солдатлар ишек төбендә туңып көтеп торганнар. Үткен һәм гайрәтле әби: «Выставайт, салдат умирайт!» – дип кычкырып, командирларны уята торган булган…

Әни үзенең балачагы, бигрәк тә әбисе белән бабасы турында дәү әниебез хатирәләренә таянып сөйләргә ярата иде. Әхмәтзакир бабасы белемгә һәвәс һәм бик тырыш булганга, аларның гаиләсе ачлыктан интегеп, теләнчелек юлына басмаган. Шулай да сугыш чорының авырлыгы ул чор кешеләренең бөтен күзәнәкләренә кадәр үтеп кергән. Әниемнең балачагы белән бәйле,

беренче карашка бик әһәмиятле күренмәгән, ләкин ул чорның символик атрибутлары саналган берничә күренеш күңелгә уелып калган: сөяктән ясалган уенчыклар, мәктәпкә бару өчен абыйсыннан калган такта сумка (аны бабалары үз кулы белән эшләгән), язын кар эрегәч бакчадан җыйган черек бәрәңге һәм алабутадан пешерелгән икмәк... Шул авызга алмаслык төче икмәк һәм такта сумка да кечкенә кызда яңа үрләр яуларга көч бирә – ата-бабаларыннан күчкән белемгә омтылыш гел үзен сиздереп тора. Кече Кайбыч авылыннан килеп укытып йөргән Рәхмәтулла Сөнгатулла улы Биктаһиров кебек укытучылар да кызның күңелендәге яшерен хыялларына көч өсти, канатландыра... Сугыштан соң җиденче классны «яхшы» билгеләргә тәмамлаган әниебез, шәһәргә китеп, укуын дәвам итәргә карар кыла. Ләкин аның бу хыялы ул чорның колхоз идарәсе таләпләренә туры килми шул: шәһәргә укырга китү өчен аңа паспорт бирмиләр – унбиш яшьлек кызны колхоз фермасына бозау караучы итеп куялар. Ул елларда фермада бөтен эш кулдан башкарыла, айлар буена хезмәт хакы түләнми. Озак вакытлар бушка эшләгәннән соң, ниһаять, беренче хезмәт хакы бирәләр, һәм ул акчага яшь кыз үзенә итәк-костюм, аяк киеме сатып ала. (Матур киенү теләген тормыш авырлыклары да җиңә алмый!) Акчасызлык һәм юклык әнине тагын бер эшкә – хат ташучы хезмәтенә дә алынырга мәҗбүр итә. Колхоз эшеннән бушаган арада, бабасы алып кайтып куйган газеталарны йөгерә-йөгерә авыл урамнары буйлап тарата. Ике эшне берьюлы алып барган тырыш кыз, иске өйгә кияү кертмим дип, урманда бүрәнә әзерләү эшенә дә тотына. Абыйсы читкә эшкә чыгып китү сәбәпле, өйне яңарту – пычкы тотып агач кисү, бүрәнә күтәрү кебек ирләр эше әни өстенә кала. Йорт-җирен матур итү теләге һәм эшкә батырлык сыйфаты бөтен авырлыкларны җиңәргә булыша: Кече Кайбыч авылына килен булып төшкәнче, әтисе нигезендә яңа йорт салып калдыра ул.

Әниебез эштән беркайчан курыкмады һәм зарланмады, һәр эшне фидакарьләрчә җиренә җиткереп башкарды. Фәкать аның күңелендә һич төзәлмәс бер яра бар иде: әтисе немецларда әсирлектә булганы өчен җитәкчелекнең әнисенә салкын мөнәсәбәте. Бигрәк тә Җиңү бәйрәме көннәрендә сугышта үлеп калучыларның тол хатыннарын искә алганда, ветераннарны котлаганда, дәү әнинең кимсенүе, аңа бер открытка да бүләк ителмәве әниемнең йөрәген гел сыкрата иде. Дошманга әсир төшәргә катгый рәвештә тыелган икәнен белсә дә, кулында сугыш коралы да булмаган ач һәм хәлсез солдат нишләсен соң... Дәү әнинең сөйләве буенча, Габделхак бабай әсирлектән берничә тапкыр кача. Ләкин кайсы якка таба карап йөгерсәң дә, дошман җирендә һәр адымда сине әсирлек сагалап тора. Соңгы тапкырында бер дусты белән бергә качалар, юлда иптәше хәлсезләнеп егыла, бабай үзе дә аякта көчкә басып тора. Бер авылга җиткәч, бер немец әбисе аны тавык кетәклегенә кертеп яшерә. Мәрхәмәтле карчык артыннан эзләп

Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» дигән китабында язылганнар – нәкъ әти сөйләгәнчә.

килгән немец солдатларына бабайны сатмый. «Минем дә улым сезнең кебек тилмереп йөридер», – дип, совет солдатына үзендә калырга рөхсәт итә. Шул кетәклектә туңып озак ятkангамы, әсирлектә күргән җәзаларданмы – бабай туган ягына үпкә чире белән кайта. Туган авылына кайтып бераз хәл җыйгач, колхоз эшенә чыгарга мәҗбүр була: гаиләне туендырырга, ипилек булса да эшләргә кирәк бит. Үзенең бик тиздән үләчәген белгәнгә, өченче балага авырлы хатыны өчен борчыла, «Ялгыз башың ничек кенә үстерерсең икән бу балаларны?!» – дип өзгәләнә... Тормыш авырлыкларына баш имәгән дәү әниебез өч баласы янына бабайның сеңлесенең бер яшьлек кызы Рәшидә апаны да сыендыра әле – барысын да үстереп, олы тормыш юлына чыгара.

Тугыз дистәдән артык гомер иткән дәү әниебез, әниебез инде мәңгелеккә китсәләр дә, сугыш китергән авырлыклар, Габделхак бабай белән бәйле әрнү һәм сыкрау хисләре югалмады, алар безгә – балаларына, оныкларына күчеп калды... Бу урында туктап, әнием язып калдырган хатирәләргә күчәм. Биш-алты яшьлек кыз баланың моңсу кичерешләре белән олы яшьтәге ханымның сагышлы тойгыларын бергә үреп биргән бу язма – әтиләрен сугышта югалтканнар өчен тирән күңел яраларын кабат яңарту булса, сугыш афәтен бары тик укып-ишетеп кенә белүче яшь буын өчен ачы тарихи хакыйкатькә бер мисал дип саныйм. Сугышлар башка кабатланмасын һәм Ватан язмышы өчен үзләрен корбан итүчеләргә гаделсез мөнәсәбәт булмасын иде дигән теләктә калам. Текст, зур үзгәреш кертелмичә, әниебезнең язу стилендә бирелә.

«Исемдә калганнардан»

1945 елның көз айларының берсендә (октябрь, ноябрь) тәрәзәбезне шакып: «Сөенеч! Габделхак кайта!» – дип кычкырдылар. Өйдәге кешеләрнең барчасы чыгып йөгерде. Туганнан туганым Гөлҗиһан ул көнне бездә иде, мин аның белән уйнап йөргән җиремнән куян мамыгыннан бәйләнгән башлыгымны киеп куйдым. Ул башлыкны әби, бер сынык икмәк биреп, берәүләрдән алып калган иде. Өйгә кайтып кергәч, әти мине кочагына күтәреп алды. Өй эче халык белән тулды, кайсы елый, кайсы: «Безнекен күрмәдеңме?» – дип сораша.

Кешеләр таралышып, чәй эчәргә утыргач, әти: «Мин кайтканга артык шатланмагыз, сез – мине, мин сезне күрер өчен генә кайттым», – дигән. Шуннан башланды инде авыр көннәр... Әти гел авырый, хәле юк. Ул кышны авырып чыкты. Тәрәзә буендагы сәкедә ята иде. Тавышланырга ярамый, урамга чыксам, капка төбенә

Көзен кыр казларының тавышын ишеткәндә, әтием искә төшеп, мин дә елыйм.

малайларны да китертмим. Әнинең сөйләве буенча, мин капканы «шап» иттереп ябам икән. Әтием исә: «Фәридә капканы нигә шулкадәр каты яба соң?» – дип сыкрана торган булган әбигә. Шунлыктан әби: «Кызым, капкадан йөрмә, арттан, нәүрәп артыннан йөр», – дигәч, арттан йөри башладым. Ләкин бу юлы да әтием бакча таптала дип борчылган. Кыш буе шулай гел пошынып, бик каты авырып чыккан.

Әти бертуганы Зиннәтша абый белән сугышның беренче көнендә үк фронтка чыгып киткән. Алар китүгә икенче көнне Зиннәтша абыйның икенче улы Ринат дөньяга килгән. Улының туу хәбәрен ишеткәч, абый: «Ярар, нигез хуҗасы булыр», – дип язган. Чыннан да, шулай булды – Ринат Иске Чәчкаб авылында атасы нигезендә яшәп калды.

Кайсы якта, кайсы фронтта булганнардыр – ике туган бер-береннән аерыла. Зиннәтша абыйдан үлем хәбәре килә. Әти булган төркемне немец солдатлары куып киткән. Көзге яңгырлы көн, өсләрендә кием юк... Юлда бер кеше шинель күтәреп торганын күреп, әти тиз генә шул шинельне алып кия. Әсирлектә аларга ашарга көнгә берәр уч арыш биргәннәр.

Күпмедер вакыт узгач, әти ул мәхшәрдән качкан, тик үзебезнең якка чыгып җитә алмаган. Бер немец офицеры, мотоцикл белән очрап, кире алып киткән. Анда аңы югалганчы кыйнаганнар, салкын подвалга япканнар. Күпмедер ятканнан соң чыгарганнар һәм кайнар цехка эшкә куйганнар. Ашарга юк, ачлыктан аякта басып торырлык көч юк... Немецлар арасында да миһербанлылары очраган: сакчыларның берсе билгеле бер урынга ашарга куеп киткәләгән.

Аннары башка әсирләр белән бергә әтине дә хуҗалыкларга тараткannar, анда сыер саудырганнар. Сыер саварлык хәле булмаган – куллары шешеп чыккан. Алай да сакчылар күрмәгәндә бераз сөт эчеп, хәл җыйгалаган. Аягында гел богау булган. Хуҗаларның нинди эшләре бар – барысын да эшләгәннәр. Атларын болынга илткәндә, алып кайтканда кыр казларының каңгылдашып очканын күреп: «Сез үз илегездә бит...» – дип, әти юл буе елап бара торган булган...

Аларны Америка солдатлары коткара: шатлыктан кочаклашып елашалар... Әти шактый гына больницада яткан. Бераз хәл кергәч, кайтырга рөхсәт биргәннәр. Озатып куйыйк дисәләр дә, әти үзе генә кайтырга булган.

Әле дә хәтерлим, «Әтиең кайда?» – дип сорагач, сугышның нәрсә икәнен белмичә, «Сугышта! Миңа күлмәк алып кайта!» – дип әйтә идем. Чыннан да, әти сугыштан миңа күлмәклек материал алып кайткан иде. Аны үзе белән больницада ятучы бер иптәше биргән: «Кызым бар дип әйтәсең, ал», – дигән. Шакмаклы материал иде ул...

Әни көне буе колхоз эшендә булгач, әти өйдә гел әби белән кала иде. Әти: «Эштән калып, бераз минем янда тор әле», – дисә дә, әни эшкә барырга мәҗбүр. Бик кырыс вакытлар бит...

Абый белән чоланда йоклый идек. Беркөнне әни яныбызга чыкты да, безне кочып елый башлады: «Әтиегез китте», – диде. Әтинең җеназасын өйдән алып чыкканда: «Әтине алып китмәгез...» – дип кычкырып елаганымны хәтерлим. Бар да: «Кайта ул, кайта», – дип мине юаталар. Әтинең кайтканын һаман көтәм әле... Үзем барырмын инде яннарына. Әни дә шунда, энем Рәшит тә... Рәшит әтинең кырыгы узгач туган иде, ул инде күптән алар янында...

Бу – истә калганнар, әни сөйләгәннәрдән. Әни исән булса, барын да сорашыр идем. Соң шул инде... Элек сөйләшеп утырырга вакыт тимәгән. Хәзер вакыт та бар – әни юк...

Бүген 7 май, 2020 ел. Ураза вакыты. 9 Май – Җиңү бәйрәме якынлаша. Безгә бернинди шатлык алып килми бу бәйрәм. Сугышта булганнарга пособиеләр, пенсияләр бирделәр. Ләкин сугышның беренче көненнән фронтка киткән һәм сугыш беткәч кенә кайтып, сызланулар эчендә нибары ун ай яшәп калган әти кебекләр күләгәдә күмелеп калды. Өч кечкенә бала белән бик яшьли тол калган әни гомере буе кимсенеп яшәде... Әле ярый бабай бар иде, аңа зур рәхмәт – ул безне үз канаты астына алды...»

Рамилә ЯРУЛЛИНА-ЙЫЛДЫРЫМ.
Кече Кайбыч авылы.



Игътибар! Яңа проект!

КЕМНӘРДӘН ҮРНӘК АЛЫРГА?



Үрнәк татар гаиләсе нинди була?
Халкыбызның гореф-гадәтләрен, рухи кыйммәтләрен ничек саклый ул?
Балаларда туган телебезгә мәхәббәт уятуның алар гына белгән серләре бармы?

«Татар гаиләсе/үрнәк алыгыз». Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән берлектә «Сөембикә» журналы башлаган уртак проект шулай дип атала. Максатыбыз – Татарстанның район һәм авылларында яшәүче матур татар гаиләләре белән таныштыру, татар гаиләсен зурлау, татар гаиләсенең үрнәк моделен сурәтләү.



Бәлки, сез шундый гаиләләрнең берседер, ә бәлки, андый гаилә сезнең янәшәгездә яшидер? Шулай икән – бу бәйге, димәк, сезнең өчен! Безне үзегез белән таныштыру өчен редакция белән элемтәгә керү җитә*. Шалтыратыгыз, языгыз – тәкъдимнәрегезне көтәбез. Безнең журналистлар сез яшәгән төбәккә юлга чыгарга инде әзер!

Конкурс гыйнвар аеннан башлап декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Җиңүчеләр махсус жюри карары буенча ачыкланачак.

Бәйгедә җиңгән биш гаиләне кыйммәтле бүләкләр көтә!

**Искәрмә: конкурсның шартлары белән тулысынча «Сөембикә» журналы сайтында таныша аласыз.*
www.syuyumbike.ru



ОЛЫ ЙОРТ КИЛЕНЕ







Лилия ГӘРӘЕВА

Альбина һәм Алмаз ФАЗЛЫЕВлар – авылда менә дигән итеп яшәп ятучы яшь гаиләләрнең берсе. Мохитләре – татарныкы, яшәү рәвешләре – чын татарча. Ир-ат зурланган, олылар хөрмәтләнгән, балалар Аллаһы Тәгаләнең бүләге итеп кабул ителгән, мул тормышлы матур гаилә бу. Альбина – блогер. Гап-гади татар авылында яшәүче гади генә татар кызының аккаунтына 60 меңнән артык кеше язылган. Аны күзәтеп баручылар да татарлар, чөнки ул алар белән татарча аралаша.

Шәхсән үзем аның тегү дәресләренә мавыгып язылган идем. Кайдадыр ерак бер авылда бер ханым үз өендә остаханә ачып, хатын-кызларга матур-матур күлмәкләр тегә – кызык бит. Чынлыкта, тегүгә генә багышланган блог түгел ул, анда чып-чын авыл тормышы – әбиле-бабайлы, балалы-чагалы, печәнле, бәрәңге бакчалы, сөтле-каймаклы... Ул блогта туган телебез, авылның бүгенге көне, гореф-гадәтләребез... Гаиләдәге җылы мөнәсәбәтләр дә чагыла анда, мәхәббәт тарихы да, өлкәннәргә булган хөрмәт тә... Аны хәтта яшь киленнәргә тормыш сабаклары дип әйтер идем әле. Һәм шулай атар да идем: «Бәхетле булырга теләүчеләргә Альбина Фазлыева сабаклары».

Альбина Фазлыева блогыннан: «Ир-ат өчен дә, хатын-кыз өчен дә гаилә иң зур нигъмәт ул. Бу гаиләдәге ир һәм хатынның, балаларның бәхете андагы мөнәсәбәтләрнең ничек корылышына бәйле. Кечкенәдән әтине ихтирам итәргә өйрәттеләр безне. Ул – гаилә башлыгы, аның фикере һәрчак өстен иде. Әти безгә терәк тә, ышанычлы яклаучы да булды. Әни исә аның булышчысы һәм һәр эштә аның фикердәше. Балачагымнан менә шундый гаилә моделе формалашты миндә. Шуның өчен дә үз гаиләмдә икенче рольдә булу миңа бер дә читен түгел. Ирне гаилә башлыгы дип, ә үзеңне аның ярдәмчесе дип тану мөһим әйбер. Хатын-кызның нәфислеге көчсезлектә түгел, ул – нәзакәтлелектә, миһербанлылыкта, җылылыкта. Нәфислеген югалту хатын-кызга көч өстәми, ул аны бәхетсез итә».

Альбина – төп йорт килене. Төп йорт дигәч, аңладыгыз инде: туганнарның күңелен гел тартып тора



Мәхәббәтнең гомере өч кенә ел, диләр. Ышанмагыз, чын мәхәббәт – мәңгелек!

торган «кыйбла» монда. Бәйрәмнәрне, Коръән ашларын, туган көннәрне, бәйрәмләп уза төп йорт килененең. Каникуллар җитсә, әби-бабай янына туганнарның балалары елыша... Төп йортның үз кануннары бар. Шушы кануннарны үтәп яшәгәндә генә йортта тынычлык һәм татулык була.

Яшь ханымның үзе белән каракаршы сөйләшәбез. Ничек яши хәзерге заманда төп йорт килене?

– Мондый тормыш миңа кечкенәдән бик таныш, – ди ул. – Әнием төп йорт килене иде. Үземә дә шундый язмыш насыйп булды. Төп йорт килене булуның, билгеле, үзенчәлекләре дә бар. Монда ике якның да сабырлыгы, юл куя белүе кирәк. Үзеңнекен генә кайгыртып, бергә яшәп булмый. Олы кешенең киңәшен тотарга, күңелен күрергә тырышасың, аларның үзенчәлекләрен дә искә аласың. Әти белән әни үзләре дә безгә карата бик зур сабырлык күрсәттеләр. Иремнең әти-әнисенә булган хөрмәтенә беренче көнемнән үк сокланам. Мондый тәрбияне аңа әтиәнисе биргән бит!

Ачу килгән чаклар бездә дә була, билгеле. Дөньяда идеаль кешеләр юк бит. Андый мизгелләрдә бик шәп ысулым бар – дәшмим. Шул вакытта ачуны йотып, сүзеңне әйтми калсаң, соңыннан «ярый әйтмәдем» дип шатланып йөрисең. Үзеңне хөрмәт итүләрен теләсәң, башта үзең хөрмәт күрсәт! Бу – яшәү принцибым.

Альбина Фазлыева блогыннан: «Туган – төче, ят – әче», – ди татар халкы! Әлхәмдүлилләһ, без туганнарга бик бай, бик ишле гаилә! Дәү әнием биш бала үстерде, оныклары да күп булды. Без кечкенәдән күрешеп-аралашып яшәдек. Су коега җыелган күк, дәү әнием йортына балалары гел кайтып торды, өебездән кунаклар беркайчан өзелмәде. Ахирәткә күчәр алдыннан ул барыбызга бер васыять әйтеп калдырды: «Туганлык җепләрен өзмәгез! Һәрчак аралашып, дус-тату яшәгез». Аллага шөкер, дәү әниебез киткәннән соң да туганнар белән араны өзмибез. Табын әзерләп, кунак сыйлаганнан беркайчан да ризык бетми, киресенчә, ул меңе белән кире кайта. Аллаһның илчесе Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләрендә дә: «Әгәр байлыгыгызның киң булуын һәм гомерегезнең озын булуын теләсәгез, туганлык җепләрен ныгытыгыз», – дигән.

Иремнең гаиләсе дә аралашучан, кунакчыл гаилә булды. Алар да минем өчен якын кешеләремә әверелде. Туганлык бәрәкәтне арттыра, нәселне, милләтне ныгыта!»

Фазлыевлар йортында өч буын бергә көн күрә. Килешәсездер – бүген бер йортта өч буын бергә яшәгән гаиләләрне сирәк очратасың. «Әби-бабай белән бергә яшибез», – дигәнне ишетсәк, хәтта гаҗәпсенеп үк куябыз. Әгәр дә сораштыру уздырган булсак, мөгаен, киленнәрнең күбесе төп йортта яшәргә теләмәвен әйтер иде. Әле гаилә корганчы Альбина да шәһәрдә яшәргә хыяллана.

Альбина Фазлыева блогыннан: «Балачагым Киров өлкәсенең татар авылында үтте. Мәктәпне тәмамлагач, зур планнар белән Казанга укырга киттем. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм тегү колледжында белем алдым. Казан шәһәрендә ателье ачу иде хыялым. Инде булды дигәндә, кияүгә алып киттеләр. Шулай итеп, Балтач районының Бөрбаш авылына – Фазлыевлар гаиләсенә килен булып төштем. Студент вакытта, авылга кияүгә чыгып, каз бәбкәсе саклап утырыр хәлем юк, дип сөйләнеп йөргән булсам да, Аллаһ миңа ризыкны авыл җирендә язган. Яңа тормышка бер ел буе ияләнергә туры килде. Иремнең авылга булган мәхәббәте тора-бара миңа да йокты.

Ательемны булдыру хыялы чынга ашты дисәк тә була. Өйдә берүземә бер бүлмә. Кеше кафеларда, матурлык салоннарында ял итсә, минем көч бирә торган урыным – тегү бүлмәсе. Дәү әнием: «Һөнәрле кеше ач булмас», – дип әйтә иде. Яраткан һөнәрең кәсепкә әйләнеп китсә, тагын да яхшы. Бүгенге көндә кул эшләре зур кыйммәткә ия. Һөнәрле булуның тагын бер ягы – гел дә яңа кешеләр белән аралашасың».

Бөрбаш... Фазлыевлар... Балтач районы Бөрбаш авылыннан Җәлил хәзрәт Фазлыев хәтерегезгә килдеме? Ялгышмадыгыз. Альбина – алар килене, төпчекләре Алмазның хәләле. Республикага билгеле андый кешенең килене булу үзе үк зур җаваплылык. Моның шулай икәнен Альбина да яшерми:

– Инстаграмга текст язаммы, фото урнаштырамны – башта кат-кат уйлыйм. Нииндидер сүз әйтеп, әтинең абруена зыян китермәммме? Ул нәрсә дияр? Хупларммы?

Җәлил әти дә, Гөлфәния әни дә – бик акыллы, һәрнәрсәнең хикмәтен белүчеләр. Ник алай итәсез, ник болай итәсез, димиләр. Мин блог алып барам, күп вакытым телефонда, интернетта уза. Бәлки, алар бу эшемнең мөһимлеген дә аңлап бетермиләрдер, ләкин тыймыйлар. Мондый мөнәсәбәткә яхшылык белән җавап бирәсе килү табигыйдыр.

Бүгенге заманда кайнана-кайната белән яшәүне авыр йөк итеп күрәләр. Имеш, алар яшьләр тормышына кысылып, ничек яшәргә кирәген өйрәтә, оныкларны элеккеге заман тәртипләре белән тәрбияләргә тырыша. Килен булып килгәнемә тугыз ел, бергә яшәгәнебезгә бер генә көн дә үкенгәнем юк. Бар кешегә таныш акыл иясе Җәлил хәзрәт йортына килен булып төшкәндә бераз куркытты, билгеле. Зур хуҗалык, мин килгәндә кайнанамның кайнанасы – Җәлил әтинең әнисе дә исән иде. Хәтерлим әле, бу йортта беренче көннәремдә эшне ничек, кайдан башларга, кемнән рөхсәт сорарга да белмим. Җитмәсә, ирем Алмаз да, безнең әти бик кызу кеше, каршы төшә күрмә, дип кисәтеп куйды. Куркуларым бер дә юкка булып чыкты. Җәлил әти кызу булса да, бик шаян, шук, бүтәннәр күңелен аңлый торган кеше бит. «Килен, бу йортта ни кушсалар да, ни әйтсәләр дә, син «ярар», диген дә, үзеңчә эшлә!» – диде ул уены-чыны белән.

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

Бер хәл булса, әниләр кызларын яклый. Минекеләр исә кияүләрен яклый.

Альбина кечкенәдән әнисе белән дәү әнисенең татулыгын күреп үсә. «Өйдә дәү әнигә хөрмәт шулкадәр зур булды. Табынга утырышкач, ризыктан ул авыз итми торып, беребез дә үрелми иде», – ди әңгәмәдәшем. Үзе дә кайнанасы Гөлфәния ханым турында бары җылы итеп кенә телгә ала.

Альбина Фазлыева блогыннан: «Сездә ничек әйтәләр: кайнанамы, биемме? Кайда ничек әйтәләрдер, ләкин бу сүзне ишеткәч, уйга усал карчык килеп баса. Киленгә бер-бер артлы авыр эш кушып, тормыш өйрәтеп тора торган хатын күз алдына килә. Аллага шөкер, хәзер заманалар рәхәт инде, андый элеккеге карашлар артта калды, киресенчә дә әле. Әниләребез, балалары рәхәт яшәсен дип, безнең өчен тырыша!

Килен булып төшүгә авылдашларның күргән берсе: «Син шулкадәр кайнанаңа охшап килгәнсең», – дип әйтә иде. Әле кайчак урамнан үтеп барганда миңа «Гөлфәния» дип эндәшкән чаклар да булды. Аллаһның бер рәхмәте инде бу. Минем әнием кайнанасы – дәү әнием белән һәрчак тату яшәделәр. Тату гына түгел, алар дус кызлар кебек булды! Мин аларның мөнәсәбәтләрен күреп, күңелемнән генә гел дога кыла идем. Миңа да яхшы кайнана насыйп булып, тату гомер итәргә язсын дип сораганым хәтеремдә.

«Килен кайнана туфрагыннан», – диләр. Дөрестән дә, бу безгә туры килеп тора. Әни белән бик килешеп яшибез, сүзебез дә беркайчан бетми, фикер-уйларыбыз белән дә уртаклашабыз. Ул хәтта минем блогымны да күзәтеп бара. Үзенең инстаграмы булмаса да, постларымны аңа укытам, кайчак язганда киңәшләрен дә сорыйм. Ул минем кул эшләрем белән дә кызыксына, теккән чагым булса, кереп эшләремне карап чыга. Аның игътибарына бик сөенәм. Әнидән мактау сүзләре ишетү күңелләргә май булып ята.

Гөлфәния әнигә хөрмәтем бик зур, минем өчен ул һәрвакыт үрнәк хатын булачак. Гомере буе хезмәттә булган, өч бала үстергән, кайнана-кайнатага хезмәт иткән, авыр сынаулар аша үткән. Әле нинди абруйлы ирнең хатыны бит ул! Җәлил әти дәрәҗәсендә әнинең дә өлеше бик зур. Руслар әйтмешли, «за каждым великим Мужчиной стоит великая Женщина!»

Киленнәр һәм кайнаналар турында сүз чыккач, гадәтенчә, Җәлил хәзрәт тә бер кызык хәл сөйләп, көлдереп алды. Мәзәк итеп сөйләсә дә, аңлаганнарга зур мәгънә бар иде аның сүзләрендә.

– Безнең авылдан Фазлыйәхмәт абзыйга әтисе зарлана икән: «Анаң белән килен тыныша алмыйлар. Башка хатын табарсың, әллә киленне җибәрәсеңме?» «Әти, килен әле яшь кеше, яшь кешене үзгәртеп була, әнине инде үзгәртеп булмый. Бәлки, син үз хатыныңны җибәрерсең», – дигән Фазлыйәхмәт абзый. Шуның шикелле, яшь кешене үзгәртеп тә, тәрбияләп тә була.

Татарларда гомер-гомергә төпчек малай гаиләсе төп йортта калган. Безнең әти-әниләр дә шулай иде, без дә шулай яшәдек. Төп йортта калучы яшьләр булмаса, нигез ничек яшәсен?! Безнең әтиләр әле дүрт почмаклы өйдә дә торганнар, хәзер исә авылда өйләр иркен, һәркемнең үз бүлмәсе. Олы кеше кирәкмәгәнгә кысылып кына йөрмәсен. Менә анысы мөһим. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) бер хәдисе бар: «Үзеңә кирәкмәгәнгә кысылмау – мөселманлыкның иң зур билгесе».

Тормышта аңлашылмаучылык булмый тормый инде. Шуны истә тотарга кирәк: тавыш бер як гаебе белән генә чыкмый, бер кулны күпме генә болгасаң да, тавыш чыкмый. Тавыш өчен ике кул кирәк.

Җәлил хәзрәт белән Гөлфәния ханымның кызлары Айсылу гына шәһәрдә кияүдә, Булат һәм Алмазлары исә шушында – авылда яшәп калган. Алмаз белән Альбина да ике егет белән бер кызның әти-әнисе. Балаларына исемнәрнең иң матурларын сайлаганнар: Зәйнәп, Салих, Хәлим. Без килгәндә Зәйнәп белән Салих лагерьда иде. Бөрбаштагы бу дини лагерьнең даны шулай ук еракларга билгеле. Сүзебез әнә шулай җай гына балаларны һәм оныкларны тәрбияләүгә күчә.

Җәлил хәзрәт вәгазьләреннән: «Үзебездән соң безгә караганда да яхшырак берничә бала калдыру – һәркайсыбызның бурычы. Хакыйкатьтә, дөньяда чишәсе бер генә мәсьәлә бар, ул – яхшы тәрбияле бала үстерү. Бер генә һөнәр бар – әти-әни булу. Әгәр дә кешелек дөньясы үзенең әти-әни вазыйфасын җиренә җиткереп үтәп, бала тәрбияләү мәсьәләсен хәл итә алса, башка проблемалар үзеннән-үзе чишелеш юлын табачак. Нәсел яхшырсын, киңәйсен дисәк, гаиләдә, ким дигәндә, өч бала булырга тиеш».







– Әби белән әни бик кырыс булдылар. Кырыслыкта аларны да уздырдым бугай, өйдә гел тал чыбыгы торды, – ди Җәлил хәзрәт. – Үз балаларым булса, каты кысаларда тотмам диген идем дә, кысаларсыз гына тәрбияләп булмый икән.

– Безнең балаларны тәрбияләве кыен булмады. Әтиләреннән күреп, бик кечкенәдән дин өйрәнделәр, – дип, Гөлфәния ханым да сүзгә кушыла. – Оныкларны өйрәтеп тә торасы булмады. Хәлимебез әле сөйләшә дә белми иде, Коръән аятьләренә охшатып, үзенчә авазлар чыгара, имеш, дога укый. Азан әйткәнен күрсәгез! Сүзләрен белми, мәкамен, авазларын чып-чын итеп китерә.

Фазлыевлар гаиләсендә тәрбиягә кагылышлы төп кагыйдә – балаларга үзең үрнәк бул. Татарча белүләрен теләсәң – үзең алар белән татарча сөйләш.

– Без татар авылында яшибез, балалар татар бакчасына, татар мәктәбенә йөри, татар теле – төп аралашу теле. Алай да, телләре хәзер русчага күчәргә тора. Башка балалар кебек, безнекеләр дә русча мультфильмнар карый, телефондагы уеннарны да яраталар. Рус телен белмәгән бала хәзер татар авылында да юк, – ди Алмаз. – Кунакка кайткан балалар белән русча сөйләшкәннәрен ишетсәк, «татарча сөйләшәбез, яме, бу сүз татар телендә дә бар бит», дип, шул сүзнең татарчасын уйлап әйттерәбез. Үзләренә дә кызык булып китә.

Альбина Фазлыева блогыннан: «Тән биргән дә ана, сөт биргән дә ана, тел биргән дә ана, көй биргән дә ана». Безнең бөек татар телебез искиткеч бай! Бүген минем аналар һәм балалар турында язасым килә әле.

Безнең тәрбия эшендә иң төп система ул – ислам! Динебез тәрбия бирү өчен камил яратылган! Хәзерге заманның текә юнәлешле тәрбия системалары фанаты түгелмен. Үзебезчә, милли, дини тәрбия бирергә тырышам. «Прәннек һәм чыбыркы» алымы да күпмедер дәрәҗәдә булырга тиеш дип уйлыйм.

Минем бер алыштыргысыз ысулым бар. Безне үстергәндә әти-әнием кулланган кайбер алымнар миңа ошамыйча, тискәре йогынты белән күңелемә кереп калган булса, аларны кулланмаска тырышам! Шул гына!

Әниләр һәм бәбиләр темасында тагын бер борчыган момент бар: ул да булса балага тавыш күтәрү. Хәзер уйларсыз инде, Альбина балаларына бер дә тавыш күтәрми, ул камил әни, янәсе. Юк, әлбәттә, беребез дә идеаль түгел. Минем дә балаларны орышкан вакытларым була! Тик чит кешеләр янында алай эшләмәскә тырышам. «Кеше алдында мәчеңә дә тавыш күтәрмә!» – ди иде дәү әни».

Ике катлы таш йортның (Бөрбашта йортларның барысы да шундый матур, бик нурлы авыл ул!) аскы өлешендә бик зур китапханә.

– Бабалары Җәлил соңгы акчасына да балаларга китап күтәреп кайтырга мөмкин. Әкият китапларын күтәреп, хәзер тезеңә менеп утыралалар, – ди Гөлфәния әбиләре оныкларын шапылдатып сөя-сөя. Бу балаларның мәхәббәттә, яратуда коенып үскәннәре әллә каян күренеп тора шул. Әти-әни назына өстәп, әбиләренең дә әнә шулай йомшак кына баштан сөеп, иркәләп йокыдан уятулары, бабайларының акыллы киңәшләре, бәләкәй генә уңышлары өчен дә сөендереп биргән бүләкләре бик кирәк аларга. Бу җылылык гомерлеккә җаннарын җылытачак.

Авыл дигәч тә, үз хуҗалыкларында гына кайнийлар дип уйламагыз аларны. Шәһәрнекеләрнең төшенә дә кермәгән актив тормыш монда.

– Әбиләребезнең аулак өйләргә, утырмаларга йөрүләрен кызыгып тыңлый идек бит. Аулак өйләр күңел ачу чарасы гына булмаган, кызлар анда кул эшләренә дә өйрәнгән, тәмле ризыклар әзерләгәннәр, – ди Альбина. – Аулак өйләрне заманга яраклаштырып үткәрәсе килү теләге бездә күптәннән иде инде.

Альбина Фазлыева блогыннан: «Районыбызның мәгариф бүлеге җитәкчесе Алия Юнысовна белән берлектә «Милли бизәк» дип аталган кичә оештырырга булдык. Әлеге чараның төп темасы – яшь буында милләтпәрвәрлек тәрбияләү. Милләтебезнең киләчәге үзебездән тора.

«Милли бизәк» кичәсенең программасы бик кызыклы һәм эчтәлекле булачак. Киемнәрне тасма белән милли стильдә бизәү, калфак ясау буенча мастер-класслар үткәреләчәк. Бала тәрбияләү, хатын-кызның гаиләдә һәм җәмгыятьтә урыны турында сөйләшәчәкбез. Әлеге кичәдә мин үзем кул эшләренең бүгенге көндә кыйммәте, һөнәрле булуның файдасы турында сөйләргә җыенам. Милләтебезнең киләчәген якты итәр өчен «Милли бизәк» кебек чаралар үткәрелү бик күркәм гамәл. Әлеге зур эшкә өлеш кертә алуым белән мин бәхетле».

...«Өч әйбер диндә юк, ләкин ул динне саклый: милли тел, милли кием һәм милли гореф-гадәт!» – дигән Шиһабетдин Мәрҗани. Минем геройларым тел, милләт бетә дип кайгырып түгел, телебез үссен, милләтебезнең киләчәге ышанычлы булсын дип кайгыртып яшәүчеләр. Үзләренең тормыш рәвешләре белән халкыбызның иң матур традицияләренә җан сулышы өрүче алар.

ВИДЕО









«МИШӘРЛӘРЕМ...»



– Син ничекләр түзгән булдың икән, анай! Вәгыйзәнең бу сүзләрне ачыргаланып әйткән мизгеленнән аларның тормышлары икегә бүленгән: Фәритле һәм Фәритсез чакка. Хәер, нигә аларныкы гына, барыбызныкы да. Тормышындагы һәр вакыйга белән социаль челтәрләр аша таныштырып баргангамы икән, ул үзе дә, аның гаиләсе дә безгә бик якын иде. Әнисе, хатыны, балалары, оныклары, хезмәттәшләре аша Фәрит туган авылы Урмайны, аның кешеләрен, Чуашстанда гомер итүче татарларыбызны, бу төбәкнең гореф-гадәтләрен, йолаларын, аш-суын, җыр-моңын, биюләрен бөтен дөньяга танытты. Якташларын бездән яраттырды, сокландырды, үрнәк алырга этәрде! Чуашстан татарлары турында бөтен дөньяга иң элек ул сөйләде. Үз төбәгенең генә түгел, Ульян, Нижгар, Мордовия мишәрләренең дә фольклорын өйрәнде, бөртекләп җыйды һәм сәхнәгә чыгарды – аларга яңа сулыш өрде. Ә аның тамашачы каршына барабан алып чыгуы – анысы үзе аерым бер тарих!

Фәрит Гыйбатдинов – Чуашстан татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе, Чуашстан Республикасының милли эшләр буенча совет әгъзасы, «Урмай-Зәлидә» төрки дөньяның традицион мәдәнияте халыкара фестивале директоры. Чуашстанның Комсомол районы сәнгать мәктәбе директоры иде. Иде... Күңел әле дә ышанмый. Татар халкының узган елгы иң зур югалтуларының берсе – ул... Фәрит кебек милләтпәрвәрләр татар дөньясында сирәк. Төбәкләрдәге татар оешмаларының абруе аерым шәхескә бәйле. Ә Фәрит Гыйбатдинов үз тирәсенә бөтен Чуашстан татарларын туплый алды. Бер йодрык итеп! Чуашстан хөкүмәте белән дә мөнәсәбәте әйбәт булды – республика җитәкчелеге Фәрит Абдулла улын хөрмәт итте, аның сүзенә колак салды, кирәк урында булышты: татарларга йөз белән борылды. Дан һәм дәрәҗә өчен эшләмәде Фәрит боларның берсен дә – мишәрләре өчен тырышты. Ул бу мәсьәләдә ихлас һәм риясыз иде: вакытын да, көчен дә җәлләмәде.

Әнисе өчен Фәрит – горурланырлык ул, хатыны өчен – таянырлык ир, балалары өчен олы йөрәкле ата була белде. Аларга килгән хәсрәтнең зурлыгын сөйләргә сүзләр җитми...

– Фәрит әткәсен бөтенләй белми. 3 яшьлек бала нәрсә хәтерләсен инде?! Кайнамның Казанда туганнары бик күп иде: зур кызымны алып шунда кунакка киткән чагы иде. Ул көнне иртән дүрт сарыкның өстен алдым – Фәрит миңа тотышып торды. Бик сабыр иде ул... Аннан икәү келәт алдына эшкә киттек. Яңгыр күп яуды – игеннәр мул булды ул елны. Кайткач, җәтрәк ашарга пешердем, өчәү бергә утырып ашадык. Абдулла кибеттә эшли иде, ул елларда кибетчеләр кара халат кияләр иде бит. «Чиста халат бир әле, товар алып кайттым, бушатырга барам», – ди. Ишектән чыкканда: «Мин киттем, Фәритне яхшы кара», – диде. Бәлки, ул аны болай гына әйткәндер, Фәрит еш кына урамда үзе генә дә уйный иде бит... Улымны ияртеп тагын келәт алдына эшкә киттем. Барып кына җиттек, артыбыздан бер малай эзләп килде: «Җиңги, җиңги, әйдә әле, Абдулла әзи чирләгән дип әйтәләр», – ди. «Ай Алла, ничек чирләсен, әле табын янныннан чыгып китте бит», – дим. Чирләгән кеше түгел иде – багана кебек бит... Яңа больница салганнар гына иде – Абдулланы шунда күтәреп кертеп яткызганнар. Берни белми, аңсыз... Аңарчы кан басымы күтәрелгәне булмады. Районнан врачны бик көттек, килеп җитмәде. Күз алдында үлде дә китте... 33 өч яшь иде. Ә миңа – 25. Өченче балага биш айлык авырлы... Үзем дә аңсыз ятканмын. Күпме вакыттыр, белмим... Бу ыгы-зыгы белән Фәритне күздән җуйганмын. Ә ул, ишегендә йозак икәнен дә күрмичә: «Атай, ач! Атай, ач әле!» – дип, кибет тирәли йөри икән. Аны апам табып күтәреп алып кайтты. Шулай ятим калдык...

Кайгының иксез-чиксезе бу, алты дистә ел узып та, онытыла алмый торганы – Минзәйнәп апаның күзләренә тагын мөлдерәп яшь тула. Итәктә берсе – 5, икенчесе – 3 яшьлек ике бала, өченчесе – йөрәк астында. Торыр җир юк – кайнана янында гомергә кала алмыйсың: кайнесенең башлы-күзле булыр чагы килеп җиткән...

Әмма тол калган Минзәйнәптә сабырлык та, тырышлык та, үҗәтлек тә җитәрлек булып чыга.

– Тәвәккәлләп тотындым... Братларым булышты: урман алдык, бура бураттык. Тукайлар ямьле генә ызба эшләп бирделәр. Ул өлгергәнче кайнам янында яшәдек. Бик яхшы тордык. Абдулла сентябрьдә үлде, Рушаниям 31 декабрьдә туды... Элек авылда тракторда күп акча эшлиләр иде бит. Фәриткә: «Әллә тракторга гына керәсеңме?» – дия идем. Аңлап бетермәгәнмен инде... Көлә иде: «Анай мине тракторга укытма келәде», – дип... 8 нче класстан соң, бер братыма ияртеп, сохоз-техникумга укырга җибәрдем. Чыгарып җибәрү бик авыр булды, солдатка озату – тагын да... Кайтуга авыл кешеләре белән шабашка китеп барды. 1 мең тәңкә акча алып кайтарып бирде. Карыйм, аягындагы ноские тишек. «Нигә яңаны алып кимәдең инде?» – дим. «Акчаны киметәсем килмәде», – ди...

Агрономга укып кайткан Фәриткә авылда эш булмый һәм аны... клуб мөдире итеп куялар. Җыр-бию исә – аның дөньясы! «Мәдәният өлкәсендә эшлисем килә», – дисә, әнисе риза булган булыр идеме әле? Ә монда тормыш барысын да үзе көйли.

Урмай – үзе бер дөнья, ә Фәрит аның күчәре, диләр иде. Халык та аның яратуына ярату белән җавап бирде.

Ата-ана сүзеннән чыгу юк урмайларда.

– Инде безнең малай үләнмә кели. Чү әле, Фәрит, бер сүз әйтим әле сиңа, дим. Синең эшкә юл өстендә генә Гарәф абзыйлар тора. Үзебез кебек кешеләр... Сабыр гына бер кыз бар аларда. Вәгыйзә исемле. Колхоз эшендә күргәнем бар. Күреп кара әле шуны, сүләп кара, дим... «Ярар», – диде. Аллаһның рәхмәте, насыйбы булган икән... Хәзер, Вәгыйзә, син сүлә!

39 ел бергә яшәгән кайнанасын бүлдермичә, сабыр гына тыңлап утырган Вәгыйзәгә дә сүзгә кушылырга чират җитте.

– Элек суга башняга йөри идек. Көянтә-чиләк күтәреп чыксам, каршыма Фәрит килә – клубтан кайта икән. «Вәгыйзә, бүген һинд киносы була, аннары танцы, килегез», – ди. Ә безнең урамнар клубка бик йөрми иде – атайлар яратмый. «Гомерегез үтә инде беркая да бармыйча», – ди бу миңа. «Ярар, синең кебек егет булыр әле», – дим шаяртып... Ул чакта авылда аулагөйләр була иде: Фәрит клубны ача да, үзе аулагөйгә китә. Без якын торгач, клубны бикләргә атайдан сорый иде. Икенче көнне иртән безгә клуб ачкычларын алырга керә. Шундый ояла идем аннан, бигрәк тә яланаяк чагым булса... Ә атай Фәритне бик ярата иде.

Аннан ул мине сүләшергә чакырып чыгарды. Кабакта сызыклар бар икән, шуларны күрсәтте дә: «Вәгыйзә, озак йөрмәбез, менә шушы сызыкны тутырабыз да, өйләнешербез. Югыйсә сәфәр ае керә», – ди. «Өч көн килеп кем үләнә инде?» – дим... Беркөнне абыйга ияреп индийский кино карарга клубка мин дә кердем. «Бер-ике сүз генә әйтәм», – дип, абыйдан сорап калды ул мине. Шул көнне иптәшләре белән элдереп алып та кайтты. Туй көнебездә миңа 19 тулды... Икенче көнне исә ул Казанга сессиягә чыгып китте. Мәдәният-сәнгать институтына читтән торып укырга кергән иде инде...

Бер-бер артлы балалар туа: Рәзинә, Динә, Фәнил. Вәгыйзә килгәч, алар яңа йорт өлгертергә керешәләр. Җиңел булмый, әлбәттә.

– Вәгыйзәмне килен кеше дия алмыйм. Үз оланнарым кебек ямьле, тәртипле булды. Олы кызым – Миннегөлем Урмайда тора, аның белән дә бик дуслар алар, серләре уртак. Гомердә дә кайнаналы-киленле тавыш чыгармадык. Безнең татулык Фәритемнән дә торгандыр. Ни булса да, икебез дә Фәриткә белгертмәдек. Ул безнең ара гел тигез булды дип белде. Ә мин алар арасы тигез булсын дип тырыштым... Нәрсә бүлик? Бары – бергә, югы уртак булды. Оланнарны үстергәндә үк Мәскәүдән әйбер ташып сата башлаган идем. Күршедәге бер ахирәтем белән йөрдек. Авыл җирендә нәрсә юк – шуны күтәреп ташыдык: кием-салым, яулык, калын шәлләр, пәрдәлекләр...

Фәрит чын татар булып яшәде, башкаларга үрнәк булды. Бу эшне хәзер аның рухы дәвам итә.



Чират торып нужармадык, кибет мөдирләре белән танышып, шулардан гына ала идек. Эшнең җиңеле булмады инде безгә: шабашта да йөрдем, пилорамда да эшләдем... Мин Мәскәүгә чыгып китсәм, Вәгыйзәгә әйбер сатарга кала иде. Кулы җиңел иде аның... Мин дә аңа гел нәрсәдер алып кайтам, берсәк күңелен күрәм. «Аны киеп кара, моны киеп кара», – дим...

Ә Фәрит... Фәрит башаягы белән эшкә чума. Озакламый аны район үзәгенә алалар – сәнгать мәктәбенә директор итеп куялар. Ул авылларда бу мәктәпнең филиалларын ачып җибәрә. «Мишәр» җыр һәм бию ансамблен оештыра. 25 ел дәвамында «Урмай моңы» татар яшьләре җыр фестивален үткәрә: меңләгән катнашучы Россиянең бөтен төбәкләреннән генә түгел, хәтта чит илләрдән дә килә. Тагын бер иҗади проекты – «ART-MADHIA» фольклор фестивале авыл бәйрәменнән регионара дәрәҗәгә күтәрелә. Ә 2013 елда нигез салынган «Урмай-Зәлидә»се төрки дөньяны берләштерә. Сәнгать аша шулай итеп бөтен дөньяга Чуашстан татарлары турында сөйли Фәрит.

– Бөтен күңеле, җаны белән эштә иде ул. Бер эшне эшләмә киләсә, төн дә йокламый иде. Без аны өй мәшәкатьләре белән бик борчымаска тырыштык. Эшенең авыр, җаваплы икәнен белә идек бит. Кирәк икән, аны көтеп тормыйча кышлык утынны анай белән үзебез алып, үзебез ярып, өеп үк куя идек. Алма вакытларында – бездә бәрәңгене «алма» диләр – Фәритсез булмый иде, билгеле. Безгә аның исән-сау булуы, эшләп йөрүе шатлык иде. Бик кадерле кеше иде ул өебездә...

Бездә дә төрле вакытлар булды... Тормыш бит. Китапханәдә эшләгән чагым. Район үзәгенә семинарга бардым шулай. Кайтырга чыккач, яныма бер хатын килеп басты. «Син бит Фәритнең хатыны буласың? Ничек яшисез? Ул сиңа акчасын кайтарамы?» – ди. Югалып калдым: «Без акчаны анайга кайтарып бирәбез», – дим. «Синең Фәритең Мәскәүдән килгән практикант кыз белән йөри бит. Бик чибәр кыз ул! Гел кыска кызыл күлмәк кия», – ди... Бөтен тәнем кинәт камырга әйләнде: ничек кайтып җиткәнемне дә белмәдем. Фәрит ул көнне дә өйгә соң кайтты.

Рәзинәгә озынрак күлмәк кигезгән идем. «Нигә бу кадәр озынны кигездең, кыскарагы юкмы соң?» – ди. Туры килүен кара син... Эчемне утка салган теге сүзне әйттем инде: «Фәрит, син шундый-шундый кыз белән йөрисең икән», – дим. Аптырап китте. «11 нче класс укучысы – олан гына бит ул», – ди. Аннан: «Вәгыйзә, мине рәнҗеткән өчен бу гөнаһны ничек җыеп бетерерсең? Икенче юлы, мондый сүзне әйтсәң дә, мин ашап туйгач кына әйт», – диде. Мин табынга утыруга әйткәнмендер инде. Клубка эшкә кучкәч аңладым – үзең теләмәсәң, сиңа берәү дә килеп асылынмый...

Гаиләсендә аңламасалар, бу кадәр эшләрне башкарып чыга алган булыр идеме икән Фәрит?

«Мишәр» ансамбле сәхнәләрдә куйган биюләр иң элек алар өендә туа. Урта ишекне яба да, бии дә бии Фәрит. Кичтән өйдә чарлаган күнегүләрне икенче көнне үзенең «артистларына» өйрәтә – укытучыларга, табибларга, шәфкать туташларына...

Сәхнә костюмнарсыз яши алмый. Кайдан алырга – бергәләп утырып уйлашалар. Авыл советы булышлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән, тукымалар эзләп, Мәскәүгә үк чыгып китә. Фабрикадан фабрикага йөреп арзанрагын табып алып кайта.

Баян юк, гармун юк, гармунчы юк... Күңелдән бөтен авылдашларын барлый – таба, сөйләшә, җайлый – ансамбльдә уйнарга күндерә. (Бүген белгечләр кытлыгының ни икәнен инде белмиләр – һәркайда Фәритнең шәкертләре эшли.)

Ә «Мишәр» белән иң беренче тапкыр Казанга концерт куярга бару?! Зур сәхнәгә чыгу һәр күңелгә канат куясын белә бит ул – шуңа тырыша.

Балаларны ансамбльгә тарту өчен ниләр генә уйлап тапмый: аларны әле Казан, әле Мәскәү күрергә алып чыгып китә. Мәскәүдә яшәүче сеңлесе Рушаниянең ул чактагы бер бүлмәле фатирына бер автобус бала белән кунарга барып керүен әле дә көлеп сөйлиләр. Сыялар!

«Урмай моң»ына килгән катнашучылар кайда кунган дип уйлыйсыз? Урмайда кунакханәләр юк – бер кичкә Фәритнең үз өе дә, барлык туганнарының, авылдашларының өйләре дә «кунакханәгә» әйләнгән.

Казаннан Чуашстанга кем, нинди эш белән килсә дә, моңа кадәр гел иң элек Гыйбатдиновларда тукталды: журналистлар, җырчылар, тарихчылар... Фәритнең Вәгыйзәгә: «Иртәгә безгә шундый-шундый кунаклар килә», – дип кайтып әйтүе җиткән: табын әзерләнгән, мунча ягылган. Тәүлекнең кайсы вакытында килеп керсәләр дә!

– Рәхмәт Фәриткә – дөнья күрсәтте. Миңа гына түгел, бөтен авылдашларга. Ансамбльгә йөрүче оланнарны Төр-

киягә кадәр алып барды. Бала-чага белән юлда йөрүнең җаваплылыгын күз алдына китерәсез инде. Кайтканда аэропортта самолетны көтеп утырабыз. Берзаман: «Сезнең очкыч китте», – диләр... Нәрсә булды, аңламадык: самолет киткән, ә багажларыбыз калган. «Сезгә Мәскәү аша билет бирәбез», – диләр. Дәртләнгән идек ул юлы. Фәрит ничек түзгәндер авыру йөрәк белән...

Кырымны да күрсәтте ул «Мишәр»ләргә. Узган ел җәй ансамбльнең өлкәннәрен Кабарда-Балкарга алып барырга тиеш иде, анысы менә насыйп булмады...

Без бик матур яшәдек – ул яктан үкенечләр юк. Ул миңа һәммә нәрсәне үзе алып киертте. Кая барса да бүләксез кайтмады. Оланнарны бик яратты. Бездә балаларга кычкыру гадәте беркайчан булмады. Аларга Фәритнең күз карашы җитә иде. «Ярар», – диләр дә, үз бүлмәләренә кереп китәләр, бу хакта башка сүз кузгатмыйлар. Курку түгел, әтиләрен хөрмәт итү иде бу. Ул кайтмыйча, ишектән кермичә беркайчан аш бүлмәдек: аерым-аерым ашау гадәте юк иде бездә. Оныкларга куанып яшәде. Рәзинәнең улы Җамалның татарча сүләшүенә кинәнә иде. «Казан малае бит, ә татарчасы ничек әйбәт!» – дия иде. Фәнилнең улы Җәбраил тугач сөенеп бетә алмады. «Ул бит Гыйбатдинов!» – дип куанды. Бабасыннан 1 яшьлек булып калган шул нарасый әле дә аны онытмый – кайткан саен бүлмәләрдән эзли... Динәнең Сәете белән дә бик якыннар иде: үз хәле авыр булса да, Чабаксардан – больницадан шалтыратып та гел аны сорады... Кыз туганнарын бик якын күрде. Миңнегөл әптинең туган көненә чәчәк тотып бармыйча калганын хәтерләмим... Ә алар Фәрит белән, аның халык арасындагы дәрәҗәсе белән горурландылар... Шундый ир белән гомер иткәнемә бик бәхетлемен. Ул минем өчен туган булгандыр, мәңге бәхил, урыны җәннәттә булсын...

Йөрәк белән яшәде инде ул безнең. Берәүгә дә авыр сүз әйтмәскә тырышты, бөтенесен тигезләмә келәде. Байлык артыннан кумадык, булганына канәгатьләндек. Безнең сөенечләр башка иде... Ахирәтләре арасында хуҗалык җитәкчеләре дә байтак булды. Әмма ул алардан сыңар капчык иген дә сорамады. Ә «Мишәр» өчен сорый иде! Кырыгыннан соң мәктәбенә 3 миллион грант килде менә. Күпме чапты шул акча артыннан?! Төннәр буе документлары белән утырды: үзе бухгалтер, үзе юрист, үзе оештыручы булган... Ул китүгә акча да күчте, моңарчы мәктәптә булмаган кыйммәтле яңа уен кораллары да кайта башлады: думбра, балалайка... Берсен дә күрми китте...

Әңгәмәбез кабат өзелә. Тагын күз яшьләре... Минзәйнәп апа: «Торган саен хәсрәт зурая гына бара. Аллаһым безгә сабырлыклар бирсә иде», – ди.

Өмет тулы соңгы ике атна бар әле... «Ашыгыч ярдәм» Чабаксарга алып киткәч, башта өч көн хәлләрен язып тора ул. «Үпкәләрнең берсе – 35, икенчесе 45 процентка зарарланган, диләр. Анайга әйтегез әле, укысын, үзе сулый башласын, дип сорасын», – ди. Минзәйнәп апа бер якта ялвара, Вәгыйзә – икенче якта... Бер-бер артлы ике инфаркт кичерде дигәч тә өметне өзми әле алар. Ун ел элек булганы белән санасаң – өченче йөрәк өянәге. Ике атнадан соң иртәнге җидедә телефон шалтырый: «Фәрит Гыйбатдиновның хатыны буласызмы? Сезгә авыр хәбәр бар...» Вәгыйзә икенче бүлмәдә намазлыгы өстендә утырган кайнанасы янына чыга: «Син ул чакта ничек түзгән идең, анай?!» Барысы да томан эчендә кебек булгангадыр – хатирәләр өзек-өзек... Кәфенләп, мөселманча гүргә иңдерү бәхет булып тоела – монысын дуслары оештыра. Бу авыр көннәрдә Фәритнең һәр дусты олы бер терәккә әйләнә... Улын озатып, зиратка кадәр үзе атлап барган 84 яшьлек Минзәйнәп апа икенче көннең таңында гына елый ала... Иң зур юаныч – төшләр. Соңгысында Вәгыйзәгә: «Мин хаҗ кылган якка киттем», – дигән.

Хаҗ кылган якка... Бу изге җирләрне ике ел элек барып күрде ул. Җомга саен Фейсбукта: «Киттек әле... Безне мәчетләрдә көтәләр!» – дип яза башлады. Фәритнең әнә шул «көтәләр»ен укып кына да, мәчет ишеген ачып керүчеләр шактый булгандыр кебек тоела миңа... Үз артыннан ияртә белә иде ул!

Гөлнур САФИУЛЛИНА.
Казан–Урмай–Казан.



Фотолар: гаилә архивыннан

PRESSA



Гөлсәрия – Пермь якларыннан, Барда кызы. Әдәбиятны яратуы, иҗатка тартылуы аны Казанга алып килә. Тынгысыз күңеле университетның журналистика бүлеген сайлый. Хис-кичерешләргә бай нәзберек җаны исә гел шигъри дулкында тирбәлә. Шул елларда студент кызның шигырьләре Илдар Юзеев фатихасы белән «Азат хатын» битләрендә урын ала... Чаллыда яшәп иҗат итүче Гөлсәрия Басыйрова бүген дә укучыларын моң, сагыну, ярату тулы шигырьләре белән сөендерә.

Гөлсәрия БАСЫЙРОВА

ЯРАТУЫМ... САГЫНУЫМ... САГЫШЛАРЫМ...

Төсле сагыш

Мин синең язларга
ел саен кайтырмын –
ничек тә күзләрне алдармын.
Беренче тын алып,
сөенеп балкыган
чәчәге булырмын язларның.

Күз явын алырдай
сап-сары болында
карашны оялтып нур уйнар.
Һәр сары чәчәкнең
үзәкне өзәрдәй
мин булып багуын кем уйлар?..

Икебез яраткан
сап-сары төс булып
хисләрем болынга агылгач,
Бу аның төсе, дип
барыбер танырсың,
исеңә төшереп сагынгач...

***

Синең белән бер биисем килә,
Күзләр чиккән сары келәмдә.
Бию көе – яфрак кыштырдавы,
Күзләр җыры бары... белөм дә.
Мин оялып кына биер идем,
Сулышыңны тоеп йөземдә.
Карашымны яшереп, утлар булып
Кабынып идем, ахры, үзем дә.
Очып-атлап әйләнгәндә берүк
Аягымны җиргә тидермә...
...Алтын көзнең хыял аланына
Чакыр әле мине биергә.

Танго

Мин бүген ашкынып биедем,
Хисләнеп биедем тангоны.
Бу бию – ярату турында,
Бу бию – икәүнең җан моңы.

Син дә бит күземә карадың,
Аңладың күңелдә ни барын.
Дәртле дә, моңлы да бу көйне
Кабатлар йөрәгем гел тагын.

Бу бию – әйтерсең өермә,
Без аның нәкъ менә түрендә.
Йөрәкләр кушылды биюдә...
Мин танго биедем бүген дә...

Күңел күбәләкләрем

Күңел күбәләкләремнең
Төсләре төрле-төрле.
Берсе – ак, икенчесе – ал,
Берсе – зәңгәр төсмерле.
Берсе – моңым, берсе – җырым,
Өченчесе – сагышым,
Тагын берсе – сагынуым,
Моңайганы – ялгышым.
Ялгышым булса да якын –
Яраткан күбәләгем.
Моңайма юкка, сине бит
Назыма күмәләмен.
Сөенеч – серле канатлы,
Куна һәрбер таңыма.
Барысын да озатыймчы
Мине сөйгән җаныңа.

***

Сагынасыңмы?
Ә мин сагынам...
Бик сагынсаң әнә күккә кара.
Бер йолдызкай балкыган да анда,
Сиңа таба якты нуры бара.
Мин көнләшеп карап торам аңа.
Сагынасыңмы?
Ә мин сагынам...
Арабызга Аем күпер сала.
Иярәм дә тизрәк, сиңа барам!
Йолдыз кызый, үпкәләгән сыман,
Көнләшепләр, ахры, карап кала...

***

Чәчләремә кушып үрдем
Әбиемнең чулпысын.
Иңнәремә шәлен салдым,
Иң матурын – чуклысын.
Көмеш тәңкә аваз бирә
Бер-берсенә кагылып.
Чулпы җыры ишетелә
Җаннарыма сарылып.
Әбиемнең чулпылары
Нигә һаман җырлы соң?
Аркамнан сөяләр сыман –

Тоям кулы җылысын.
Челтәр шәлдә истәлеккә
Аның күркәм төсе бар.
Мәңге күңелдә сакланган
Иркәләгән хисе бар.
...Чулпым да юк, шәлем дә юк
Иңнәремә салырлык.
Бездән ниләр калыр икән
Ядкарь итеп алырлык...

***

Иртә язда умырзая
Азга гына балкып ала.
Тик җырларда җырланырлык
Матурлыгы истә кала.
Умырзая, умырзая,
Гомерләр бит үтеп бара.
Ни кызганыч, яздан көзгә
Бигрәкләр дә йөгерек ара.

Сөюнең үзе кебек син –
Сафлык төсе ап-ак таҗың.
Баш калкытып уянасың,
Тоеп җанда Язның назын.
Умырзая, умырзая,
Гомерләр бит үтеп бара.
Нигә шулай яздан көзгә
Бу чаклы да кыска ара?!

***

Мин бит сине һаман көнлим әле...
Ә син, ахры, бер дә көнләмисең.
Сары көнбагышым, дия идең,
Әллә инде аңа тиңләмисең?

Көнбагарның хәлен аңлыйм хәзер,
Ул кояшны күрми түзалмаган.
Карашлары белән гел озаткан,
Алларына чыгып узалмаган.

Бармы җирдә кояш көтмәгән гөл?
Юктыр, юктыр. Булса да бик сирәк.
Көнбагышың булып калыр өчен,
Миңа да бит Синең нурың кирәк...

***

Сары чәчле бәләкәч кыз,
Мин бит сине таныйм, җаным!
Чәчләреңнән сөйим әле,
Син бит минем нәни чагым.
Чәчәкле матур болында
Мин үзем бер гөл идем.
Иң матурын сайлап кына
Такыялар үреп кидем.
Сары гөлләр арасында
Иң моңлысы мин идемме?
Әллә, моңлы бала булып,
Язмышыма баш идемме?
Сары чәчле нәни кызкай,
Моңлылар җирдә азмы соң...
Күрәсеңдер еллар аша –
Бәхетле булды язмышым.
Сагынам сине, сагынам,
Гөлләр исе – толымыңда.
Җитәкләшеп йөрик әле
Балачагым болынында.

***

Кайчан гына ап-ак таҗлы
Ромашкадан күлмәк кидем.
Чәчәкләрдән такыя үрдем.
Мин – Җәй идем.

Сәйләннәрем хәзер – миләш,
Төсләремә сары иңде.
Күлмәгем дә алтын сыман.
Мин – Көз инде...

Һәрбер елым минем сәйлән.
Сәйләннәрем бәйләм-бәйләм.
Гомеремнең һәр мизгеле
Минем өчен гүя бәйрәм..

***

Барысы да үзгә минем – тик үземчә:
Яратуым,
Сагынуым,
Сагышларым.
Җырларым да үзем кебек сәер генә,
Сөю җырын сайлап
бер дә ялгышмадым.

Аны күпме җырласаң да туеп
булмый:
Үсендерә,
Ашкындыра,
Алгысыта.
Бер карасаң – йөрәгемне моңга төрә,
Бер карасаң – өмет биреп,
гел ярсыта.

Тик үземчә...
Мин башкача була алмыйм:
Ачык күңел,
Ялган түгел –
Җырлы бүген.
Кояш эзләп баккан
нәүмиз күңелемнең
Болыт кына капламасын зәңгәр күген.

***

Җаным тынган вакытлар бар,
Ташлап уйлар бәйләмен,
Андый чакта бизәк чигәм,
Төсле җепкә әйләнеп.
Уем белән бизәк чигәм,
Бизим сәйләннәр белән.
Җәйге болын кебек матур
Күңелдә чиккән келәм.
Нинди хыялый инде бу,
Дигәннәр бардыр, беләм.
Хисләремне чигә сыман
Алтын җепле уй-энәм...

***

Төн... Урам... Бар дөнья йокыда.
Җил уйный бары тик буранлап.
Күңелем нәрсәдер көткәнгә,
Күземне алалмыйм урамнан.

Ни көтәм? Буранда адашкан
Сөюем табылыр кебекме?
Йөгәнләп булмаган уйларны
Тыймыйм да. Алар бит иректә.

Ярсуны басарга теләпме –
Төн гизәм, ияреп үзем дә.
Җил... Буран тынгысыз җанымда...
Яшь булып кар эри йөземдә.

Барыбер табар идем

Чишмә булсам, аның кебек
Гел җырлап агар идем.
Сиңа илтәсе юлларны
Барыбер табар идем.

Төнге күктә йолдыз булсаң –
Гел күккә багар идем.
Нурыңнан синең яктыны
Барыбер табар идем.

Кышның бозы булсам да мин,
Барыбер янар идем.
Сине дә яндырыр өчен
Әмәлләр табар идем.

***

Яшь кәләшнең нәфислеге төсле,
Ак бөркәнчек аша күренгән...
Беренче кар җиргә төшә шулай –
Дөнья әнә акка төренгән.

Матурлыгы аның җанны сафлый,
Оныттырып көзге сагышны.
Күңел бит ул шуңа көтеп ала
Бураннары белән ак кышны.

Ярсулары аның басыла да,
Сабырлыгы арта әзрәк.
Янар өчен тагын Язны көтә,
Сөяр өчен аңа Яз кирәк!



Уфада яшәп иҗат итүче язучы Дилә Булгакова хикәяләрендә нечкә хис, драматик лиризм өстенлек итә, геройның иң тирән күңел кичерешләре ачыла. Укучылар аның шигырьләрен, нәсерләрен, балалар өчен язылган әкиятләрен дә яратып кабул итә. Ә аның шигырьләренә язылган «Кыр казлары», «Сагынам», «Үпкәләмә» кебек җырлары халык арасында бик популяр.



Дилә БУЛГАКОВА

БҮЛӘК

(Хикәя)

Кечкенә генә өйдә яшәп, гомер йомгагын сүткән Бибисара әбинең юанычы да, куанычы да – бер песие бар. Һәр туган яңа таңын да намазын укып, догалары белән каршы ала, Ходайның биргәненә шөкер кылып яши карчык. Аның бер генә туганы да, кан кардәшләре дә булмады.

Шәһәр читендә онытылып барган берничә өй бар. Кычытканнар, уймак-уймак камышлар, черек-җимерек киртәләр яныннан тар гына кәҗә сукмагы Бибисараның песиле өенә алып бара.

Бибисара гомер буе ятимлектә, ятимнәр йортында үсте. Аның кайсы яктан, кайсы авылдан, кемнең газиз кызчыгы икәнен беркем дә белмәде. Балалар йортындагы тәрбияче апасы сөйләгәннәр генә истә: «Үскәнем, башкалар кебек әнкәңне, туганнарыңны эзләмә, чөнки монда кайсы төбәктән килгәнеңне беркем дә белми. Сине поезд вагоныннан алып безнең балалар йортына тапшырган кеше олы яшьтәге ир-ат иде. Ул ашыга-ашыга: «Бу баланың авылы – сиртмәле коеларына кадәр утырып янды, документлары да юк. Менә бер язу-кәгазь бар, бәлки, шуның белән урнаштырырсыз тере ятимне. Сездән дә рәхимле, саваплы кеше булмас, түземле балага охшаган, ә исеме-фамилиясе сезнең кулда, менә бу язуда», – дип, сине – озын чәчле кызчыкны калдырып киткәне әле дә истә... Син шундый ябык идең, сәләмә генә киенсәң дә, ач булсаң да, еламадың, барына риза булып: «Рәхмәт сезгә, апалар», – дип кенә башың иеп торганың истә. Шуна күрә «Рәхмәт кызы» дип кушамат та такканнар иде...»

Ул оялчан, тырыш, акыллы кыз булып үсте, ләкин ничек кенә кечкенә чагын хәтерләргә теләсә дә, исенә төшерә алмады. Тырышып укыды. Күңел түрендә исә нигәдер бер өмет яшәде, зур хыялы ташлап китмәде: «Бәлки, минем әнием дә исәндер. Аның исеме ничек икән, матурдыр инде, кайларда яши икән ул? Әнием, әтием! Минем барлыгымны белә микән алар?»

Гомере буе Бибисарага йөрәк өзгеч шул сорау тынгы бирмәде. Үсеп җиткәч, балалар йортының директоры бу тырыш кызны кызганыпмы, әллә аның зирәк, зиһенле, сабыр булуын күзәтепме – ярдәм кулы сузды. Укуын тәмамлагач, кече төркемгә тәрбияче итеп калдырды. Ләкин бу көннәр озакка сузылмады...

Узганнәрен хәтерләп утырган Бибисара сискәнеп китте: «Бәй, иртәнге намазга соңлый язганмын, тәүбә, тәүбә!»

Тәһарәтләнеп пакьләнгәч, намазлыгына басты: «Аллаһы Тәгаләмә шөкер, өлгердем, өлгердем», – дип, сабыйларча куанды. Намазын укып, догаларын кылгач, тартмада ике баласын имезеп яткан песинең савытына сөт салды.

– Песекәем, синең йомшак йомгакларың үсеп беткәннәр инде, җылы сөт тә ялый башладылар, рәхмәт төшкерләре. Нишләргә соң? Миңа яңа торак бирәбез дип хәбәр иттеләр. Син миңа рәнҗемә инде, ике генә бөртек балаңны изге кешеләр кулына тапшырырмын, – дип, әниләрен имеп яткан песи балаларын калтыранган куллары белән сөя-сөя, кичтән әзерләп куйган кәрзиненә – челтәрләнеп беткән иске мамык шәленә салды да шәһәргә юнәлде...

Базарга килеп кергәндә, эт, мәче, читлек кошлары сатучылар үз урыннарына җыелган иде инде... Бибисара карчык кыяр-кыймас кына бер якка барып басты, кәрзинен җиргә куйды, ә песи балалары кәрзин читенә тәпиләре белән ябышып: «Без кайда, әниебез кайда соң?» – дип, әче тавыш белән елашты. Карчыкның кулына йомшак тәпиләре белән үрелеп, ялап та алдылар.

– Курыкмагыз инде шултиклем, курыкмагыз, азрак сабыр итегезче, йоклап та алыгыз, – дип, әби кәрзиннең өстенә шәлен ябып куйды. Шунда этләр карап йөргән бер малай килеп:

– Әби, бер песине миңа бир әле, мин песиләр яратам, – дигәч, Бибисара тураебрак басты. Баштанаяк карагач:

– Бәй, улым, син аны карый алырсыңмы соң? Җәберләмәссеңме? Әнкәң рөхсәт итәрме соң? – дип, малайга сораулар яудырды. Ә үзе эченнән генә: «Рәхмәт төшкере, бу бала акыллыга охшаган, бәлки, яхшы карар...» – дип уйлады. Аннан соң:

– Улыкаем, мин сиңа ышанам, сайлап ал – күңелеңә кайсы ошый, – диде. Малай шатланып:

– Кәрзиннән кайсысы башта карый, шунысы минеке була, – диде.

Ак туфлиле кара песи баласы үрелүе булды: «Вәт менә монысы – минеке! – дип, песи баласын күкрәгенә алып кысты.

Ә песи баласы ят кулда, калтыранып, үзенчә пырхылдады да, елап ярдәм сорагандай тырмашып, малайның кулбашына менәргә маташа башлады. Малай катып беткән куллары белән песинең нәни генә тәпиләрен күлмәгеннән ычкындыргач:

– Әбекәй, бер сумым гына бар, – дип, акча сузды.

Бибисара елмаеп:

– Улыкаем, мин бит песи балаларын сатмыйм, бүләк итеп кенә бирәм. Аны җәберләмичә ашат, ул сөт ялый белә, – дип, малайның кулындагы бәләкәчне сөеп куйды. Карчык үзе күпмедер акчасын алып малайга сузды:

– Мә, улым, анда юлда ливер колбасасы сатып алырсың, яме. Аның исеме – Бүләк, үзем куштым. Балам, бу шәлем, иске булса да, җылы ул. Мә, аны шул шәлгә төреп, кәрзингә салып ал, – дип малайга бирде.

Малай, рәхмәт әйтеп, күз ачып йомганчы шау-шулы базар эченә кереп тә югалды.

Ә карчык сыкранып, уйланып калды. Ярдәм сорап елаган икенче песи баласыннан гафу үтенгәндәй:

– И ачыккансыңдыр инде, әниеңне эзлисеңдер. Ялгыз калдың шул, бәләкәч, тынычлан, – дип сөйләнде. Карчык янына яшь, чибәр бер кыз тукталды:

– Бәй, бигрәк бәләкәч бит, күк йомгак! Әби, кочагыңдагы шул күк йомгагыңны миңа бирәсеңме? Калтыранма, хәзер безгә кайтабыз, тәмлекәйләр белән сыйлармын, – дип, песи баласын кечкенә кызыл танавыннан үбеп алды. Аннары сумкасыннан акча алып әбигә сузды. Йокысыннан уянып киткәндәй, әби:

– Юк, балакаем, песи балаларын сатмыйм, тиздән фатир алам, миңа иптәшкә аларның әнисе бар, – диде.

Кыз исә:

– Ярый, әбекәй, дога кыларсың, бу сиңа хәер, – дип, акчаны Бибисараның кесәсенә салды да күк йомгагы белән сөйләшә-сөйләшә китеп барды.

...«Песекәем, мескенкәем ни дияр соң?» – дип, әкрен генә гаепле кешедәй тупсасыннан атлап керде ул. Өй эче тып-тын, тик песие генә карлыккан тавышы белән ара-тирә балаларын чакыра...

Бибисара үзен гаепле сизсә дә: «Алар рәхәттә яшәячәк, яхшы кешеләрнең кулына тапшырдым бит», – дип, үз-үзен юатты, песиен кулына алып сөйде, сыйламакчы һәм юатмакчы булды. Тик песи хуҗабикәсе салган ризыкка кагылмады. Елый-елый, әле карават астына, әле мич артына йөгереп, балаларын эзләде. Ишек кырына барып, чыгарга сорагач, әби үрсәләнгән песиенә ишеген ачты. Песи атылып чыгып китте. Бибисара тынлыкка төренгән өендә сыкранды, өзгәләнде. Бичара песи өй тирәли елый-елый балаларын эзләде. Карлыккан тавыш белән ярдәм сорап, ике көннән соң ишекне тырнады. Ябыгып, тартышып беткән песекәй ишекне ачуга атылып йөгереп керде дә балалары яткан тартманы иснәнде дә иснәнде...

– Җитәр инде, юләркәем, тынычлан, – дип, карчык песиен күкрәгенә кысты. Ни күзләре белән күрсен: песинең түшенә сөт төшеп, туң бәрәңгедәй катып шешкән... Ни эшләргә дә белмәгән карчык шүрлектә эленеп торган батист яулыгын алып, песинең күкрәген кысып бәйләп куйды. Аны сабыйдай кочаклап, җылы урынына барып ятты да азрак йокымсырап китте. Йә Ходай, әйтерсең лә үзенең күкрәкләренә дә тулышып сөт төшкән: сыкрап, чәнчеп-чәнчеп авырталар. Уянса, бер кулы белән песиен кочаклаган, икенче кулы белән үзенең түшләрен тотып карый да гаҗәпкә кала – шундый тулышкан алар. Аның күкрәкләренә бит беркайчан да сөт төшкәне булмады. Үсмер чагында асрау кыз булып тормышлары җитеш кешеләрдә хезмәт итте, аларның кызларын үстерде. Ә инде олыгайгач, аңа шул кечкенә агач өйне сатып алып бирделәр һәм үзе йоклап йөргән пружиналы караватны, тормыш кирәк-яраклары калдырып, рәхмәтләр әйтеп, бары тик хуҗабикәнең каберен карарга, тәрбияләргә вәгъдә алып, ул белмәгән-ишетмәгән якка чыгып киттеләр...

Песинең түшләре уттай яна. «Әй Раббым, бу мәхлуккаемның балаларының язмышы ничек булыр соң?» – дип уйланып, тагын моңсуланды Бибисара.

Песи балаларының да язмышы төрле булды шул.

Малай, шәһәр читендә үги әнисе белән яшәгән бер бүлмәле фатирга шатлана-шатлана песи баласы белән



кайтып керде. Үзе белән сөт, ливер колбасасы, мәкле йомшак күмәч алган иде. Песи күтәргән малайның шатлыгы кинәт кенә юкка чыкты. Шул арада әнисе эчкән, исереп тә өлгергән. Тамагына аннан-моннан капкалап, малай йокларга ята.

Менә ул тиздән мәк-тәпкә барырга тиеш, ә әни кеше гел тирги, кимсетә, кыйнап та ташлый. Ачуы килгәндә, ак туфлиле песине дә тәрәзә төбеннән бәреп төшерә.

Малайның кагылып-сугылып, ач яшәгәнен күреп, күршеләре бик кызгана. Җыелып сөйләшеп, аны ятимнәр йортына урнаштырырга булалар.

Башта малай бер дә китәргә теләми, елый. Икенче көнне генә ризалаша. Үзенең Бүләк исемле песи баласын да алып китә...

Ә икенче песи баласы барысына караганда да бәхетлерәк була – тәмле-тәмле ризыклар гына ашап, йомшак мендәр өстендә үсә. Аны иркәлиләр, ефәк тасмалар тагып, фотоларга төшерәләр...

Менә бер көнне Бибисара карчыкның өеннән ерак түгел кранлы тракторлар күренде. Аннары бер ак машина якынрак килеп туктап, аннан бер ир-егет чыкты да Бибисараның өенә юнәлде. Ишегалдына чыгып баскан карчыкка:

– Әбекәй, сиңа күчәргә туры килер. Әнә шәһәр читеннән ерак түгел йортның беренче катындагы бүлмә – якты, ремонт ясалган. Синең өең искергән инде, сүтәргә килдек, әбекәй! Бу урында яңа өйләр төзиячәкбез, тиз көндә әйберләреңне җыеп күчен, яме. Син берүзең генәме әллә? – дип сорады.

– Юк, юк, улым, без – икәү, песекәем белән күчәбез, – диде Бибисара карчык.

– Ярар. Машина бирербез, күченергә дә ярдәм итәрбез, әбекәй, кайгырма, – дип, әбинең аркасыннан сөеп куйды.

Ике көннән соң әбинең өе янына машина килеп туктады. Төн йокламыйча, әбекәй булган кием-салымын төйнәп куйды. Иртә белән зиратка барып, догалар укып кайткан иде инде. Ике хатын, бер ир кереп, әйберләрен машинага төяргә ярдәм итте. Тик песиен генә таба алмады. Сөлгегә ураган Коръәнен, намазлыгын кочаклап, машина эченә кереп утырды, машина кузгалып китте. Йорты күздән югалганчы әби песиен күзләде, тик ул күренмәде.

Бибисара карчыкка ярдәм иткән бер кыз: «Менә, ичмаса, үзебезнең мөселман кешеләре! Һәрвакыт җыйнак, чисталар. Әбиебез ташландык өйдә ничегрәк яшәп яткан бит: идәннәре кырып юылган, бер җирдә тузан тапмассың, молодец, әбекәем», – дип, карчыкның аркасыннан кагып та куйды. Биш катлы йорт алдына килеп туктадылар. Карчык өйгә кереп, тирә-якка күз ташлап алгач: «Әлхәмдүлилләһ, минем догаларымны Аллаһы Тәгалә кабул иткән», – дип түрдән узды. Тимер караватын урнаштырып, түгәрәк өстәлнең башта өстен, аннары аякларын кертеп утырткач, юып үтүкләгән ак ашъяулыгын җәеп куйгач, өе ямьләнеп, нурланып китте. Бибисара пешергән кабартмаларын өстәленә чыгарып куйды да:

– Йә, уңган кызлар, беренче тапкыр кергән өйдән чәй эчмичә чыкмыйлар, рәхмәт, балакайларым, әйдәгез, аш пешерү бүлмәсенә, шунда танышырбыз, – диде.

Гөрләшеп чәй эчкәч, әбекәйнең эченә җылы йөгерде. Кызлар чыгып киткәч тә, Бибисара, йорт эченә сокланып, карап чыкты. Барысы да әйбәт, тик дусты, песие генә җитми иде аңа. Бибисараның бар уе – песиен табып, яңа фатирына күрше тирәсен җыеп, Коръән уку мәҗлесе үткәрү иде. Ул әкрен генә әйберләрен урнаштырды, өен җыештырды, тәрәзәләрен сөртте.

Икенче көнне ак челтәр пәрдәләрен элеп куйды да, өстен-башын алыштырып, кибеткә барып кайтты. Токмачын кисеп, киптерергә куйды, табаларын чистартты. «Тәмле гөбәдия пешерермен. Хәзер тәрәзәмне әзрәк ачып торыйм, яңа буяу исе килә шул», – дип, тәрәзәсен ачты. Өй каршында әбиләр, берничә хатынкыз утыра иде. «Менә болар минем яңа күршеләремдер. Йә Ходаем, яхшы гына адәмнәр белән таныштыр. Безгә бергә гомер итәсе» – дип уйлап, ихатага чыгуы булды:

– Нихәл, яңа күрше? Сине күптән көтәбез, танышыйк әле, әйдә, кил, утыр. Без менә шулай җыелышып гөрләшәбез, ашларга йөрешәбез, – дип, Бибисараны чакырып утырттылар.

Урта яшьләрдәге таза гына хатын:

– Исемегез ничек була? – дип сорады.

– Бибисара булам, – дигәч, теге хатын янә:

– Кемнәр белән күчеп килдең? – дип кызыксынды.

Бибисара азрак каушабрак калды:

– Кемнәр белән дип инде... таянып яшәгән бер Аллаһым гына булды гомерем буена. Мин ятимнәр йортында үстем. Иске өемдә песекәем бар иде, тик күченгәндә таба алмадым шул. Менә урнашып беткәч тә барып алам, Аллаһы боерса, ул көтәдер инде, эзлидер мине, – диде.

Шунда утырган хатыннарның берсе:

– Песи – иптәш ул, менә син күченгән фатирыңда да бер малай песие белән яшәде. Үги әнисе эчте, малайны җәберләде, шуңа үзе дә игелек күрмәде. Соңгы тапкырында бөтенләйгә психушкага озаттылар, диделәр. Күп атналар үтте инде. Ә теге тома ятимне песие белән балалар йортына юллап тапшырдык. Исән-сау яшәргә язсын, син күчкәнче управдом ремонт ясады, – диде.

Карчык калтыранып куйды да:

– Йә Ходаем! Ярдәмеңне бир, – дип сүзсез калды.

Бибисараның яңа күршеләре тагын әллә ниләр турында сөйләшсәләр дә, ул ишетмәде. Азрак утыргач:

– Ярый, таныштык, бик тә яхшы кешеләргә охшагансыз, барыгыз да җомга көнне ашка керегез. Ишегем ачык булыр, – дип, әллә нинди шомлы уйлар белән йөгерә-атлый өенә кереп китте.

Коръән ашыннан бик соң гына таралыштылар. Бибисара карчык көченнән килгәнчә табын әзерләгән иде. Яңа күршеләренең берсе – зур сөлге, берсе – чәй бирде; ипи, кульяулык, яңа парлы чынаяначлар алып керделәр.

Хуҗабикә үзе моңлы тавышы белән Коръән сүрәләрен укыды, дога кылды. Укымышлы карчык күрше



Рәсем: Наталья Васильева

булып килгәнгә бик тә куандылар. Бибисара һәрберсенә күчтәнәчләр төреп бирде, елмаеп озатып калды.

...Яңа фатирда тормышы матур, күңелле башланып китте. Тик иске йорты тирәсенә, зиратка ничә тапкыр барса да, песиен очрата алмады. Ул кичен ишекләрен бикләп «Аятел-Көрси»не өч тапкыр укыды. Беркайчан да биш вакыт намазын, намаз артында укыла торган догаларны калдырмады.

– Сөбханаллаһи үәлхәмдү лилләһи үә лә иләһә илләл-лаһү үәллаһү әкбәр...

Еш кына песиен алган теге малайны исенә төшерде: «Кем белә, бәлки, минем песиемнең Бүләк исемле баласын алган малай турында сөйләгәннәрдер бу хатыннар? Кызганыч, сорашмадым да бит, и Ходаем!»

Көннәр, атналар, айлар узды, ә Бибисара догада булды. Менә иртәнге ашын ашагач, уразага керергә ният кылу догасын укып:

– Нәүәйтүән әсуумә саумә шәһри рамәданәә минәлфәҗри иләл-мәгъриби хаалисан лилләәһи тәгаалә, – дип, әзрәк ятып торырга булды. Күпме черем иткәндер, көтмәгәндә ишегенә шакыдылар.

– Бибисара инәй, ачыгыз әле, сезгә хат бар, – диделәр. Бибисара «Бисмилла»сын әйтеп ишеген ачты.

– Нинди хат соң, яхшы гына хәбәр булса иде инде. Минем беркемем дә юк, беркемнән дә хат көтмим. Бу ялгышлыктыр, миңа хат язучы беркем дә юк бит, балам! – дияргә ашыкты.

– Юк, әбекәй, син яратып, тәрбияләп үстергән Әминә исемле кыздан бу хат. Ул чит илдә яши, Төркиядән шәһәр хакимиятенә хат җибәргән. Хаты эчендә сиңа аталганы да бар. Бу кыз хатны безгә, управдомга, китерде. Мин сине беләм бит, шуңа аны үзем алып килдем, – диде теге чакта күченергә ярдәм иткән хатын. – Әй, әбекәем, фатирың ничек матурланган, нинди нурлы... Ярдәм кирәк булса, әйт, булышырбыз. Синең кебекләр күбрәк булса, бу дөнья тагын да матуррак булыр иде, – дип, Бибисара әбине мактады.

Аннары кыз укый башлады.

– «Бибисара апа! Бу мин – Әминә. Исәндәдер, минем әти – Хәмит, ә әнием – Әсма Әмир кызы анда вафат булган иде, каберен карарга вәгъдә биргән идегез. Бу хатны әтием кушуы буенча язам, Бибисара апа. Сез озак еллар безнең белән бер гаилә булып яшәдегез. Туган яклардан китүебезгә дә шактый еллар үткән, берничә тапкыр посылкалар салдым, хатлар да яздым, хәбәр булмады... Дөресрәге, картәтиемнең үтенечен үтәргә дип, әтием яздырды. Ярый әле исәнсез, әти кайлардан белгәндер инде, ләкин картәтиемнең аманәтен үтәргә булдык, аның язуын салабыз, үзе хәзер гүр иясе инде. Үзең укырсың, мин – Әминә кызың. Үбәм, хуш!»

Бибисараның, күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте:

– Рәхмәт яусын, зур шатлык алып килгәнсез миңа. И балам, минем үткәннәремне сөйләсәң, үзе бер зур тормыш. Менә шул изге кешеләр, үзләре киткәндә кала читендәге өйне сатып алып бирделәр. Ничә еллардан соң мине онытмыйча хат язуларын әйт әле, ә? Рәхмәт төшкере, мин догада булырмын. Картәтиләренә ясин укырмын, Аллаһы Тәгаләм боерса, – дип, Бибисара кулъяулык чите белән күзләрен сөртеп, икенче хатны кулына



алды. Кызлар: «Бу, Бибисара әбекәй, синең телдә, гарәп хәрефләре белән язылган, без укый алмыйбыз инде анысын», – дип, ишеккә таба атлаганнар иде, әби алартуктатты:

– Туктагыз әле, балакайларым, кичә кичтән генә пешергән пәрәмәчем бар иде, икегезгә икешәрне алыгыз әле, ифтарда авыз ачкач, шулар белән чәй эчәрсез, – дип, аларга пәрәмәчләрне төреп тоттырды.

Кызларны озаткач, күзлеген алып, саргаеп беткән кечкенә хат кисәген кулына алды да укый башлады: «Биби, бу минем сиңа бер әйтер сүзем: без калдырган тимер караватның башларын сүтеп карачы, сиңа гомерең буена җитәр. Күпме еллар саклап йөрткән серем, шуның өчен дә: «Караватыңны ташлама, сакла – бу бездән «Бүләк», – дигән идем, хәтереңдәме, уңган кыз?..» – диелгән иде.

Хат ахырындагы хәрефләр бер-берсе белән буталып, югалып калгандай булды. Карчык, калтыранып, иске караватына күз ташлады. Хатның соңгы юлларында: «Бу минем буыннан-буынга күчеп килгән хәзинәле ятак, оныгым юллап килмәс – алар җитеш тормышта яши. Бибисара, кызымның каберен карыйсыңмы? Менә туксанны вакладым инде, син догада бул. Олы хөрмәт белән, Сөләйман бабаң...» – дип язылган иде.

Чү, Сөләймән картның әманәтен мин үстергән Әминә кызым юллап җибәргән булып чыга бит. Рәхмәт инде, балам! Бабалары яшәгән еллар кара еллар иде шул. Миңа һәрвакыт: «Син сабыр, акыллы, аз сөйлисең, синең белән ат урларга барырга була», – ди торган иде изге җан! Мине гарәпчәгә, укырга, язарга, намазларга да Сөләйман бабай өйрәткән иде», – дип, онытылып, хатны күкрәгенә кысып, Бибисара үз-үзенә сөйләнде...

Карчык килгән хатларны кабат-кабат укыды, көне буена да, һәр намаздан соң да, ифтардан соң да утын сүндермичә гел догада гына утырды.

«Аллаһы Тәгалә минем картлыгымны ничек зурлаган, көтмәгәндә хат җибәреп куандырган кешеләремә мең-мең рәхмәтләр», – дип кабатлады ул, тик ятагына якын барырга курыкты: «Нәрсә соң анда – карават башында», – дип аптырап торды.

Ниһаять, батырчылык итеп, карават башларындагы йомрыларны борырга маташты, тегеләр тутыгып беткәнлектән бирешмәде. Бибисараның да көче юк иде. Чүпрәкне көнбагыш маена чылатып сөртте. Комодның аскы тартмасыннан чүкечен алып суккалады. Маташа торгач, борып алды да, юрганын таратып, карават башын какты. Аннан көмеш тәңкәләр коелды... Карчык үз күзләренә үзе ышанмыйча: «Бу бит көмеш тәңкәләр! Патша башлары төшерелгән чын кара тәңкәләр! Әй Ходаем, боларны нәрсә генә эшләтим икән соң?» – дип сөйләнде.

Карават башының икенчесеннән дә шундый ук тәңкәләр коелды, алар арасында берничә алтын тәңкә дә күренде. Мондый байлыкны гомерендә беренче тапкыр күргәч, аптырап калды, кемнәргә бирергә боларны? Кемнәр белән бүлешергә? Хәзинә калдырган картның рухына дога кылды. Таңга чаклы күзен дә йоммады. Аннары, ныклы бер карарга килеп, берничә тәңкәне сумкасына салып, хатларын да алып иртүк хакимияткә юнәлде.

Әбине җылы каршы алдылар. Комиссия төзеп, бүләк көмеш тәңкәләрен банкта алыштырып, акчасын саклау кассасына салдылар. Ә бер өлешен, Бибисараның үтенече буенча, ятимнәр йортына күчерделәр.

Өлкәннәр көнендә Бибисара карчыкны зурлап, ятимнәр йортына чакырдылар. Рәхмәтләре чиксез иде директорның, олы йөрәкле карчыкны балалар белән очраштырырга зур залга алып төштеләр. Аның ничек ярдәм итүе турында сөйләп, таныштырып үткәч, Бибисарага сүз бирделәр. Ул чиста итеп киенгән, башына ап-ак батист яулык өстеннән зәңгәрсу кәшемир шәлен бәйләгән. Югалып калса да, каушавын сиздермәскә тырышып:

– Балакайларым, тырышып укыгыз. Белемле, укымышлы кеше беркайда да югалмый ул. Яшәгән, белем алган бүлмәләрегез якты, зур, чиста... – дип сөйләгән җиреннән карчык кинәт тукталып калды, кырыйда песи тотып басып торган малайга төбәлде. Башыннан: «Бу минем Бүләгем түгелме соң?» дигән уй ялтырап үтте. Ак туфлиле песине күргәч, карчыкның күңеле бер шатланды, бер икеләнде. Бу песие аңа бик тә таныш, аның ике тәпие дә ак. «Минем песи балам үскән! Бүләк! Бүләк!» – дип, әкрен генә якын килеп дәште. Малай да бер адым талпынып атлады: бик тә якын, озак көткән кешесен тапкандай, югалып калды. Ә дуслары: «Илнур, сине каян белә ул?» – дип аптырашты...

Әби бу йортка бик еш килеп йөрде. Үсеп җиткән «тере йомгак» – Бүләк араларын якынайтты. Малай да ял көннәрендә тәрбиячедән рөхсәт сорап, әбигә кайта башлады. Песие белән ул көтелгән кунакка әйләнде.

Бу өч ятимне үзара җылылык, бер-берсенә ышаныч һәм бер-берсенә тартылу хисе бәйләде. Җылы, чиста өйдә тәмле ризыклар белән сыйланулар малай өчен зур бәхет иде.

Көн артыннан көн, ай артыннан ай үтеп торды, аяусыз картлык һәм чир әбине аяктан екты. Түшәгенә яткач, бетмәс-төкәнмәс уйлары, ятим балачагы, авыр яшьлеге күз алдыннан үтте. Изге Сөләйман картка гомере буена догада булса да, аз кебек тоелды. Юк, якынлашып килгән әҗәле аны куркытмады, «Илнурым ничек яшәр, кемнәр соң ярдәм кулы сузар?» – дип борчылды ул. Ул арада Илнур җиткән егет булып килә иде инде.

Бу дөньяда тын гына яшәгән шикелле, әбинең әҗәле дә аны йоклаганда үз куенына алды. Бибисара карчыкны җирләп кайтканнан соң аның васыятен укып ишеттерделәр. Игелекле карчык бар булган мөлкәтен: фатирын, саклык кассасындагы хазинәсеннән үзенә тиешле өлешен – барысын да Илнурга яздырып калдырган иде. Һәм аерым кәгазьдә: «Улым, бергә барып йөргән изге зиратны гына уратып ал, маллар кереп, каберләр өстендә йөрмәсен. Бу – васыятем, улым!» – дип язылган иде.

Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләргә бирелгән зур бүләк – мәрхәмәтлелек хисе фани дөньядан, бакый дөньягача изге бер нур булып үзара бәйләнде...



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

ТАР КҮҢЕЛЛЕЛЕК

Кайбер кешеләр туганда ук тар күңелле булып туамы?

– Пәйгамбәребез бер хәдистә: «Һәрбер бала фитрасы, ягъни табигый халәте белән туа», – ди. Табигый халәт – Аллаһыга ышанучы, аны танучы булып туа дигән сүз. Димәк, ниндидер яхшы сыйфатлар белән дөньяга килә. Формалашканчы, балигълык яшенә җиткәнче, балалар гөнаһсыз дип санала. Мәрхүм булсалар, алар турыдан-туры җәннәткә керәләр дә. Балигълык яшенә җиткәч яки шул яшькә җиткәндәрәк аңа нәселе тәэсир итә башлый. Җиде буын әбибабаларының холкы, ниндидер сыйфатлары, авырулары яки, киресенчә, яхшы яклары шушы балада чагылыш табачак. Нәселдән күчкән холык, гомумән, биш яшьләрдә үк күренә башлый. Шуңа күрә дә кияүгә чыкканда (өйләнгәндә) сайлаган парыңның нәселенә карыйлар, өйрәнәләр. Анда кемнәр булган, алар үзләрен ничек тоткан – һәммәсен күздән үткәрәләр. Тар күңеллелек тә, гомумән, кешедә булган барлык начар сыйфатлар нәселдән килергә дә мөмкин. Ләкин тар күңеллелек үзе бер аерым сыйфат кына түгел. Ул калган сыйфатлардан формалаша – тәкәбберлекнең, саранлыкның, гафу итә белмәүнең, көнләшүнең, кешеләрне куралмау, яратмауның чагылышы булып тора. Әгәр дә кеше яшәү дәверендә шушы начар сыйфатларга ия булып, аларны үзендә үстерә килсә, болар ахыр чиктә барысы да тар күңеллелеккә китерәчәк. Бер көндә түгел, тора-бара. Тар күңеллелек артында ни торганын аңлаганда гына безнең алдыбызга тулы бер картина килеп басачак.

Тар күңеллелек кешенең үзенә күбрәк зыян саламы, әллә тирә-юнендәгеләргәме?

– Ул, әлбәттә, беренче чиратта кешенең үзенә зыян китерә. Ни өченме? Моны аңларга теләсәк, тар күңеллелек артында торган кайбер сыйфатларны аерым алып карыйк. Әйтик, саранлыкны. Пәйгамбәребез: «Саран кешене яратмаслар», – ди. Бу – кешенең үзенә зыянмы? Әлбәттә, зыян. Көнчелекне алыйк. Көнче кеше белән берәүнең дә аралашасы килми – рәхәт түгел бит. Димәк, ул тагын үзенә зыян китерә. Тәкәбберлекне карыйк. Мондый кешене дә тирә-юнендәгеләр яратмый, аның белән аралашмаска тырышалар, гадәттә, андыйлар икейөзле була. Шуңа да тәкәббер кешеләрнең, гомумән, дуслары булмый. Димәк, бу очракта да начар сыйфатыннан кеше үзе беренче булып зыян күрә. Шул ук вакытта аның тирәягында булган кешеләр дә моннан зыян күрә. Ир кешенең тар күңеллелегеннән хатыны зыян күрә. Хатынның тар күңеллелегеннән – ире, балалары. Күршеләре зыян күрә, туганнары, дуслары, якыннары. Хезмәттәшләре дә зыян күрә. Оныттырга ярамый: синең үзеңә зыян китергән әйбер башкаларга да зыян китерәчәк. Әмма без, һичшиксез, бер әйберне аңларга тиеш: начар әхлак, начар холык, теләсә нинди начар сыйфат, беренче чиратта, әлбәттә, кешенең үзенә каршы килеп чыга. Чөнки ул аның өчен савап алмый, бу аңа гөнаһ булып кына языла. Һәм шул гөнаһ кыямәттә аны тәмугка алып керергә мөмкин.

Телгән очракта бу сыйфатыннан кеше котыла аламы?

– Әлбәттә, котыла ала. Аллаһы Тәгалә: «Без кешеләрнең күңелләрен ачабыз», – ди. Күңелен ачканнан соң кеше иманга, дингә килә. Иманга, дингә килә алмаганнарның күңелләре ябык була – алар тар күңелле булып кала. Акылы белән Аллаһы Тәгаләнең, диннең дөрес сүзләр сөйләгәнен бөтен кеше аңлый, әмма йөрәгенә кертә алмый – күңеле, йөрәге ябык бит. Күңеле ачылгач, киңәйгәч исә хак, матур сүзне, дөреслекне кабул итә башлый. Үз чиратында үзе дә шушы хаклыкны, дөреслекне таратырга тырыша. Шуңа күрә тар күңеллелектән котылу өчен, беренче чиратта, моны Аллаһы Тәгаләдән сорарга кирәк. Аннан – үзеңдә булган шушы начар сыйфатларны бетерергә тырышырга. Ә әлеге сыйфатлардан арыну өчен безгә дин генә ярдәм итә ала. Әйтик, саранлыктан болай гына арынып булмый. Кешегә: «Саран булма», – дип күпме генә әйтеп торсаң да, уңай нәтиҗәгә ирешә алмыйсың. Үз малыңны кемгәдер бүлеп бирү бик авыр – акыл моны гел тыя. «Бирмә, югыйсә үзеңдә азая. Нинди ният, нинди максат белән син аны кешегә бирергә тиешсең әле?» – ди.

Яки икенче мисал: бөтен кеше дә үзен башкалардан өстенрәк итеп тоярга тырыша. Әгәр дин булмаса, син үзеңне, чыннан да, тәкәбберләнеп, өстенрәк тоярга мөмкинсең. Башка сыйфатлар да шулай. Коръән аятьләре, хәдисләр, динебез кешенең сыйфатларын үзгәртергә ярдәм итә, аны урынына куя – тирәякка һәм үз-үзенә дөрес итеп карарга өйрәтә. Шуңа күрә үз-үзен үзгәртер өчен динне кулланса, кеше киң күңелле була ала дип әйтәбез. Ләкин бу урында сорау туа: диннән ерак кешеләр дә киң күңелле булырга мөмкин бит. Алар бар, алар күп. Бу очракта нәселендәге күркәм кешеләрнең – ата-бабаларының аңа күчкән сыйфатлары ярдәмгә килә. Яки кемнеңдер (туганнарының, әбибабаларының) кылган догасы. Шуңа күрә динсез кешене тар күңелле дип әйтә алмыйбыз. Ләкин шул ук вакытта әгәр кеше диндә булмаса, динне аңламаса, динне кабул итәргә теләмәсә, ул барыбер тар күңелле булып санала. Ягъни кешеләргә карата киң күңелле булса да, үзенә карата тар күңелле булып кала. Үзенә җәннәт, үлгәннән соң рәхәт тормыш теләми. Аллаһы Тәгаләне юк дип әйтеп, шулай ук үзенең тар күңелле икәнен күрсәтә. Менә шуңа күрә тар күңеллелекне икегә бүләргә була: кешеләргә карата һәм дингә карата. Иң киң күңелле кеше – ул Аллаһы Тәгаләгә дә, кешеләргә карата да киң күңеллелеккә ия булган кеше. Әгәр икесенең берсе җитми икән, ул ярым киң күңелле генә була.





Безнең нәселнең тамырлары Казан ханлыгы чорына ук барып тоташа. Үземнең биш йөз еллык укытучылар династиясен дәвам итүче булуыма шатланып яшим. Гомер буе укытучы булып эшләдем, унҗиде ел рус телендә белем алсам да, рәхәтләнеп туган телемдә сөйләшәм.

Туганнарым – безнең нәселнең дәвамчылары – Сахалин, Урта Азия, Донбасс, Бурятия, Сочи һәм Россиянең төрле почмакларында дәрәҗәле урыннарда эшлиләр.

Әтием Мөхәммәдиев Әүхәди, әнием Фәйсханова Маһитап – Байлар Сабасыннан, икесе дә сугыш һәм тыл ветераннары. Алар – сугышның бар ачысын, үзәккә үткән мәшәкатьләрен үз иңнәрендә кичергән кешеләр. Әтием тимерче булып эшләгән. Үгез белән җир сөргәннәр, урак урганнар, урман кискәннәр, Шәмәрдәннән чәчү орлыгы ташыганнар, окоп казырга йөргәннәр.

Сугыштан соң да Карл Маркс исемендәге колхозда эшләүләрен дәвам иткәннәр. Әнием кәбестә, карлыган бакчасында алдынгы булган. Сабада алмагач бакчасын утырткannнар. Әниебез Маһитап Фәйзехан кызының арабыздан киткәненә инде ун ел булса да, гел безнен белән сыман. Ул балалары, кияү, онык-онықчыклары күңеленә мәңгегә якты нур булып кереп калыр.

Әтием сугышка хәтле Уралда тимер юлда, Белоглин, Донбасс шахталарында эшләгән. 1938 елда япон самурайларына каршы хәрәкәттә (Хәсән күле янында) катнашкан, инвалид. Сахалинда авыр хезмәттә булган. 1940 елда туган якларына әйләнеп кайта. Чит җирләрдә йөргәннән соң, үз районына кайтып, әнием белән тигез гомер итеп, сигез баласын хезмәт белән тәрбияләп үстергәннәр, югары белем биргәннәр. Гади хезмәт кешесенең дә зур тырышлык белән үз балаларын кеше итә алуның бер матур мисалы бу. Әтием Байлар Сабасында шырпы комбинатында, райпода янгын сүндерү хезмәтендә авыл хуҗалыгы идарәсендә 25 ел сак хезмәтендә эшләгән. Саба мәктәбен салуга аның да өлеше кергән. Әтиемнең кулыннан бар эш тә килә иде: өй дә салды ул, мич тә чыгарды, сәгать тә төзәтте, итек астына олтан да сала белде. Ун баласының сигезен югары уку йортында укытып, тормышта үз урыныбызны табарга ярдәм иттеләр. Мең рәхмәт аларга! Тормышта төрлесен күрделәр, әмма кеше булып кала белделәр!



Розалия МӨХӘММӘДИЕВА.
Саба районы.

Сөбханалла, күз тимәсен!

Уңган, тырыш, пөхтә Зөләйха Шәрапованы 1978 елдан бирле Казан дәүләт университетындагы тарих-филология факультетының журналистика бүлегендә уку чорыннан беләм.

Һәрвакыт затлы, матур киенгән, чем-кара чәчле Зөләйхага Татарстан китап нәшриятында, аннан соң «Татарстан коммунисты» журналында сәркатип булып эшләгәндә дә: «Күз тимәсен бу кызга, шулкадәр өлгер», дип, гел сокланалар иде. Хезмәтен яратып, җиренә җиткереп башкарды Зөләйха. Бауман урамы 19 нчы йортта язучылар үткәрә торган «Әдәби җомга» кичәләрендә катнашып, күренекле әдипләр, җырчылар, композиторлар белән таныштырды Зөләйха сабакташларын. Кичәләрдән соң, тулай торагына алып кайтып, самавырдан чәй эчертеп, коймак белән сыйлый иде. Болар инде үткәндәге якты, җылы хатирәләр.

Гаиләдә өч малай – Яхъя, Фәрит, Хәлил арасында бердәнбер кыз – әнисенең ярдәмчесе, җиз олпат самавырны чип-чиста итеп ялтыраганчы юып, бавырсаклар пешерүче, керләр чайкаучы уң кулы булып үсә ул әнисенең. Батыр йөрәкле,

Фото: Анна Арахамия

тәвәккәл булуы – әнисе Сәгыйдәнең әтисе Мирзаһит бабасына охшавыннандыр, мөгаен.

Зөләйхабыз хәзер Ханова инде. Казан дәүләт ветеринария академиясен кызыл дипломга тәмамлаган Габделбәр Ханов белән гаилә корды алар. Гөл кадерен былбыл белә диган кебек, бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яшиләр. Гаилә бәхетенә ямь өстәп уллары Булат туа. Ә менә кызларын көткәндә Зөләйха зур бәхетсезлеккә очрый: юлдан чыгып барганда аны машина бәрдерә. Тугыз айга кадәр оча сөяге сынган килеш хастаханәдә, аннан өйдә ятып, зур түземсезлек белән баласы тууын көтә, Аллаһтан ярдәм сорый. Шөкер, баласы исән-сау туа, аңа Зөлфия дип исем кушалар. Әти-әнисенә, энеләренә рәхмәтле ул бу көннәр өчен. Зөлфия зур үсеп, әти-әнисенең горурлыгына әйләнә. Матур итеп затлы калфаклар чигә, дини белем ала. Казанның 70 нче мәктәбендә балаларга белем бирә.

Зөләйха бүгенге көндә китаплар язу белән шөгыльләнә. «Шау чәчәкле болынлыкта Әшәлчәм», «Авылым йортлары – тарихым капкалары» китаплары туып-үскән җиренә зур бүләк. Шулай ук авылларына багышлап ике фильм да ясата ул.

Зөләйха хәзер лаеклы ялда булса да, зур максатлар белән яшәвенә сокланам! Ул һаман эзләнүдә, тарихын барлауда. Тырыш авылдашлары турында мәгълүмат җыя, алар турында мәкаләләр яза, шәҗәрәләр төзи.

Дөньяда аның кебек эчкерсез кешеләр күбрәк булсын иде!

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан.



Минемчә, бәхет кешегә гаиләсе аша килә. Һәр кешегә үз гаиләсе кадерле һәм изге була торгандыр.

Әтием ягыннан бабам Галимҗан – Сарманның Чукмарлысыннан. Әтиәниләре берсе артыннан берсе вафат булып, алты бала бик яшьли ятим кала. Күрше Илексаз авылының тырыш гаиләсендә үскән Шәмсенисаны, димләп, бабайга кияүгә бирәләр. Фәхрисламовлар гаиләсендә бер-бер артлы дүрт бала туа. Шатлыклары озакка җитми, 1941 елда Бөек Ватан сугышы башлана, бабамны сентябрьдә фронтка озаталар. Әтием Гыйффәт – әле бер айлык сабый, олысы Гөлсинәгә 8 яшь була. Галимҗан бабай юлда салкын тидереп, Куйбышев госпиталендә вафат була. «Иреге сугышта үлмәгән, дип, берсеннән-берсе кечкенә дүрт балага пенсия дә түләмәделәр. Җаным-тәнем белән тырыштым, балаларыма хәер сораштырмадым», – дип сөйли иде әбиебез. Язмыш аны тәрлечә сыный. Күкрәк баласы булган әтиебезгә бишек сиртмәсе төшеп, үлем хәлендә кала. Әби аны олы бер могҗиза белән генә саклап кала. Сынаулар моның белән генә бетми: кыш уртасында кич белән яктылык өчен телеп куйган чырадан янгын чыгып, йортсыз калалар. Әби кайтуына ишегалды уртасында кап-кара морҗа гына утырып кала. Ә аның өстендә торган изге Коръән китабына берни булмый. Бәхеткә, балаларны күрше-тирә тәрәзәдән чыгарырга өлгерә. Ул кышны күрше Гайсина Нурҗиһан апада чыгалар. Җәйгә инде Илексаздагы туганнары ярдәме белән өй өлгертеп керәләр. Нурҗиһан апа якын туганыбыз кебек булды, әти-әни аны яккан мунчадан, пешкән ризыгыннан калдырмады, ярдәмләшеп яшәделәр. Шәмсениса әби безгә – оныкларына догалар өйрәтте, пәйгамбәрләр тарихын гарәпчәдән тәрҗемә белән укый иде. Шундый бер вакыйгага гел исемдә. 5 нче сыйныфта укыган чагым иде. Яз башында болыннар кардан ачылуга без, түбән оч кызлары, шунда туплы уйнарга җыела идек. Беркөнне уенга чыгарга вакыт җиткәндә әбием токмач басарга кушты. Мин тиз генә камырны җәйдем дә, ашыга-ашыга калын итеп токмач кисеп куйдым. Әби токмачларымны күрде дә, яңадан камырны җыйдырып, җылы шулпа салып, кабат җәяргә кушты. Бу юлы инде токмачны нечкә итеп кисәргә туры килде. «Эшләгәнең безнең өчен булса, өйрәнгәнең – үзең өчен, тик яхшы итеп эшлә», – дигәне гомерлек тормыш дәресе булды. Шәмсениса әбинең авылыбыз остабикәсе булуын да әйтмичә кала алмыйм. Мактануым түгел, хәтта туган авылы Илексазда да, әбиебез кунакка килсә, Коръән укытып, аш уздырырга алдан чират алып куя торган булганнар. Нәсел тамырларын барлый башлагач, әнием Лира ягыннан булган әбием белән бабамны да искә алыйм инде. Алар, Чукмарлыдан ерак түгел, Куктау авылында яшәгән. Бабам Мөхәммәт Галиев белемле, зыялы булган. 1938–1941 елларда Чукмарлыда авыл Советы рәисе булып эшли. Аннан сугышка китә. 1945 елның 15 мартында, Берлинга 70 чакрым калган җирдә каты яралана. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен бик күп орден-медальләр белән бүләкләнә. Мөхәммәт бабабыз – безнең горурлыгыбыз. Язучы Мөхәммәт Садри үзенең «Солдат һаман юлда» дигән китабында бабайга багышлап «Тупчы Мөхәммәт» дигән әсәрен урнаштырган. Шулай ук Риза Ишморатның «Җиңү юлы буйлап» дигән китабында да бабабыз турында язма бар. Алар фронтовик дуслар була. Әби-бабаларым турында берсеннән-берсе матур, якты истәлекләр саклана күңелдә. Урыннары оҗмахта булсын. Безнең хәер-догаларыбыз барып ирешсен!

Гөлнара ФӘХРИСЛАМОВА-ГУДАЕРОВА.
Сарман районы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адр ес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

ҮГИ ӘНКӘЙНЕҢ ҖЫЛЫ ЙӨРӘГЕ



Фото: Анна Арахамия

Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

«...Үги ананың бик әйбәтләре була. Гадәттә, алар турында гел яман сөйлиләр, ләкин алар турында юньле сүзне күбрәк сөйләргә кирәк. Чит канга ана булырга тырыша бит ул. Мәҗбүри яратып булмый бит. Ә ул рольгә кереп «уйнарга» тиеш. Бала исә рольгә керми, «уйнамый». Ике артистның берсе уйнап, икенчесе уйнамаса, спектакль туа алмый. Үги аналы гаиләдә әнә шуңа күрә җылы, уңай тормыш коруы бик кыен. Үги аналарны кызганырга, ихтирам итәргә кирәк...» Мөхәммәт Мәһдиев «Мәңгелек яз» әсәрендә үги әниләр турында әнә шундый уйлануларын язып калдырган. Үги тормышны үз башына төшкәннәр генә аңлыйдыр, мөгаен. Үги ананың да, үги баланың да үз хәле... Әмма гомер уртасына җиткән ир балачагын искә алганда «Үги әниләргә һәйкәл куярга кирәк», – ди икән, димәк, барлык үги әниләр дә, халык телендәге кебек, явыз түгелләр. Чит балаларны карап үстерә икән, димәк, алар олы йөрәкле...
Үги әни белән үскән Татарстанның халык артисты Җәвит ШАКИРОВ үзе сөйләсен әле...

– Бик елак булганмын мин. «Кем башына улый микән бу?» – дип әйтә торган булганнар. Әнкәй үлгәч, елаудан туктаганмын. Туры килү микән инде бу, әллә чынлап та юрауларның чынга ашуымы... Әнкәй үлгәндә бик кечкенә идем. 3 яшьләр тирәсе булды микән. Аның авырып ятканын, хастаханәгә алып киткәннәрен өзек-өзек кенә хәтерлим. Соңгы юлга озатканда олылар артыннан зиратка ияреп барганымны да бераз беләм. Кышкы бик салкын көн иде ул. Шунда картинең (әнинең әнисе) минем янга килеп бүрегемнең колакчыннарын ныгытып бәйләп, муеныма шарф урап куюын хәтерлим. Ятимлекнең беренче ачылары шуннан башлангандыр инде ул. Салкыннан саклаучы әни юк! Салкын... Әткәй колхоз эшеннән кайтып кермәде. Әнкәйне югалткач, йөрәк ярсуын басар өчен тагын да эшкә бирелгәндер. Әткәй иртән мичкә ягып киткәндер инде. Әмма ягылган мич – әнкәй җылысы түгел. Йортыбыз алты почмаклы иде. Кергәч тә – кухня. Алгы бүлмәгә узуга – уң якта карават. Без – өч бертуган, Мәснәви абый, Радик абый һәм иң кечкенәсе – мин шул караватта йоклый идек. Өйгә салкын төшә башлагач, юрган астына кереп ятабыз. Абыйларым мине уртага салалар. Үзләренчә шулай җылытырга теләгәннәрдер инде... Кереп-чыгып безне караучылар булгандыр инде ул. Хәзер дә уйлап куям: нигә ул вакытта безне туганнар тәрбиягә алмады икән? Эти бирмәде микән? Әллә бер кешегә дә кирәк булмадык микән...

Безне карар өчен әткәй әнкәйләр алып кайта башлады. Берәүне генә дә түгел, өчне генә дә түгел... Хәтерлим әле тракторга утыртып, әнкәй алып кайтырга ерак авылга алып барды. Мине күреп җәлләсеннәр өчен шулай эшләде микән?.. Без беркайчан да өйгә килгән хатын-кызга апа дип эндәшмәдек, беренче көннән үк «әнкәй» дип әйтә идек. Ана назы теләүдән булды микән ул... Әле хәзер дә Башкортстанның Чакмагыш район үзәгендә яшәгән Радик абый белән күрешкән саен искә алабыз: әткәй кемне генә алып кайтса да, әнкәй, дидек. Күпме кешегә әнкәй дип әйткән балалар без! Әмма йөрәккә тигәне: алар киләләр дә, кире китәләр иде. Юк, килгән әнкәйләргә начарлык эшләмәдек без. Аларның калуын бик теләгәнбездер, үзебезчә ярдәм итәргә дә тырышканбыздыр. Өйдә хатын-кыз булмау авырлыгын ул вакытларда инде аңлап өлгергәнбездер. Хәлле хуҗалык санала идек. Абзар тулы мал-туар булды. Авылда иң беренче «Запорожец» машинасын да әткәй алды. Әткәй колхоз дип янды. Өйдә бик сирәк була иде. Помпотех (техника буенча бригадир ярдәмчесе) булып эшләде. Көне-төне запчасть артыннан чапты. Килгән әнкәйләр авырлыкка түзә алмаганнардыр. Зур хуҗалык өстенә, өч чит балага ана бул әле син! Өч малай бит ул! Безне бит ашатырга, өс-башларыбызны юарга, тәрбияләргә кирәк. Әмма үзәкне өзгән бер яклары бар иде: килеп бер атна яшәделәрме, ике ай тордыларммы, киткәндә мал бүлделәр. Аларның нәрсә алып килгәнен хәтерләмим, әмма төянеп китәләр иде. Хәтта абыйлар белән ярып өеп куйган утын әрдәнәсенең яртысын төяп җибәргәнебез хәтеремдә...

...Күпләр килде, күпләр китте. Әткәй безгә күп тапкырлар: «Бүген кунак килә. Сезгә әнкәй алып кайтам, әзер торыгыз», – дип әйтте. Күп тапкырлар сөенә-сөенә өй җыештырдык... Хәзерге әнкәебез тугызынчымы, сигезенчеме булып килде. «Сине 5 яшьтән карап үстердем, балакаем», – ди әнкәй миңа.

Бу әнкәй килгәч, тамак туя башлады, өс бөтен булды. Безне җәлләп килгәндер инде ул. Аңа ул вакытта 32 яшь булган. Эти белән аралары 7 яшь. Ул вакытта безнең өйдә бернәрсә калмаган. «Сезне ашатырга ни кашык, ни тәлинкә юк иде. Әниләрнең ташларга дигән китек кашыкларын җыеп алып кайттым», – дип сөйли әнкәй.
Әнкәй эштән курыкмады. Абыйлар белән утын да кисә иде. «Килгән мәлне көн аралаш алтышар таба ипи сала идем», – дип искә ала әнкәй. Безне ашатып туйдырып булмагандыр, күрәсең. Ул пешергән ипи тәме һаман истә. Безнең караватыбыз янындагы гына өстәл бар иде. Күпереп пешкән яңа ипине мичтән алып шунда тезеп каплап куя торган иде әнкәй. Көндез генә ашау җитмәгән, төнлә, ут сүнгәч, шул ипине сындырып алып юрган астында ашый идек. Ипи валчыклары, коелып, иртәнгә тәнгә ябышып каталар иде. Ләкин төнлә ипи ашап яткан өчен әрләгәнен хәтерләмим. Балалык булгандыр инде ул. Иркәләнеп-назланып яшәмәсәк тә (ул вакытларда бала сөю дигән әйбер булды микән?), ямьсез яшәмәдек. Әйткәнемчә, әткәй эштән кайтып кермәде. Бик абруйлы кеше иде. Кулында һәрвакыт техника булды. Мал таба белде. Председательләр, күрше авыл бригадирлары кереп йөри иде безгә. Ә алар авылда теләсә кемгә керми.

Без инде әнкәй китмәсен дип тырышканбыздыр – кул арасына керә башлагач, бөтен эшне эшләдек. Әнкәй ашсу остасы иде. Өйдә колхоз механизаторларына ашарга пешерде. Без гел аның тирәсендә кайнаштык, ярдәм иттек. Бәрәңгесен әрчедек, бидонын юдык. Әле ипигә дигән камыр басканым да хәтердә. Ипи пешерү өчен урманнан колмак җыеп кайту минем өстә иде. Гомумән, урманда җиләк-җимеш җыярга ярата идем. Чиләгемне тутырмыйча кайтмадым. Бу – балачакның күңелле бер хатирәсе. Әнкәй бик дөрес, гадел, чиста кеше безнең. Механизаторларга дип биргән иттән, ипидән безгә өлеш чыгарганы булмады. Алардан соң бидон төбендә калса гына салып бирә иде. Авыл халкы барыбер сүз ишеттерми калмый. Бервакыт әнкәй аш пешерүдән баш тартты. Өч-дүрт көн генә башкалар пешереп карады. «Безне Әлифә апа ашатсын», – дип, механизаторлар баш күтәрде.

Әткәй белән әнкәйнең уртак ике балалары туды: энем Азат, сеңлем Ләйсән. Яшь аралары хәтсез зур иде. «Аера идеме?» – дип сорыйсың киләдер... Сизмәдем. Балалык белән сизмәдем микән? Бишебезне дә бертигез күрә иде.

«Үги аналарның бер кимчелеге була. Һәрберсендә дә. Бик кечкенә кимчелек ул. Үги баласын уятканда ул беркайчан да баланың җылы, йомшак яңагыннан сөйми. Ятагыннан торып идәнгә баскан үги баланың җылы гәүдәсен беркайчан да үзенең кочагына алмый. Баланың, кичтән чайкалмыйча калганлыктан, төнлә «пәри ялаган» авыз тирәсеннән, әллә нинди исләр килеп торуга да карамастан, яратып бер үбеп алмый. Чөнки ул – үзенеке түгел. Үз сасысы түгел. Әнә шул ике назны күрмәгән бала үги бала дип атала...»
(Мөхәммәт Мәһдиев)

PRESSA



■ Авылга кайткан саен, без кечкенә чакта кып-кызыл булып утырган Чия тавына карыйм да рәхмәтләремне укыйм. Үстергән әнкәемә, тапкан әнкәемә... Тудырган әнкәем, балаларым бәхетле булсын иде, дип васыять итеп калдыргандыр, мөгаен... Шуңа безне Әлифә әнкәебез ятимлек чоңгылыннан үз кочагына алгандыр. Ә чит канны һәркем дә кочагына ала алмый...

Әткәй белән әнкәйнең гармун алып кайтканнарын хәтерлим. Безнең авыл гармунчылар авылы иде. Күршеләргә кереп гармун телләренә басыштыра башладым. Грипп белән авырып ятканда алып кайттылар бит шул җиз телне. Авыру да онытылды, урам да онытылды, лапта уены да онытылды. Өйдән чыкмыйча гармун уйнарга өйрәндем.

6-7 нче класста укыганда мине Уфага – интернат-мәктәпкә җибәрергә документлар җыя башладылар. Ул бик яхшы белем бирә торган көчле мәктәп иде. Уфадагы бөтен танылган артистлар шунда укыган. Документны җыеп бетергәч кенә әткәйгә: «Нигә аерасыз аны, котыласыгыз киләме?» – дигән сүз ишеттергәннәр бит. Шуннан әткәй белән әнкәй уйларыннан кире кайткан. Шулай итеп авылда калдым.

Мәктәп дигәннән... Ятимлек ачысын искә төшерә торган бер нәрсә бар иде мәктәптә. Елга бер тапкыр ятимнәргә бишмәтме, пимамы бирәләр. Безне класста аны миңа гына бирәләр иде. Бишмәтемне тотып: «Ни өчен нәкъ менә минем язмыш шундый икән?» – дип уйлап утыра идем...

Әти усал түгел иде. Бөтен усаллыгы: «икеле» алсак, дәфтәр күчертте. Өйдә стена белән идән арасында ярык бар иде. Әткәй салмышрак кайткан көннәрдә дәфтәрне шунда гына шудырып төшереп җибәрәбез. Икенче көнне ул эшкә чыгып киткәч, дәфтәрне идән астыннан төшеп алабыз. Ә менә әнкәй эзле усал иде. Шул усаллыгы белән безне җиңгәндер дә инде. Җебек булса, җиңә алмаган булыр иде. Әйе, әнкәйнең дә кайтып киткән чаклары булды. Әмма анда әнкәйнең әнисе дә эзле усал иде. Аннан соң татарда «Төшкән җирендә таш бул», дигән әйтем бар. Әткәй алырга баргач, кайта иде әнкәй. Әткәй салгалый иде шул безнең.

Авылның бит аның бер начар гадәте бар: бар булсаң – күралмыйлар, юк булсаң – бирә алмыйлар. Көнләшүчеләр дә булгандыр. Әткәйгә өмет итеп йөрүчеләр дә булгандыр. Әткәй, бәлки, йөрәген басар өчен эчкәндер, ә бәлки, аны җәлләп эчерткәннәрдер. Авылдашлар: «Әхмәтгали, эчмә, хатының, балаларың бар», – дип әйтергә тиешләр иде дә соң, әмма авылда ул сүзләрне бик сирәк кеше әйтә шул. Әткәй бер дигән эшләп йөргән җиреннән, хаталанып, эчеп кайта торган иде. Хатасыз кеше булмый, билгеле. Ни өчен шулай кылангандыр?! Әнкәй: «Котырталар, балакаем», – ди торган иде. «Әхмәтгали, Әлифә бит балаларны ашатмый, аларны эшләтә генә, кыйный», дигән сүзләр эчкән кеше өчен кызыл чүпрәк инде ул. Кайтып кәстрүл белән ашларны чыгарып түккән чаклары булды... Элек акчаны сандыкта саклыйлар иде бит. Берсендә, тавыш чыккач, әткәй сандыктан акчаларны алып мичкә атты. Мич алдында өелеп торган утынга кысылып калган кызыл унлыкны алып качырганым хәтердә. Өйдән чыгып йөгергән чаклар да булды. Ут сүнгәнен көтеп йөрибез дә кереп ятабыз. Озак сүнми торса, күршеләргә кереп кунабыз. Без, балалар: «Әткәй, эчмә инде», – дип әйтә торган идек. «Булды, балалар, башка эчмим», – дисә дә, кабатлана иде шул ул хәлләр. Әмма бер кешегә дә сиздермәдек, зарланмадык... Әткәйгә карата үпкә дигән әйбер булмады бездә. ӘТКӘЙ бит ул! Язмыш... Берни эшләтеп булмый. Гаеп итеп сөйләвем түгел. Мин әткәйне аңлыйм. Бик авыр булган аңа. Күп авырлык күргән. Йөрәге янгандыр. Безне кеше итәргә тырышкан. Мин рәхмәтле генә аңа. Әткәй 60 яше тулганчы ук китеп барды. Авырып та тормыйча. Ул вакытта Казанда Горький урамында – Сәйдәш музееның бер бүлмәсендә яши идек. Төш күреп уяндым. Әткәй эшләгән МТМ (машина-техника мастерское) чип-чиста итеп җыештырып куелган. Монда бит тәртипсезлек иде, ничек болай җыештырылган бу дип уйлыйм төшемдә. Уянып, ике сәгать үтте микән, «Әтиегез үлде» дигән телеграмма китереп бирделәр. Урыны җәннәттә булсын!

Үги әнкәйләргә җылы мөнәсәбәт булган кешеләр бик аз шул ул. Ә безнең әнкәй ничек кенә кырыс булса да, ашатты-киендерде, балалар арасында ким-хур булмадык. Киенү, ашау, тәртип ягыннан да авылдагы башка балалардан бер башка өстен булдык. Әткәй техника арасында йөрсә дә, пычрак кием кимәде. «Ир-атның иң күзгә ташланган әйбере күлмәк якасы һәм күлмәк җиңе», – дип әйтә торган иде әнкәй, хәзер Зөлфия апагыз кабатлый. Әнкәй юктан да чук ясый иде. Төн утырып безгә, үзенеке булмаган өч балага, оекбаш-бияләйләр бәйли иде. Аны яманларга ничек тел барсын?! «Улларым», дип кенә эндәште һәм эндәшә. Ул заманда да авылда эчә торган хатыннар бар иде. Бер дигән гаиләләрдән дә рәхәтлеккә чыдаша алмыйча, начар юлга кереп киткән хатыннар да бар бит. Ә безнең әнкәй авырлыкларга бирешмәгән. Ул түзгән, холкы көчле булган. Исән-сау гына булсын – 84 яшь тулды үзенә. Сеңлем белән авылда яши. Без дә кайтып йөрибез, кулдан килгәнчә ярдәм итәбез.

Үги әнкәйләргә һәйкәл куярга кирәк! Мин моны чын күңелемнән әйтәм. Ул вакытта да бездән котылырга мөмкинчелек булгандыр. Ә мине, әйтәм бит, интернат-мәктәпкә дә җибәрмәделәр. Җәмгыятькә ярарлык итеп тәрбияләп үстерде әнкәй. Әгәр тәрбия булмаса, бәлки, юкка чыккан да булыр идек. Балага ана тәрбиясе аеруча мөһим ул.

Кирәк ӘНКӘЙләрнең исемнәрен,
Мәрмәр такталарга уярга!
Бу гына аз! ҮГИ ӘНИләргә кирәк
Алтыннардан һәйкәл куярга!

2021 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР
(һиҗри исәп буенча 1442–1443 еллар)

18 февраль – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич Рәгаиб кичәсе дип атала. Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисенең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә. Бу айда Ибраһим һәм Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре. Кече хаҗ – гомрә хаҗы да шушы айда кылына.

10 март – Мигъраҗ кичәсе. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

27 март – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

13 апрель – изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн. Коръән иңгән ай.

8 май – Рамазан аеның соңгы ун киченең берсе – Кадер кичәсе (ул 27 нче кичкә туры килергә мөмкин). Бу кичәдә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәдне пәйгамбәр итеп сайлаган. Кадер кичәсендә башкарган изгелекләр мең ай эчендә кылынган яхшылыкларга караганда да хәерлерәк. Кадер кичендә гөнаһлар гафу ителә, догалар кабул була.

13 май – Гайдел-фитыр көннәре. Ураза гаете.

21 май – Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы – һиҗри, 922 нче милади ел).

19 июль – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

20 июль – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган корбан чалу бәйрәме.

21, 22 июль – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә фарыз намазларыннан соң, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен махсус догалар кылына.


9 август – яңа мөселман елы – 1443 ел һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына торган ай. Аллаһы Тәгалә бу көнне игелек кылучыларның гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

18 август – Гашура бәйрәме – мөнәҗәтләр, догалар укыла торган бәйрәм.

17 октябрь – Мәүлид бәйрәме. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) туган көн. Бу көннәрдә мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәерләр (зәкят) таратыла.

Төзүчесе:
хаҗи Абдулла ДУБИН.

Фото: Анна Арахамия



КАРЕЛ ИЛЕ



Фото: www.pixabay.com



Чулпан
ӘХМӘТОВА

Карелиягә баруыбыз һич уйламаганда килеп чыкты. Финляндиягә барып кайту нияте белән Казаннан Питерга алган билетлар бар иде. Таҗлы вирус афәте, ил чикләрен җиде йозакка бикләп, хыялларга нокта куйды дисәм, өтер генә булган икән. Шөкер, без ялга чыгар вакыт җиткәндә ил эчендә чикләүләр йомшартылды, шәһәрара очкычлар оча башлады. Ниятләгән сәфәребез, ярты юлда юнәлешен үзгәртеп, Санкт-Петербург–Петрозаводск поездында «Карелияне ачу» дигән яңа максатка таба кузгалды.

Ак төннәр хакимлек иткән июль ае иде. Питердан ераклаша барабыз. Төн уртасы булуга карамастан, дөнья яп-якты, тимер юл кара урман уртасыннан, зәңгәр күлләр янынннан чаба, берән-сәрән генә авыллар күзгә ташланып кала. Дөресен әйткәндә, гел урманнар арасыннан бару бераз ялкыта, хәтта шомландыра да дияр идем. Әкияттәге кебек бит: кара урман, чуен юлы, алда – билгесезлек...

Петрозаводск безне еламсырап каршы алды – вак яңгыр сибәли иде. Бераздан ялтырап кояш чыкты, тимер юл вокзалыннан башланып киткән Ленин проспекты безне туп-туры Онега күле ярларына алып килде.

Шәһәр яшеллеккә күмелгән. Урамнар чиста-пөхтә, йортларны төзү-төзәтү эшләренә ныклап тотынганнар. Зур проспектларның һәркайсы Онега күле ярына китереп чыгара. Бу күл – шәһәрнең йөзе, горурлыгы, туристларны җәлеп итү урыны. Яр буенда да төзекләндерү, бизәү эшләре бара. Шунысы кызык, алны-ялны белмичә, эшне бетерик инде дип ашыгып эшләмиләр монда. Бу нисбәттән, «Бездә булсамы?!» кәлимәсе уйга-телгә еш килде.

Тарихка күз салсак, Петр патша 1703 елда Онега күле тамагында – Лососенка дигән елга ярына корал заводын төзү эшенә керешә. Ул бу якларда җирнең тимер рудасына бай булуын күрә. Тимер күп булганлыктан, хәтта аерым сулыклар махсус төскә, тәмгә ия бирәдә. Әлеге завод төзелешенә башка җирләрдән осталар китерелә, крестьяннар күчереп утыртыла, хәрбиләр җәлеп ителә... Шул урында Петровская бистәсе барлыкка килә. 1777 елда Екатерина II Указы белән аңа шәһәр статусы бирелә. 1781 елда Петрозаводск Олонецкая губернасының үзәге булып санала башлый. Әлеге төбәкнең беренче губернаторы исә якташыбыз, шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Гавриил Державин була.

Петрозаводскиның үз аурасы бар: аны тоеп була. Шәһәр православие рухы белән сугарылган. XVIII–XIX гасырларда Иске шәһәрдә төзелгән архитектура корылмалары – Александр Невский (1823), Крестовоздвиженский (1852) гыйбадәтханәләре, апостоллар Петр һәм Павел (1781), Стретенская (1798) чиркәүләре бик кадерләп саклана.

Анда яшәүчеләр гадиләр, әмма Карелиянең – үз якларының чын патриотлары. Дөньяда берданбер урында – Онега күле янындагы Шокша бистәсе янында чыгарыла торган ал төстәге кварциттан Наполеон саркофагы, Мәскәү Кремле янындагы Билгесез солдат кабере, Мавзолей һәм Казан соборының аерым өлешләре эшләнүен горурланып сөйлиләр.

Карелия – төрле балыклар мыжгып торган елгакүлләр, затлы-кыйммәтле ташлар, чыршы-нарат урманнар иле. Петрозаводскидан бераз читкәрәк китүгә, биеклеге 12 метрдан ашкан кыялар тезелеп киткән. Вулкан атудан, җир тетрәүдән барлыкка килгән бу кыялар сокландыра да, сагайта да.

Кайчандыр бозлыклар эрегәннән соң барлыкка килгән Онега күлен «төче сулы диңгез» дип атыйлар.

Әйтүемчә, шәһәр халкының иң яраткан урыны – Онега күле. Күлнең яшен 12 мең ел тирәсе дип исәплиләр. Аның мәйданы – 9700 квадрат километр. Зурлыгы ягыннан Европада төче сусаклагычлар арасында икенче урында тора. Дөнья күлләре арасында – унтугызынчы урында. Тирәнлеге 127 метрга җиткән урыннар бар. Аңа меңләгән елгалар коя. Свирь елгасы исә аны Ладога күле белән тоташтыра. Әлеге күлдә мең ярымлап утрау исәпләнә.

Петрозаводскидан бу утрауга туристлар төялгән метеорлар еш йөреп тора. Су юлы белән бер сәгать чамасы барыла. Урыны-урыны белән ярлар күздән югала, әмма эреле-ваклы утраулар еш очрый: кайберләре буш, икенчеләрендә тормыш барлыгы күзгә ташлана.

Кижи утравын әллә кайдан танныйсың – мәһабәт, затлы Преображенская чиркәве еракларддан балкып, әкияти бер серлелек белән үзенә чакырып тора. Биеклеге 38 метрга җиткән бу гыйбадәтханә – Кижи утравының төп бизәге, ул дөньяга танылган, дәреслекләргә кертелгән корылма. 22 гөмбәздән торган әлеге бина фәкать агачтан төзелгән. Читтән караганда, аның агачтан гына булуына ышанасы да килми. Искиткеч архитектура, күз явын алырдай бизәкләр, гөмбәзләрнең агачтан эшләнүе һәм гасырлар дәвамында су уртасында саклануы (1714 елда төзелгән санала) – үзе бер могҗиза. Нәкъ шушы корылма утрауның музейга әверелүендә хәлиткеч роль уйный.


Әлеге чиркәү ишегалды каберлекләрдән генә тора. Бер нәсел кешеләрен җирләү өчен кечкенә генә мәйданчык бирелгән – һәр нәселнең үз хачы, өч аршын җире. Мәетләрне ничек җирләгәннәр, ничек урын җиткергәннәр – башка сыймый.

Карелия туфрагы – икмәк үстерә торган уңдырышлы туфрак түгел. Анда гомер бакый икмәккә туймаганнар. Ни гаҗәп, Кижи утравының туфрагы исә иген игү өчен бик кулай булып чыккан. Моны белеп алган кешеләр, җиргә бик сак мөнәсәбәттә булып, хәтта йорт-җирләрен якын-тирә утрауларга күчереп, шул урынга иген чәчә торган булганнар. Мунчалар, амбарлар су эченә кертеп салынган. Зират өчен дә урынның бик аз бүленүен шуңа бәйләп аңлаттылар.

Утрауга йортлар, корылмалар төрле утраулардан алып киленгән. Бай йорты, урта хәлле крестьян йорты, фәкыйрь йорты – һәммәсе үзенчәлекле. Йорт эчендәге җиһазлар, кирәк-яраклар безне моннан ике-өч гасыр элек булган вазгыятькә алып кайта. Читәннән үрелгән койма-капкалар, бакчаларда үсеп утыручы яшелчәләр ул чорны тулырак күзалларга ярдәм итә.

Утрауларның иң танылганы – Кижи. Ул ЮНЕСКО тарафыннан дөнья-күләм әһәмиятле мирас булып теркәлгән.





«Менә бу йортны нигез хуҗалары эчендәге җиһазы-ние белән утынга дип саткан булган, – дип сөйләде гидыбыз. – Мендәр япмалары чигүләрендә сакланган даталарга карап, аның ике йөз ел чамасы элек салын-ганын белдек».

Әлеге утрауда өч авыл урнашкан – Кижи, Васильево һәм Ямка. Авыл саен берничә йорт, алар әле дә мал үрчетеп, балык тотып дөнья көтә.

Кижи утравы узган гасырның егерменче елларында ук тарихи-архитектура истәлеге статусын ала. Әмма 1966 елдан гына «күк астындагы музей» дип санала башлый. Әлеге утрау – ачык музей, биредә рус, карел һәм вепс халыкларының агачтан эшләнгән әйберләре тупланган. Карелия фин гаскәрләре тарафыннан ок-купацияләнгәч, бу утрау да әсирлектә кала. Финнар-ның аны үз илләренә кушу һәм фин галимнәре өчен тикшеренү объектына әйләндерү хыялы гына утрауны җимерелүләрдән саклап кала.

Көнебез әлеге утрау белән танышып, хозурланып узды. Бәхеткә, яңгыр да яумады, көчле җилләр дә чыкмады. Бу якларда һава тиз алмашына торган гадәт бар.

Әлбәттә, утраулар буйлап сәяхәтне тагын дәвам итеп булыр иде. Әмма санаулы вакыт чикле: икенче көнебезне Кивач шарлавыгына багышларга булдык. Ул республиканың Кондопога районында, мәйданы 11 мең гектар тәшкил иткән тыюлыкта урнашкан – Петрозаводскидан 80 чакрымда. Юл урманнар, сихри күлләр, күл тирәли урнашкан авыллар аша сизелми дә уза. Табигать гаҗәеп матур. Җан ял итә... Кивач фин теленнән «куәтле, гайрәтле» дип тәрҗемә ителә икән. Ул, чынлап та, шарлавыкның җанын чагылдыра: 10,7 метр биеклектән шаулап, гөрләп ага. Аның көче ташларны кузгата, ваклый. Кивач – үзенең зурлыгы белән Европада тигез җирдә барлыкка килгән шарла-выклар арасында икенче урында, аннан куәтлерәк булганы Швейцариядә, Рейн елгасында икән. Барып күрәсе булыр әле.

Риваять буенча, Кивач үзе белән янәшә агучы Суна һәм Шуя елгалары үзара узышып уйнаганда барлыкка килгән, диләр. Имеш, Суна елгасы арып киткән дә, иптәше Шуядан калып, ял итәргә уйлаган. Бераздан Шуядан шактый артта калуын аңлаган һәм бар көченә томырылып чаба башлаган. Күзенә ак-кара күренмичә ике атлап, бер сикереп чапканда кыяларны җимергән, ташларны кузгаткан һәм нәтиҗәдә, Кивач шарлавыгы барлыкка килгән...

Якташыбыз Гавриил Романович Державин үзенең «Шарлавык» («Водопад») шигырен язгач, Кивач аеруча танылып китә. Державинны ул үзенең көтелмәгән ягы белән шаккаттыра: Суна елгасы тыныч кына агып килә дә, бер мизгелдә кинәт аска томырыла.

Шарлавыкка бару юлында Россиядәге беренче шифаханә – 1719 елда эшли башлаган Марциаль су ку-рорты урнашкан. Әлеге минераль чишмәләрдә Петр I дә шифа тапкан, ул биредә берничә тапкыр булган. Без дә чишмә суларын татып карадык: төрлесеннән төрле дәрәҗәдә тимер тәме килә. Ә урыны – шәп!



Петрозаводскида өч көн кунак булганнан соң кайтыр юлга – Питер тарафына кузгалдык. Юлыбыз Ладога күле буенда урнашкан, фин чигеннән ерак булмаган Сортавала шәһәре аша уза. Шәһәргә кайчан нигез салынуы турында төрле чыганаклар төрлечә сөйли. Рус чыганакларында ул 1468 елларда искә алына башлый. Ни өчен бу шәһәрдә тукталырга булдык соң? Минем үземне, мәсәлән, төрле чорларда төрле халыклар, илләр кул астында булып, төрле мәдәниятләрне берләштергән булуы җәлеп итте. 1617 елда ул Швеция составына кертелә, 1646 елда шәһәр статусын ала. 1705 елның гыйнварында Төньяк сугышы барышында өч көнгә рус гаскәрләре тарафыннан алына. 1721 елда Ништадт тынычлык килешүе буенча Иске Финляндия һәм Сордавалла (ул вакыттагы аталышы) Россиягә күчә, һәм яулап алынган территориядә Выборг провинциясе барлыкка килә. Төньяк сугышы шәһәрне хәрабә хәленә җиткерә, кабат 1783 елда гына Бөек Екатерина II тарафыннан ул шәһәр статусын ала. 1811 елда Выборг губернасы Финляндия Бөек кнәзьлек составына кертелә (ул вакытта Финляндия кнәзьлеге Россия составында була). XIX гасыр ахырында биредә яшәүчеләрнең күпчелеген финнар тәшкил итә. Бу тарих шактый катлаулы һәм четерекле.

1939 елда Кышкы сугыш башлана. 1939 елның декабреннән 1940 елның февраленә чаклы совет авиациясе Сортавалага бер-бер артлы һөҗүм итеп тора. 1940 елның 2 февралендә бомбалар яңгыры аеруча көчәя. Төп халык, сугыштан качып, Финляндия эченәрәк күченә. 1940 елда Мәскәү килешүе буенча шәһәр Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы составында СССРга кертелә. 1990 елда Сортавалага Россиянең тарихи шәһәре дигән статус бирелә. Финнәр калдырган шәһәргә СССРның төрле республикаларыннан халык күченеп утыра. Менә нинди аяныч язмышлы шәһәр...

Шунысын да әйтергә кирәк, бу шәһәрдә кайчандыр татарлар да яшәгән. Бөек Ватан сугышы башлангач күбесе ничек тә кире туган якларына кайтырга тырыша. Каләмдәшем Люция Шәрәфиева миннән шәһәрдә сакланып калган иске йортларны фотога төшереп җибәрүемне сорады. Аларның Олы Кибәче авылыннан да (Саба районы) берничә гаилә яшәгән бу шәһәрдә. Үзебезнең нәселдә дә туу турындагы таныклыгына «туган җире – Сортавала шәһәре» дип язылган Фидус абый бар. Күңеле тулган чакларда ул: «Мин бит Финляндиядә туганмын», – дип сыкрап ала.

Бу шәһәрдә яшәүчеләр арасында аның үткәне турында уйлаучылар күпмедер – белмим. Кызганыч, без булганда музейлар ябык иде әле, күп нәрсәне күрә алмадык. Әмма юлыбыз ачык музей – финнар зираты яныннан узды. Монысын инде тарихтан беркем дә сыза алмый...

Сортавала районында «Рускеала» тау паркы урнашкан. Әлеге туристлык комплексының төп объекты – грунт сулары белән тулган элеккеге мәрмәр карьеры. Монда Екатерина II идарә иткән чорда мәрмәр ташын чыгару эшенә керешәләр. Дүрт төрле мәрмәр чыгарыла – көл төсендә, яшькелт-соры, аксыл һәм аксыл зәңгәр-соры. Таш чыгаруда биш йөзләп кеше эшли. Рускеалы мәрмәре Исаак, Казан гыйбадәтханәләре төзелешендә, Эрмитажның тәрәзә төпләрен ясаганда, Мәрмәр сарайны, Михайлов замогы фасадын эшләгәндә, XX гасырның икенче яртысында Санкт-Петербург метрополитенының «Приморская» һәм «Ладожская» станцияләре залларын салганда кулланыла.

Бүген исә паркта өлкәннәр дә, балалар да рәхәтләнеп ял итә. Кайчандыр мәрмәр таш киселгән мәгарәләр бүген – тылсымлы бер дөнья, көймәләргә утырып җир астын карап йөри аласың. Анда һәрвакыт салкын, җылылык нибары 7 градус. Тау өстендә исә күңел ачу өчен ни генә юк. Теләсәң, аркан буйлап карьер өстеннән «очып» үтәргә, көймәләрдә утырып йөзәргә, чүлмәкчеләрдән осталыкка өйрәнергә һәм тагын әллә нинди кызыклар табарга була. Җир асты күлләре «җырлап тора». Әмма туристларны иң җәлеп иткәне – мәгарәләр. Гаҗәп бит: адәм баласының җир астын кереп күрәсе, аннан соң кабат якты дөньяга чыгасы килә...

Әлбәттә, күргәннәрне һәм тойганнарны бер язмага гына сыйдырып бетерү мөмкин түгел. Карелиягә бару – тормышымда бер вакыйга. Мин әле бу сәяхәтне дәвам итәргә телим. Беләм, ачасы утрауларым, тоясы кичерешләрем калды. Минем әле Ак диңгезгә барып җитәсем бар! Аннан соң – күз күрер...

PRESSA

«ХАТЫНЫМНЫ ӘНИ ОШАТЫРГА ТИЕШ ИДЕ...»



Илназ ФАЗУЛЛИН,
«Ялкын» журналының баш мөхәррире;
гаилә стажы – 18 ел;
балалар – Ләйсән (16 яшь),
Газиз (3 яшь), Гайшә (1 яшь).

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Минем өчен, беренче чиратта, хатын-кызның сылу, төз гәүдәле булуы мөһим. Ә кием-салым, чәчләр шушы матурлыкны бизәп торучы өстәмә буларак кына кабул ителә. Һәм шушыларның комплексыннан хатын-кызның образы тулы булып күз алдына килеп баса.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Дөньяны ир-атлар алып бара, шуңа да алар нәрсәнедер хәл итәргә кирәк булганда, алдан бөтен якларын да җентекләп уйлап, аннары гына гамәл кыла. Хатын-кызлар исә киресенчә: уйлыйлар да, шул ук минутта эшләп тә куялар. Башкаларда гамьнәре юк! Кечкенә генә мисал. Машинамны куярга буш урын эзлим – бездә бит кая барсаң да парковка проблемасы. Таптым кая куярга икәнен, әзерләнә башладым. Һәм шул вакыт, алдыма икенче машина кереп, әлеге буш урынга басты. Рульдә – хатын-кыз. Ир-ат бит беркайчан болай эшләмәс иде... Әмма хатын-кызга сүз әйтеп булмый – тыныч кына икенче урынны эзләп киттем. Аларның мондый вак-төяк «гаепләренә» күз йомасың да, кичерәсең инде.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Алдауны. Бу якын кешеләргә дә кагыла, башкаларга да. Алдау дигәндә барысын да күз алдында тотарга кирәк: моңа хыянәт тә керә, ниндидер астыртын гамәлләр дә... Мондый очрак булса, гадәттә, чит кешеләр белән араны гына өзәсең. Ә якын кешеләрең белән нишлисең? Бүтән бу күренешне булдырмаска тырышасың. Ә, гомумән, мин үзем пацифист, шуңа күрә бөтен әйберне акыл белән кабул итәргә тырышам.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Ул, мөгаен, ир-атның яшь үзенчәлегенә карап үзгәрәдер. Мәсәлән, яшьрәк чакта, шәхсән минем өчен яңа үрләргә илһамландыручы хатын-кыз якынрак иде. Ә аннан – ир уртасына җиткәч, тормышның җитди этабына керү белән бәйледер инде бу – хуҗабикә хатын-кыз беренче урынга чыкты. Хәер, гаиләдә балалар арту белән дә бәйледер ул миңа калса. Аңлыйсың – балалар өчен әнидән дә кадерле кеше юк. Шуның өчен әниләренең алар янында булуын чын күңелдән телисең.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Танышлар арасында ир белән хатынның шулай дус булып, бөтен әйберне дә уртага салып сөйләшкән, бер-берсеннән бернәрсә яшермәгән мисаллар бар барын. Мөнәсәбәтләр турында түгел, күбрәк тормыш итү мәсьәләләрен уртага салып сөйләшү турында бара сүз. Ә мин башкача уйлыйм. Әйткәнемчә, ир-ат – ул табучы, гаиләсен караучы, аны бөтен яктан да саклаучы-яклаучы ролен үти. Һәм ул хатын белән берничек тә бер дәрәҗәдә түгел. Шуның өчен алар арасында дустанә мөнәсәбәт була алмый, минемчә.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Бу вакыйганы бөтен төгәллекләре белән хәтерләмим инде... Без Ландыш белән студент чакта таныштык, бер тулай торакта тордык, бер үк уку йортында белем алдык. Гел бергә идек: көндезләрен дә, кичләрен дә. «Тормыш корырга вакыт җитте», дигән уртак фикергә килгәнне сизми дә калдык. Без студент чакта ук өйләнештек. Миңа – 21, Ландышка 20 яшь иде. Аңа тәкъдим ясавым ниндидер романтик вакыйга булмады. Шунысын гына хәтерлим, авылга әниләргә: «Әти-әни, мин өйләнәм, җәйгә туй ясыйбыз», – дип хат язып җибәрдем. Кесә телефоннары юк иде бит әле, ә каникулны көтәсе килмәгәндер инде...

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Әйе, килешәм, шәхсән минем очракта нәкъ шулай булды. Бигрәк тә безнең кебек, егетләр генә үскән гаиләләрдә шундый күренеш күзәтеләдер кебек тоела. Алар кайчак максатчан рәвештә, ә кайчак үзләре дә аңламыйча шулай эшли: бар яктан әнисенә охшаган кызны сайлый. Тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы, холык-фигыле, уңганлыгы әнисен кабатласын. Алар өчен идеал – әни бит. Ә минем

кечкенәдән үк күңелдә тагын «әнигә ошарга тиешле хатынга өйләнергә тиешмен» дигән уй да бар иде. Бу уңайдан әнигә бәхет елмайды, ул киленен бик ярата, хөрмәт итә...

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Андый гаиләләр бар инде ул, тик минем үз даирәмдә сирәк. Моны нормаль күренеш дип санамыйм. Ир кеше теләсә кайсы очракта да күбрәк эшләргә, мал табуның яңа юлларын эзләргә, табарга тиеш. Гаиләнең төп зур чыгымнарын ул хәл итә, ә хатын-кыз үзенең хезмәт хакын вактөяге өчен генә дә тота ала. Киресенчә икән, нинди киңәш бирергәме? Әйттем инде, булганы белән канәгатьләнмичә, тагын да күбрәккә омтылырга кирәк мондый ир-атларга. Ә хатыннары аларга рухи яктан ярдәм итсен, көч бирсен, канатландырсын.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Бик әйбәт карыйм. Ике яраткан йөрәкнең кайсы үзендә әлеге хисне аңлатырга кыюлык таба һәм моңа әзер булуын аңлый – шул кеше беренче адымны ясый. Моның бернинди ояты юк.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Ландыш миңа караганда күпкә иҗадирак, «очып йөри» дисәм дә ялгыш булмас. Озак еллар балалар өчен «Тылсымлы куллар» журналы нәшер итүе дә күп нәрсә турында сөйли... Бер генә мисал. Чыгышыбыз белән икебез дә Казаннан ерак районнардан: мин – Актаныштан, ул – Тукайдан. Туган якка кайтып җитү өчен кимендә дүрт сәгать вакыт кирәк. Ә юл – һаман бер үк. Күз алдына китерегез, елга ничә тапкыр шушы трассадан узабыз, ә ул чама белән дә безнең кая җиткәнебезне әйтә алмаска мөмкин. Бу юлның һәр чокырын, борылышын, сикертмәсен ятлап бетерергә вакыт бит. Минем карашка бик гади булган әйбернең Ландышка шулай авыр бирелүен берничек аңлый алмыйм. Бу хәтта кайчак ачуны да китерә. Безнең арада: «Ничек истә калдырмаска мөмкин?» – дип бәхәс тә куба.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?

– Юк, үземнекен аңлатырга тырышам, ахырга кадәр үз сүземнән кире кайтмыйм. Әгәр миндә 100 процентлы дәлилләр булса – бигрәк тә. Кыскасы, юл бирмим. (*Көлә.*)

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора.

– Мондый очраклар өченче бала тугач ешаер дип уйлаган идем. Тик, шөкер, Ландыш барысына да өлгерә: балаларны карарга да, өй эшләрен башкарырга да, мин эштән кайтуга көн саен диярлек өстәл тулы ризык әзерләргә дә... Гомумән, мондый очраклар безнең тормышта булганын хәтерләмим дә. Ә инде булсамы? Заказ бирү яки якын-тирәдән генә нәрсәдер алып кереп, тамак ялгауны кулайрак күрәчәкмен. Бөтенләй пешерә белмим дигән сүз түгел бу. Студент чакта безнең өчен берәү дә әзерләмәде. Аннан без гаиләдә дүрт ир бала үстек. Әни үзе генә барысына да өлгерә алмый иде, билгеле. Идән дә юдык, савыт-саба да. Бәрәңге, макарон, ярмалардан төрле боткалар да пешерергә туры килде. Тик аерым, яратып әзерләгән ризыгым бар дия алмыйм: тотынсам йә бәрәңге кыздырам, йә йомырка тәбәсе. Анысы да бик килеп терәлгәндә генә. Дөресен әйтәм, мин андый эшкә ялкаурак.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

– Ачуны китерә, кайбер чакта бик нык китерә. Мин тормышта һәр ситуациядән дәрес алырга күнеккән. Шуның өчен берничә тапкыр мондый хәл кабатлангач, хәзер каядыр барасы булганда, хатынга да, балаларга да алдан ук әзерләнергә кушам. Соңга калу – ул синең җаваплы булмаганыңны күрсәтә торган билге. Бу минем күңелгә тия. Менә ни өчен моны булдырмаска тырышып, аларны алдан киенергә, әзерләнергә өйрәтәм дә. Күп очракта килеп чыга. (*Көлә.*) Гомумән, мин тыныч кеше. Беренче очрактан гына ачуланмыйм. Бер үк әйбернең күп тапкыр кабатлануы гына мине чыгырдан чыгарырга мөмкин.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Тулай торакта яшәгәндә, әле егет белән кыз чагында, ялгышмасам, Яңа елга Ландыш футболка бүләк иткән иде. Үзенең сурәте белән. Мин аны бер генә тапкыр кидем. Бүләк иткәч, киеп фотога төштек тә, салып куйдым: аннары ул футболканың язмышы миңа билгесез. Бик ошатып бетермәгәнемне Ландыш та аңлады, һәм без алга таба һәрвакыт килешенеп, кемгә нәрсә кирәген белеп, бүләккә шуны гына ала башладык. Ә өйләнешкән беренче елларда, бер-беребезгә бүләк бирешмичә, гаилә өчен дип, уртак бүләк ала идек. Электр чәйнегеннән башлап, йорт җиһазларына кадәр. Телевизор, шкаф-купе, диван...

Ә иң ошаган бүләгем... (*Көлеп җибәрә.*) Бер елны туган көнгә ул мондый бүләк эшләде: алдан әйтмичә генә, мине каядыр алып китте. «Әзер булып тор, бер җиргә барачакбыз», – диде. Мөгаен, бу ресторандыр, төшке ашка чакырадыр дип уйладым – шуңа әзерләндем. Киттек. Нинди дер таныш булмаган адрес әйтте. Барып җиттек: якын-тирәдә кафе-рестораннар күренми... Стоматология клиникасы ишек төбенә килеп туктадык без. Мин теш табибларына йөрергә бик куркам, ә ул аны яхшы белә. Үз теләгем белән анда беркайчан да бармыйм: теш бик сызласа, түзәр чама калмаса гына ишекләрен ачып керәм. Ул, миңа алдан әйтмичә генә, теш табибына приемга яздырган булып чыкты.
Ни чарадан бичара керергә мәҗбүр булдым инде. Әмма бик ачулы идем. Табиб каршына барып, креслога утырсам да, авызымны ачмадым – барыбер баш тарттым – дәвалауны башка көнгә күчердем. Бүләкне әрәм итеп булмый бит инде... Анысында инде рухи яктан әзер булып бардым. Әмма Ландышның бу бүләген «ошаган бүләк» дим: соңыннан аның бик кирәкле, файдалы икәне аңлашылды бит. Хәер, мин аны башта да акыл белән аңлый идем, тик ул моментта теш табибыннан курку хисе көчлерәк иде шул...

Тулысынча укыгыз »





Бала эче авыртудан зарланса, кайсы әти-әни генә хафага калмас икән? Эч бик күп сәбәпләрдән авыртырга мөмкин. Кайчак ул үт юлларындагы проблемалар белән бәйле булып чыга. Республика балалар клиник хастаханәсенең көндезге стационар мөдире, балалар табибы-гастроэнтеролог Наталья ГАЙБАРЯН белән сүзебез балаларга еш куелучы диагноз – үт юллары дискинезиясе хакында.

БАЛАНЫҢ ЭЧЕ АВЫРТСА...

Үт юллары дискинезиясе, атамасыннан күренгәнчә – үт сыекчасының үт юллары аша уникеилле эчәккә үз вакытында барып ирешү функциясе бозылу ул. Үт сыекчасы ашкайнату процессында алыштыргысыз роль башкара, эчәклекләрнең эшчәнлеген көчәйтә, матдәләр алмашын көйли. Үт куыгында җыелып торган үт сыекчасы куера, тора-бара ялкынсыну процессы башланырга, ташлар оешырга мөмкин. Үт юллары дискинезиясе, нигездә, 3 яшьтән өлкәнрәк балаларда күзәтелә. Төгәл диагнозны бары тик табиб кына куя ала. Кан анализы аша гына үт юлларындагы тайпылышларны тулысынча ачыкларга мөмкин түгел. УЗИ да үт юллары һәм сфинктер аппаратының функциональ халәтен тулаем күрсәтә алмый. Үт юлларындагы функциональ үзгәрешләр башлануын, рефлюксларны, үт куыгының тиешенчә эшләмәвен динамик холесцинтиграфия яхшырак күрергә мөмкинлек бирә.

Үт юллары дискинезиясен дәвалау туклану режимын һәм диетаны төгәл үтәүне таләп итә. Табиб үт кудыргыч препаратлар, ашкайнату ферментлары, физиодәва чаралары билгеләргә мөмкин. Составында үт сыекчасы яки үт кислотасы булган препаратларны ашказанында җәрәхәт булганда, ашказаны асты бизе ялкынсынганда, бавыр чирләре вакытында куллану тыела. Менә шуның өчен дә үзбелдегең белән дәвалану бик хәтәр. Табиб киңәш итсә, минераль су белән тюбажлар ясарга була. Уртача минеральләшкән шифалы сулар кулланырга мөмкин. Аның күләмен дә табиб билгели.

Дискинезиянең билгеләре

- уң як кабырга астында авырту тою. Авырту төрлечә булырга мөмкин: чәнчү, сыкрау. Йөргән вакытта ул көчәя;
- кыздырган, майлы, ачы ризыклар ашаганнан соң баланың хәле авырая: күңел болгану, укшыту, аппетит булмау;
- хәлсезлек, тирләү, йөрәк кагу;
- баланың еш кикерүе, авызда әче тәм булу;
- баланың тәрәте бозылу.



Рөхсәт ителә





- каты сортлы бодайдан ясалган макарон ризыклары;
- ярмалар;
- сөт һәм сөттә пешкән боткалар;
- тозлы булмаган сыр;
- чикләнгән күләмдә атланмай һәм үсемлек мае;
- омлет, чиле-пешле йомырка;
- искерә төшкән икмәк;
- майсыз балык һәм майсыз ит;
- яшелчә, җиләк-җимешләрне пешереп ашау яхшырак. Тазәләрен угычтан уып кулланырга мөмкин.
- Рационда клетчаткага бай ризыклар булсын. Болар: кузаклылар һәм бөртекле культуралар. Яшелчәләрдән – порей сугань һәм баклажан, җимешләрдән – алма, киви, груша.

Төп кагыйдәләр

- Көненә алты тапкырдан да кимрәк ашамаска! Организмга кечкенә порцияләрне эшкәртүе җиңелрәк.
- Билгеле бер вакытта гына тукланырга! Бу үт бүленеп чыгуны көйләргә ярдәм итә, спазмнарны кисәтә.
- Ризык мөмкин кадәр җиңел булсын! Иң яхшысы: парда яки суда пешерү.
- Авыру кискенләшмәгән чорда томалап пешерергә дә була. Кыздырылган ризык, гомумән, тыела.
- Ризык җылымса булсын! Кайнар һәм салкын ризыклар үт куыгы стеналарын ярсыта.
- Суны көненә 2 литрдан да кимрәк эчмәскә! Су үтне сыеклый, ул тизрәк бүленеп чыга.

БУ МӨҺИМ: үт юллары белән проблемалар булганда ач тору катгый тыела! Хәтта йокларга ятар алдыннан да берәр җимеш булса да кабып куярга кирәк. Дискинезия өзлегүләргә китерүе белән хәтәр, һәм бу турыдан-туры туклануга бәйле.



ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Халык аны йөрәк кагу, йөрәк сикерү, йөрәк хәлсезләнү дип йөртә. Медицина телендәге атамасы – аритмия. Сәламәт йөрәкнең тибеше синус ритмына тәңгәл. Шушы ритмнан үзгә теләсә кайсы тайпылыш аритмия дип бәяләнә. Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсенең кардиолог-аритмологы Денис ШАМЕС белән сүзебез аның барлыкка килү сәбәпләре, билгеләре, дәвалау ысуллары турында.

ЙӨРӘК НИГӘ КАГА?

Аритмия – йөрәк тибешенең дөрес ритмы бозылу. Аның төре күп, тибрәнүле – «мерцательная» дигәне ешрак күзәтелә. Йөрәк тибеше минутына 60–90 тапкыр кабатланганда норма санала. Ә тибрәнүле аритмия вакытында ул минутына 700 тибеш тә ясарга мөмкин. Йөрәк тибешенең тизләнүен кеше электрон тонометр белән кан басымын үлчәгәндә дә күрә ала. Электрокардиограмманы, Холтер аппаратын диагностика чаралары буларак әйтеп үтәргә була. Төгәл диагнозны, әлбәттә, бары тик табиб кына куя.

Тибрәнүле аритмиянең куркынычы шунда – сул йөрәгалдында тромблар барлыкка килергә һәм, вакытында диагноз куелмаган очракта, инсультка китерергә мөмкин. Йөрәк эшчәнлеге кинәт кенә бозылса, кеше күкрәк читлегендә авырту тойса, тыны кысылса, салкын тир бәреп чыкса, кичекмәстән «Ашыгыч ярдәм» чакыртырга кирәк. Кайбер төр аритмия махсус дәвалауны таләп итми. Ә менә йөрәк ритмының кеше гомеренә куркыныч янарлык дәрәҗәдә бозылуы аритмияне көйләүче препаратлар билгеләүне таләп итә. Андый препаратлар булышмаган очракта, операция ясала. Брадиаритмия күзәтелгәндә бердәнбер дәва методы – электрокардиостимулятор урнаштыру. Тибрәнүле аритмия вакытында, инсульт барлыкка килү куркынычы зур булганда пациент еллар дәвамында кан сыеклаучы препаратлар кулланырга мәҗбүр.

Аритмиянең барлыкка килү сәбәпләре

- иң беренче сәбәп – йөрәк ишемиясе, ягъни йөрәк мускулларына кислородның җитәрлек күләмдә барып җитмәве;
- миокард инфаркты;
- калкансыман биз авырулары;
- югары кан басымы;
- кардиомиопатия;
- хроник йөрәк зәгыйфьлеге;
- исерткеч эчемлекләр белән чамасыз артык мавыгу;
- йөрәкнең ялкынсынуы;
- тумыштан килгән йөрәк җитешсезлекләре;
- организмда натрий, калий һәм магнийның артык күп булуы.

Аритмиянең билгеләре

- йөрәк тибешенең ритмы тизләнү;
- йөрәкнең әле тизрәк, әле сүлпәнрәк тибүе;
- йөрәк тукталып torгандай тоелу;
- хәлсезлек, баш әйләнү;
- колак шаулау;
- күз күременең җетелеге киму.

Ничек кисәтергә

- йөрәкнең сәламәтлеген тәмәке һәм исерткеч эчемлекләр бетерүен онытмагыз;
- гәүдәнең авырлыгын гел нормада тотарга тырышыгыз;
- җитәрлек хәрәкәтләнү бик мөһим;
- физик нагрузкалар көч китерерлек булмасын;
- эш һәм ял, йокы режимнарын саклагыз;
- тукланууга игътибарлы булыгыз.



Моны белү мөһим

Аритмиядән ниндидер аерым диета юк. Йөрәк-кан тамырлары авыруларын кисәтү өчен тәкъдим ителүче диета аритмиядән дә шифа бирә. Аның нигезен яшелчә, җиләк-җимеш, бөртекләр, балык, кош ите һәм майсыз сөт ризыклары тәшкил итә.

Йөрәк эшчәнлеге бозылганда кофеин һәм тоз күләмен чикләү мөһим. Иртәнге кофесыз күз алдына китерә алмаучылар, табиб белән киңәшеп, аны тәүлегенә 300 мг гына куллана ала.

Тибрәнүле аритмия гәүдә авырлыгын нормада тотуны таләп итә. Кулланылган калорияләргә игътибарлы булыгыз. Хәзер смартфоннар өчен ризыкларның калорияләрен исәпләргә ярдәм итүче кушымталар бар.



Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Гөлнара Тимуршина ярдәме белән әзерләнде.

ҖИҢНӘРНЕ СЫЗГАНЫЙК

Гыйнварга кердек. Урамда кар ятса да, тәрәзә төбендәге «бакчабызда» эшләр җитәрлек. Бүлмә гөлләре дә тәрбияләүгә мохтаҗ, озак тишелүчән орлыклар чәчүне дә ашыктыра торырга була. Кемдер, бәлки, язгы бәйрәмгә тәрәзә төбендә лаләләр үстерергә кызыгадыр. Бу эшләргә хәзердән үк керешә башлыйк. Орлыкларны, ашламаларны, корткычларга каршы препаратларны барлыйк, яңа сортларны өйрәник. Яз көттермәс, килер дә җитәр.

Бүлмә гөлләре

Гыйнвар ае бүлмә гөлләре өчен иң авыр вакыт: һава коры һәм эссе, кояш яктысы аз... Бу чорда гөлләр өстәмә яктыртуга һәм һаваны даими дымландырып торуга мохтаҗ. Күпчелек гөлләр температураның 16–18 градус җылы булганын ярата. Алар салкынча һавага да чыдам, ләкин бу очракта суны сирәк сибәргә кирәк.

Кыш көне дә чәчәк атучы сенполия, цикламен, азалия, зигокактус, примулалар да үзләрен 16–18 градус җылыда яхшы хис итә. Тагын да югарырак температурада алар чәчәкне ашыгып атып бетерә. Озын булып үсеп киткән гөлләрне кыш көне бөре өстеннән кыскартып кисәләр. Кискәннән соң, алар тармакланып, куерып китә.

Якыннарыгызны сөендерер өчен, хәзердән үк лалә, сөмбел (гиацинт), крокус һәм нәркиз суганчаларын чүлмәккә утыртырга була. Дөрес, алар инде 8 Март бәйрәменә өлгермәс, быел тәҗрибә туплый торсагыз, киләсе елда Яз бәйрәмен үз чәчәкләрегез белән каршы алырсыз. Өйдә үстерер өчен суганчаларның зуррагын, авыррагын сайлагыз. Туфрак урынына чиста елга комы яки аның торф белән катнашмасын куллану отышлырак. Суганчаларны туфракка утырткач, сортына карап, аларны 16–22 атна салкынча (+3, +5 градус), караңгы урында тоталар. Туфрак гел дымлы булсын, ләкин артык юешләргә ярамый. Бәйрәмгә дүрт атна кала, чүлмәкләрне җылылык +15 градус булган якты урынга күчерәләр. Тизрәк чәчәк аттыру өчен, температураны күтәрәләр, чәчәк атуны тоткарларга теләсәгез, салкынчарак урынга күчерегез. Лаләләр 10 сәгатьлек яктыртуга мохтаҗ. Тагын бер сере: бу гөлләр бик салкын су сипкәнне ярата. Чәчәк аткан суганчаларны ташламагыз, яз көне бакчага күчерерсез.



Җимеш «бакчасы»

Өегездә лимон, мандарин, кофе, дәфнә (лавр) үстерергә хыяллансагыз, аларның орлыкларын менә хәзер – гыйнварда ук утырталар. Утыртыр өчен яңа гына авыз иткән җимешнең эре төшләрен сайлап алыгыз, чөнки алар тишелешләрен тиз югалта. Орлыкларны туфракка күмдергәнче,



«Эпин-Экстра» кебек бирәр стимулятор эремәсенә салып торсаң яхшы. Баштагы чорда чүлмәкнең кечерәген дә сайлый аласыз. Туфрак көпшәк, уңдырышлы булсын. Аска калын итеп дренаж салып калдырыгыз. Орлыкны 1–1,5 сантиметрга гына күмдерәләр.

Кофе үстерергә теләсәгез, орлыгын махсус сатып алырга кирәк. Кибетләрдәге кофе моның өчен яраксыз. Кофе агачы җылылыкны һәм дымлылыкны ярата, даими су сибеп торуны, кояш нуры җитәрлек булуны таләп итә.



Яшелчәчегә

Теплицасы булганнарга борыч, баклажаннарның соң өлгерешле сортларын чәчүне инде кайгырта торырга мөмкин. Аларның вегетация чоры бик озын. Озак тишелешле үсемлекләрне дә иртәрәк чәчәләр. Әйтик сельдерей, порей суганы, петунияне...

Ремонтант бакча җиләге үстерергә кызыксагыз, аны да хәзер чәчегез. Иң кулай вариант – савыттагы туфрак өстенә кар түшәп, орлыкларны кар өстенә чәчү. Әлеге ысул барлык вак орлыклар өчен отышлы. Туфрак белән күмдерсәң, алар тишелмәскә мөмкин.

Язын организмны витаминнар белән баету өчен тәрәзә төбендә хәзердән үк аш тәмләткеч үләннәр үстерергә була. Мәсәлән, рукола, кресс-салат, салат-латук, сарепта горчицасы, шпинат, рәйхан (базилик), петрушка... Ләкин, әйткәнебезчә, кыш көне үсемлекләр өстәмә яктыртуга мохтаҗ. Суны исә ике көн тондырып, җылымса килеш сибәргә, бирәр тапкыр азотлы ашлама белән тукландырырга мөмкин.

Күрәсез, кызыксынган кешегә кыш көне дә «бакча»да эш бар. Уңышлар телибез сезгә!

Фото: www.pixabay.com



«ӨЧЕНЧЕ ИЯК»ТӘН КОТЫЛЫП БУЛАМЫ?

Яшь барган саен, борын тирәсе мускулларының тонусы бетеп, бит төшә: «өченче ияк» килеп чыга. Йөзнең контуры үзгәрә. Ә аны бер-ничек тә яшереп булмый. «Өченче ияк» чыкса, бердәнбер чара – матурлык уколлары. Әмма алдан профилактик чарасын күрсәң, кыйммәтле уколлар да кирәк булмас. Мондый дефектны булдырмас өчен, иң яхшы профилактика – массаж. Профессиональ массажист-ларга йөрергә җаегыз юк икән, өйдә үзегез ясагыз. Моның өчен 20 минут вакыт җитә. «Телевизордан кино, ютубтан тапшыру караганда ике эшне берьюлы эшләп була, – ди массажист Әдилә СЕРМЯГИНА. – Бары теләк кенә кирәк».





1. Массаж ясар алдыннан битне, муен тирәләрен косметикадан әйбәтләп чистартабыз. Косметика булмаган очракта да, юып алырга кирәк.

2. Массаж ясаганда төрле майлар куллану яхшы. Файдалы да, май сөрткәч кул да шуып кына йөри – тире тартылмый. Әмма миндаль маен кулланмагыз. Ул биттәге төкләрне үстерә. Майны учыгызга салыгыз да әкрен генә битегезгә тидерегез.

3. Массажны муен тирәләре мускулларын йомшартудан, лимфа төерләре урнашкан урыннарны әкрен генә баскалап алудан башлыйбыз. Декольте зонасын, муенны сыпырабыз.

4. Баш бармак белән имән бармаклардан ыргак формасы ясыйбыз да, иякне «ыргаклар белән каптырып», мускулларны кысабыз.





5. «Өченче ияк» барлыкка килмәсен өчен, борын тирәсе мускулларының тонуста торуы шарт. Шуңа күрә ул мускулларны, түгәрәк хәрәкәтләр ясый-ясый, бармак битләре белән баскалыйбыз. Аннан соң имән бармаклар белән борын тирәсен ышкыйбыз. Болар барысы да әкрен генә ясала.



6. Ирennнәрдән «пилмән бөгәбез». Көлмәгез! Бу кисетлы мускулларны тонуска китерү өчен эшләнә.



7. Йөз мускулларын тынычландыру өчен авыз эченнән дә массаж ясыйлар. (Хәзерге вакытта популяр булган буккальный массажны шул рәвешле эшләгәннәрен инстаграмда күргәнегез бардыр.) Перчаткалар кияргә онытмагыз! Авыз куышлыгының бар җирен, түгәрәк хәрәкәтләр ясый-ясый, бармак белән баскалап чыгыгыз. Бәлки, төерләр тоярсыз. Курыкмагыз. Бу – мускуллар дөрес эшләмәгәннән килеп чыккан гап-гади хондрозлар. Аларны ышкып бетерергә була.



8. Тагын бер күнегү. Елмаясыз, әмма ирен читләрен тотып, елмаерга ирек бирмисез.

9. Һәр күнегүне өч-дүрт минут эшләгез.

10. Кабат муен тирәләрен сыйпап, тәмамлыйбыз.



Онытмагыз: массажны һәр көн эшләсәгез генә файдасын күрерсез. Бит «уянган»нан соң, төрле битлекләр ясау да киңәш ителә. Нәтиҗә тагын да яхшырак булачак.

Матур булыгыз!

Фото: Анна Арахамия



Массаж күнегүләрен QR-код аша кереп, видеодан да карый аласыз.

Балалар бүлмәсе

Балалар бүлмәсе матур гына түгел, уңайлы да булырга тиеш! Балалар тиз үсә, кызыксынулары арта, шуңа күрә аларның бүлмәсен еш кына үзгәртеп торырга туры киләчәк. Һәр олы кеше кебек үк, баланың да вакыт-вакыт аулакта каласы килә. Аның үз бүлмәсе булу шуңа да бик мөһим. Үз почмагына бала – үзе хуҗа. Балалар бүлмәсен оештыруның нинди генә үзенчәлекләре юк! Ә бит без, әниләр, барысын да алдан күреп, белеп оештырырга, уңайлы шартлар тудырырга тиеш. Бу язмада мәктәп укучысы һәм укырга керергә җыенган ике матур кыз яшәүче бүлмәне тәртипкә салырбыз. Өйне тәртипкә салу остасы Елена ТИМИНА булышыр. Бүлмәбез кызларныкы булса да, киңәшләрнең малай үстерүче әниләргә дә файдалы булырлыкларын сайладык.



Раилә ХӘЯЛИЕВА



Шкафлар

Бала кайда нәрсә ятканын белеп торсын өчен, һәр әйберне категорияләргә бүлергә кирәк. Кием шкафы киштәсенең зурлыгына карап, органайзерлар яки кечкенә тартмачыклар кулланырга була. Һәр тартмачыкка нәрсә куелганны язып (яки ясап) ябыштырырга: эчке кием, оекбаш, колготки һәм башкалар. Бу әйберләрне пөхтәләп бергә төрергә дә өйрәнсәгез, шкафта әллә ничаклы урын бушаячак.

Гаҗәпләнерсез, әмма, шкафны бер тапкыр дөрес итеп җыештырып куйганнан соң, баланың аны яңадан туздырасы килмәячәк. Шкаф эчендәге тәртип бүлмәнең атмосферасын да үзгәртергә сәләтле.

Оекбашлар, колготкилар пакетларда сакланса, алар суламый, энергиясе бозыла, шуңа бик тиз туза. Пакет төбендә ни ятканын карап торырга баланың вакыты юк, ә тартмаларга урнаштырганда киемнәр күз алдында булачак.











Фото: Анна Арахамия

БАЛАЛАР БҮЛМӘСЕ ӨЧЕН ЧЕК-ЛИСТ:

✓ Бүлмәне балалар белән бергә җыештырырга гадәтләнегез. Өй җыештыру дигән сүздән бала борынын җыерса, җыештыру процессын уен итеп кабул итәргә була. (Мисал өчен, өйне кунакханә итеп күз алдына китерергә.)

✓ Эшне ахырына кадәр җиткерергә өйрәтегез: бер уенчык белән уйнап туйдыңмы, икенчесен алганчы алдагысын урынына куй!

✓ Балалар бүлмәсен ике-өч айга бер тапкыр кирәксез әйберләрдән арындырып торырга кирәк.

✓ Балаларның кызыксынулары бик еш үзгәреп тора. Шуңа күрә кулланылмаган әйберләрне, киелмәгән киемнәрне билгеле бер урынга җыеп барыр өчен аерым тартма билгеләргә.

✓ Музыкаль инструментлар, спорт кирәк-яраклары... Кызыксынулар өчен дә урын булсын!

✓ Бала бүлмәсенә нейтраль төстәге обой сайларга киңәш итәр идем. Мондый обой белән бүлмәне үзгәртсә, яңача «киендерәсе» җайлырак.

✓ Балалар бүлмәсендә буш ара күбрәк, мебель азрак булуы мөһим.

✓ Әйберләр кайда кулланыла, шунда сакланырга да тиеш. (Тарак, чәч кыстыргычлар – көзге янында, карандашлар, буяу, пумалалар – өстәл янындагы киштәдә.)

✓ Һәр әйбер кире үз урынына куелырга тиешлеген балага кечкенәдән өйрәтеп үстерергә кирәк. Кичен, йокларга ятыр алдыннан, 15–20 минутны өйне тәртипкә китерү вакыты дип игълан итәргә була. Аннары ул матур гадәт булып калачак.

✓ Балалар бүлмәсе – аларның шәхси пространствосы, үз почмагы икәнен онытмагыз. Алар янына, ишек шакып, рөхсәт сорап кына керергә кирәк!

✓ Балалар өчен иң зур үрнәк – әти-әни гамәлләре. Пөхтәлекне үзегездән башлагыз!

Дәрес әзерли торган урын

Дәрес әзерли торган почмак бүлмәнең иң якты урыны булырга тиеш. Мөмкинлек булса, бала ишеккә аркасы белән утырмасын. Дивар артында утырса, ул үзен ышанычлырак хис итәчәк.

Көндәлек куллана торган китаплар, дәреслекләр кул сузымында гына торсын. Дәфтәрләрне, өстәмә әдәбиятны вертикаль рәвештә аерым органайзерларга урнаштыру уңайлы. Ә менә буяу, альбомнарны өстәге яки астагы киштәгә куярга да мөмкин. Һәрнәрсәне аерым тартмаларга куеп, ниләр сакланганын язып, ябыштырырга кирәк.







Уенчыклар почмагы

Монда да категорияләргә бүлеп урнаштыру мөһим. Бөтен уенчыкны зур тартмада җыеп сакларга ярамый. Курчаклар, машиналар, өстәл уеннары, леголарның үз урыны булырга тиеш.

Вак уенчыкларны каптыргычлы пакетларга җыеп куярга мөмкин.

Бүлмәдә бала яратып уйный торган уенчыклар гына калсын. Ватылганнарын ташларга, «кечерәйгәннәрен» бүләк итәргә, артыгын бер-ике айга бала күрми торган урынга алып куярга киңәш итә психологлар.

Уенчыклар бала утырып уйный торган урынга якын булырга тиеш.

Иҗат күргәзмәсе

Әниләрнең еш бирә торган соравы: балаларның кул эшләрен, рәсемнәрен кайда сакларга?

Бүлмәгә бау сузып, кыстыргычлар ярдәмендә рәсемнәрне шунда элеп чыгарга киңәш итәр идем. Вакыты белән аларны башка рәсемнәр алыштырыр. Нәни куллар иҗат иткән сәнгать әсәрен килгән кунакларга күрсәтү өчен дә җайлы ысул бу.

Вак машиналар, курчаклар, камырдан, балчыктан һәм башка ысул белән ясалган кул эшләре өчен тар киштәләр уңайлы булачак. Бала үсә төшкәч, уенчыклар урынын китаплар, атласлар алыштырыр.

Барлык кул эшләрен дә саклап бетереп булмый, иң кадерлеләрен генә җыеп куегыз да, калганнарын фотога төшереп, балага сиздерми генә «өйдән чыгарып җибәрегез».



Сырлы котлет белән бәрәңге



Тизлек заманында яшибез. Вакытны бер дә юкка сарыф итәсе килми. Әмма кайчак, аш-су бүлмәсендәге мәшәкатьләргә бирелеп, көннең узганын да сизми калабыз. Бүген сезгә тәкъдим итәргә теләгән ризыгыбыз – вакытның кадерен белүчеләр өчен. Эчлегенә укроп белән сыр салынган котлетларны бәрәңге белән бергә пешерәбез. Аны безгә күпләрнең яраткан җырчысы Илзидә ГОСМАН әзерләп күрсәтте. «Очрашулар, концертлар, гастрольләр... Өйгә вакыт бигрәк аз кала кайвакыт. Әмма гаиләм өчен аш-суны һәрвакыт тәмле итеп әзерләргә тырышам. Сезгә тәкъдим итәсе ризык туклыклы да, җайлы да. Ите дә, гарниры да, яшелчәсе дә үзендә аның!» – ди җырчы-хуҗабикә.

Кирәк

- 2 баш суган;
- 3–4 бәрәңге;
- 2 помидор;
- 250 г сыр;
- 500 г фарш;
- 1 йомырка
- 1 аш кашыгы каймак;
- 2-3 тырнак сарымсак;
- укроп;
- коры ипи валчыгы (сохари);
- тоз, борыч.

Эш барышы

■ Фаршка тоз, борыч, йомырка кушып бутыйбыз.

■ Укропны ваклап турыйбыз һәм өстенә сырның бер өлешен угычтан уабыз, ваклап туралган яки сыткычтан чыгарган сарымсак, каймак кушып, кечкенә шарчыклар ясыйбыз.

■ Азык-төлек өчен кулланыла торган пленкага аш кашыгын өеп фарш салабыз. Уртада аз гына уем ясап,



сыр шарчыкларын куябыз. Һәм аны фарш белән томалыйбыз.

■ Сырлы эчлек салынган котлетны әйбәтләп сохарида әвәлибез.

■ Майлы табага салып, ике ягын да кыздырып алабыз (5–10 минут).

■ Ул арада суганны ваклап турап, мичкә куясы табаның төбенә җәябез. Аның өстенә түгәрәкләп киселгән бәрәңгене таслап тезәбез.

■ Бәрәңге өстенә башта котлетларны, аннан түгәрәкләп киселгән помидорларны тезәбез.

■ Тулыр-тулмас бер стакан су салып, савытның өстен фольга белән томалыйбыз. Ярты сәгатькә 200 градуска кадәр кызган мичкә куябыз.

■ Ризыгыбыз пешеп җиткәч, өстеннән фольганы алып, калган сырны уып сибәбез һәм тагын 4–5 минутка мичкә куеп алабыз.

Тәмле булсын!

«Патшалар салаты»

Кунакларны затлы ризык белән сыйлап сөендерәсе килә. Шундый очрак өчен җырчыбыздан тагын бер күчтәнәч – «Патшалар салаты».

Кирәк

• 200 г тозлы кызыл балык; • 2 пешкән кишер; • 2 пешкән бәрәңге; • 3 йомырка; • кызыл уылдык (икра); • яшел суган; • майонез.

Өстәлгә киң фольга җәябез. Өстенә кишер, бәрәңге, йомырканы катлам-катлам итеп уабыз. Араларына аз гына майонез сылап калдырабыз.

Яшелчәләрдән соң өске катламның бер өлешенә озынчалап киселгән кызыл балыкны тезеп чыгабыз, ә икенче ягына мул итеп яшел суган (укроп, петрушка кушсагыз да була) түшибез. Фольга ярдәмендә әзер салатны рулет итеп төрәбез. Өстенә чак кына майонез сылап, уылдык белән бизибез. Әзер салатны суыткычка куеп торабыз. Салат-рулетны кисеп, тәлинкәдә яшел салат яфрагы өстенә куеп табынга чыгарабыз.



Фото: Анна Арахамия



Дөрес тукланырга тырышучылар яшел карабодай турында яхшы белә. Әлеге ярма үзенең файдалы үзлекләре белән кыйммәтле, һәм үз сәламәтлеген кайгыртучылар табынында аны еш күрергә мөмкин. Андагы витаминнар һәм микроэлементлар таркалмый саклана, чөнки, җентекләп кыздырылган гадәти карабодайдан аермалы буларак, яшел сортлысы термаль эшкәртү узмый.
Яшел ярманың гадәти карабодайдан аермасы бармы, аның файдасы нидә һәм аны ничек кулланалар? Бу хакта безгә дөрес туклану рубрикасының даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА сөйләр һәм яшел карабодайдан икмәк пешерү серләре белән бүлешер.



Яшел карабодай ипие

Яшел карабодайның файдасы:

- Әлеге ярма яшьлекне һәм сәламәтлекне сакларга ярдәм итүче аминокислоталарга бай.
- Ул – антиоксидантлар чыганагы.
- Яшел карабодай гликемияне көйли, аны кулланганнан соң кандагы шикәр күләме артык зур сикерешләр ясамый. Шушы сыйфаты өчен ул шикәр чире белән авыручыларга һәм гәүдә авырлыгын нормада тотарга теләүчеләргә файдалы.
- Андагы клетчатка һәм ризык җепселләре эчәклекләрнең эшчәнлеген яхшырта.
- Матдәләр алмашын тизләтә. Бу исә, үз чиратында, тизрәк ябыгырга ярдәм итә.
- Бу ярма организмнан төрле агулы матдәләрне чыгара.
- Менә дигән иммуномодулятор, ягъни иммунитетны күтәрүче.
- Ул әле витаминнарга һәм микроэлементларга да бик бай, болар исә тирегә, чәчләргә, тырнакларга яхшы йогынты ясый.
- Иң файдалы юл – яшел карабодайны үрдереп куллану. Ярманы 12 сәгать җылымса суда бүрттереп тә кулланырга була. Яшел карабодайны он итеп тарттырып, аннан төрле ризыклар әзерләргә мөмкин.

Яшел карабодайдан ипи:



Безгә бары яшел карабодай, су, бал, тоз һәм бераз вакыт кына кирәк булачак.

Эш барышы:

- 500 г ярманы әйбәтләп юабыз. Юылган ярма өстенә дүрт бармак киңлеге чыгарлык итеп фильтрланган чиста су салабыз (чишмә суы да мөмкин). Аны шул суда бер тәүлеккә калдырабыз. Суны бик нык «йотса», тагын бераз өстибез, безгә суның күләме тәүлек ахырына бер бармак киңлегеннән артыграк булуы кирәк.
- Тәүлек узганнан соң, суын түкмичә генә, ярманы блендер белән (стационар блендер кулайрак) ваклыйбыз. Шунда ук аш кашыгы ярым тоз һәм 1 чәй кашыгы бал өстибез. Яхшылап туглыйбыз.
- Барлыкка килгән массаны савытка салып, тагын бер тәүлеккә җылы урынга куябыз. Ул күперергә тиеш.
- Ипи пешерә торган форманы майлап (мин сары май кулландым), камырны салабыз һәм бер сәгатькә 190 градуска кадәр җылытылган мичкә куябыз.

Менә шулай санаулы гына ингредиентлар һәм бераз вакыт кулланып, файдалы да, тәмле дә ипи пешереп була. Бу рецепт белән пешерелгән ипине хәтта диета тотучылар да куллана ала.

Якыннарыгызны тәмле ипи пешереп сыйлагыз әле!

Фото: Камилә Димөхәммәтова

Кәҗәмөгез хатын-кыз

Ул – Җир стихиясеннән, шуңа күрә кирәгеннән артык практик һәм җир тормышы белән яши. Максаты – һөнәри яктан үсү, тормышта төпле нигез булдыру. Кәҗәмөгез хатын-кызлар һәрвакыт шуңа омтыла һәм моңа ирешү өчен гадәти юллар сайламый. Ул бик уңган, тырыш, һәрвакыт белемен арттырырга тырыша. Тәнкыйтьне авыр кабул итә, әмма колак сала. Тормышта үз көченә ышанып яши.

Кәҗәмөгез хатын-кыз сирәк булса да күңел төшенкелегенә бирелеп ала. Мондый чакта чынга ашмаган хыяллары җанын телгәли, гомернең артык тиз узуына борчыла. Депрессиядән качар өчен аңа күбрәк шат күңелле кешеләр белән аралашырга, буш вакытын актив спортка багышларга кирәк.

Мәхәббәт. Югары мәхәббәт хисләре һәм романтика – бу йолдызлыкта туган хатын-кызларга һич туры килми. Эмоцияләрен, хисләрен уңга-сулга сибеп йөрүчеләрдән түгел ул! Җаваплылык – Кәҗәмөгез хатын-кызның иң матур сыйфаты. Партнерын да зур җаваплылык белән сайлый. Әмма яратмаган кешесе белән гаилә кора алмаячак. Ә менә Кәҗәмөгез туташлар гашыйк булсалар, бар дөньяларын онытачаклар. Тик ир-атларны назлы сүзләргә күмүен көтмәгез инде! Кучкар, Кәҗәмөгез, Кыз, Чаян йолдызлыгында туган ир-атлар алар өчен пар була ала. Күңеленә хуш килгән ир-атны бик җиңел генә үзенә каратып, гаилә бәхетенә төренеп яши, диләр аның турында.

Мөнәсәбәтләр. Кәҗәмөгез бик рәхәтләнеп киңәшләр бирә, авыр ситуацияләрдән чыгу юлларын күрсәтә. Әмма күңел белән ачылып, эмоцияләр бүлешеп утыруын көтмәгез инде! Көн саен шалтыратып хәл белмәвенә дә үпкәләп йөрмәгез. Аның дуслары күп түгел, әмма дус итеп сайлаганнарына ул гомере буе тугры кала.

Гаилә. Гаиләдә һәркемнең талантлы шәхес булуын тели Кәҗәмөгез хуҗабикә. Шуңа күрә телевизор, компьютер каршында бушка вакыт әрәм итәргә юл куймый. Өй чисталыгы, пөхтәлеге белән сокландыра. Кәҗәмөгез тыныч кына өйдә утыра торганнардан түгел шул! Алар эш белән мавыгып яшәргә ярата!

Карьера. Максатчан, сабыр һәм тормышчан булганнары өчендер инде, гыйнварда туган хатын-кызларны карьеристкалар дип атыйлар. Эш, карьера хакына бар энергиясен, көчен, сәламәтлеген бирергә әзер Кәҗәмөгез. Дөньяга хыял күзлеге аша карамый, чынбарлыкны, финанс якларын уйлап эш итүчән булганга әнә шундый ул.

Акча. Акчаны эшли дә, арттыру җаен да белә бу йолдызлыкта туган ханымнар. Акча алар өчен ул – ирек. Акчаны, әлбәттә, кул көче белән түгел, башны эшләтеп табалар.

Йолдызнамә февраль

Кучкар. Күп вакытыгыз мөнәсәбәтләрне җайлауга китәр. Эшегездә яңа үрләр яулау мөмкинлеге ачылыр. Сәламәтлегегезне кайгыртыгыз. Күңелегезне ишетеп, эчке интуициягезгә таянып эш итегез.

Үгезбозау. Тормыштагы һәр әйберне контрольгә алырга тырышканда, яшәгән көннәрдән тәм табарга вакыт калмый башлый. Шуңа күрә дилбегәне азрак җибәрсәгез дә була. Бу чорда сездән дөрес туклану таләп ителә.

Игезәкләр. Нәрсәгә ышанып яшәсәгез – тормышыгызга шул килер. Мөмкин кадәр күбрәк уңай уйлар дулкынында булырга тырышыгыз. Көтелмәгән финанс ярдәме килер. Дусларыгыз, күршеләрегез белән яхшы мөнәсәбәттә булыгыз.

Кысла. Бар дөньягызны мәхәббәт биләп алыр! Тирә-юньдәгеләр сезнең белән аралашудан рәхәтлек табар. Очрашуларга чакырсалар, берүк каршы килмәгез! Сезнең дә – яңа тормыш этабына күтәрелү вакыты.

Арыслан. Үткәндәге проблемаларның күләгәсе бүгенге көнне каплап торырга да сәләтле. Үткәннәр белән яшәүдән туктагыз! Көнкүрешегезгә үзгәрешләр, яңа гадәтләр кертегез, китаплар укыгыз. Бәхәсләшмәскә тырышыгыз.

Кыз. Өстәмә керем чыганагы табылыр. Житәкчегез уңышларыгызны күреп мактар. Витаминнар эчеп, сәламәтлекне ныгытыр вакыт, нерв системасын саклагыз. Ай ахырында икенче сулыш ачылганны сизәрсез.

Үлчәү. Үзегезнең никадәр бәхетле һәм кадерле кеше икәнегезне аңларсыз. Күбрәк рәхмәтле булырга һәм башкаларга карата киң күңеллелек күрсәтергә тырышыгыз. Сезнең өчен иҗади чор башлана. Күңелегез кушканча яшәгез.

Чаян. Яңалыкларга каршы килмәгез, ешрак «Әйе!» диегез. Гашыйк булып куюыгыз бар. Юлда йөргәндә йолдызлар сак булырга киңәш итә. Вакытны кирәксез әйберләргә сарыф итмәсәгез, ай ахырында зур уңышка ирешерсез.

Укчы. Дөнья сезгә көтелмәгән яктан ачылыр. Тормышта очраган төрле билгеләргә игътибар итәргә өйрәнегез әле. Акчагызны саклап тотарга кирәк булачак. Кичләрен үзегезгә ял бирегез.

Кәҗәмөгез. Өйдәгеләрнең җылысын тоеп, вакытны рәхәт итеп үткәрерсез. Китаплар укыгыз, яраткан фильмнар карагыз, табигатькә чыгыгыз. Максатларыгызны кәгазьгә теркәп барыгыз.

Сукояр. Башкаларны оптимист булуыгыз белән сокландырасыз! Тормыштагы кайбер ситуацияләр сез теләгәнчә бармый икән, борчылмагыз, уңыш сезнең якта. Тиздән бар да җайланачак. Ай ахыры шатлыкларга бай булачак.

Балык. Куйган максатларга ирешү өчен ай дәвамында актив булырга кирәк. Ялгыз Балыклар ир-ат игътибарына күмелер. Гаиләлеләргә балалары белән ешрак аралашырга кирәк. Эшегез шактый уңышлы барыр. Яңа проектларны чынга ашырыр вакыт җиткән.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.







«КҮҢЕЛЕМНЕ ТЫҢЛАДЫМ...»

Дебет-кредит, маркетинг стратегияләре... Лана өчен болар бар да инде үткән чорда. Әти-әнисе киңәшен ихтирам итеп икътисадчы һөнәренә укыган кыз ахырда барыбер үз җанын тыңлаган... Бишенче буын рәссамнар булган нәселдә нишләп соң әле рәссамлык рухы аны үзенә тартмасын ди?! Шулай итеп, өстәлдә кылкаләмнәр, буяулар пәйда булган, мольбертка зур чиста киндер куелган. Һәм, ниһаять, әти-әнисе дә кызларының күңел халәтен тулысынча аңлаган. Чөнки алар үзләре дә һөнәри рәссамнар: әнисе Татьяна Медвецкая – рәсем укытучысы, озак еллар Әлмәтнең проект-конструкторлык институтында эшләгән, ә әтисе Рафаэль Курамшин утыз елдан артык Әлмәт шәһәрендә баш рәссам буларак хезмәт куйган.

Лана бүген ире – танылган рәссам Ирик Мусин белән яңа үрләр яулый, күргәзмәләрдә катнаша, Россиядә һәм чит илләрдә узучы төрле пленэрларга юл ала.

Беренче шәхси күргәзмәсен Әлмәт картиналар галереясында ача. «Кечкенә вакытта укытучыбыз безне һәрвакыт шушы галереяга алып килә иде, биредә үз шәхси күргәзмәмне ачармын дигән уй башыма да килмәде... – дип искә ала Лана туган шәһәре белән бәйле истәлекләрне. – Матур тукымалардан интерьер уенчыклары тегү сәнгатен дә бик яратам. Әйткәнемчә, гаилә традициябезгә әйләнеп кайтып, язмышымны сынлы сәнгать белән бәйләргә булдым. Лекцияләргә йөрдем, шәхси дәресләр алдым, Мәскәүнең «Строганов традицияләре» сәнгать академиясе студенты булдым...»

Лана иҗат иткән, бер-берсен һич кенә дә кабатламаучы, бик тә үзенчәлекле куяннар, филләр, песиләр, аюлар кайсы илләрдә генә яшәми икән хәзер! Алар хәтта ерак Японияда дә бар! Ә бер уенчык төлкене мәшһүр югослав һәм серб кинорежиссеры Эмир Кустурица сатып алган. Ир-атка йомшак уенчык нигә кирәк, дисезме?! Илһам өчен, әлбәттә! Лананың күңел җылысы салынганга күрә бу сөйкемле уенчыкларның энергиясе коллекционерларны үзенә җәлеп иткәндер дә инде! Рәссам ханым картиналарын да шундый ук халәт аша тудыра.


Аның картиналарындагы һәр композиция тирәнтен уйлап төзелгән: аларда бөртекләп җыелган хис тә, бер-берсен камил тулыландыручы төс-төсмерләр дә, тамашачы күңеленә җиткерергә теләгән уй-фикерләр дә... «Рәссамлыкка озак алынмавым үз-үземә ышаныч җитеп бетмәү белән генә бәйле иде. Югыйсә сынлы сәнгать мәктәбен дә уңышлы тәмамладым... Аннан әнием ягыннан шундый зур, куәтле нәселдән мин – бу да үзенә күрә аерым бер җаваплылык өсти. Медвецкийлар Россиягә XVII гасырда күченгән. Безнең нәсел һәр ел саен үз Халыкара слёт-җыелышын үткәрә. Миндә татарлык та җитәрлек. Әбием Шакирә – мәдрәсә тәмамлаган мулла кызы. Дини, игелекле, юмарт, тырыш иде, тыйнаклыкны иң яхшы сыйфат билгесе дия торган иде. Чигәргә, бәйләргә, тегәргә бик яратам һәм боларның барысы өчен дә дәү әниемә рәхмәтлемен!

Лана Рафаэль кызы пейзажлар, натюрмортлар, жанрлы картиналар да яза. «Рәссам хезмәте ул – үз-үзеңә бикләнеп, көне-төне иҗат итү һәм хәтта бәйрәмнәрдән дә баш тарту. Кылкаләм, киндер, буяу... Болар минем өчен бар нәрсәгә караганда да якынрак!» – ди ул.

Лана – бүгенге көндә Painted Equator (Ясалган Экватор) Халыкара арт-проект илчесе, Россия рәссамнарының иҗади берлеге һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы. Ул инде илле гомуми күргәзмәдә катнашып, биш шәхси күргәзмә ачкан. 2020 елда республикада беренче тапкыр Харис Якупов исемендәге премия тапшырылды. Лауреатларның берсе – Лана Мусина-Медвецкая.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.
















ЛАНА МУСИНА-МЕДВЕЦКАЯ

2021 – ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



Кәтифә (Екатерина) ГАЙНЕТДИНОВА,
Piter.tatar порталы һәм этножурналистларның «Культура мира» Бөтенроссия Конгрессы журналисты, Санкт-Петербург.

Балачагым, үсмерлек елларым рус милләтеннән булган әниемнең туганнары янында – Көньяк Уралда узганда, төскыяфәтемдә дә, холкымда да татар халкына хас чалымнар чагылуын ишетеп үстем. Нидән бу? Каян килә? Аңлап бетермәсәм дә, хәтеремә тирән уелып калды ул. Үсә төшкәч, шул сораулар тынгы бирми башлады. Әнә шулай итеп үземә, үземнең эчке дөньяма, асылыма юл салдым. Татар тормышын, татар телен өйрәнә башладым.

29 яшемдә инде татар гаиләсе дөньясына ишекләр ачылды: Свердловск өлкәсендәге Уфа Шигере авылына – әти ягыннан туганнарым янына кайткалап килүләр журналист эшчәнлегем белән бергә үрелеп барды. Башта мөселман проектларында катнаштым, аннары – Мәскәү, соңрак Санкт-Петербург татарларының мәдәни тормышы казанында кайный башладым. Вакыйгалар, кешеләр, берлек эшләре мине моңарчы күрелмәгән милли төсмерләр белән баетты. Татар гаиләләре белән бәйләнешне тойган хәлдә, яңа эшләргә илһамланып алындым. Халкымның гыйлемлелеген, зирәк акылын башкаларга да җиткерәсем, аның тарихын өйрәнеп, тамырларыбызга якынаясым килде. Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе татарларын берләштерүче Piter.tatar порталы проекты – моның ачык мисалы. Тыгыз аралашу, үзара хезмәттәшлек, дуслык-татулык – болар татар гаиләләре тормышында олы маяк. Тирә-якта турбулентлык күзәтелгән, социаль тормышта ориентирлар югалган бер мәлдә ничек мөһим ул! Минем агачның – милләтемнең тамырлары нык, ул яшәү көче белән сугарылган! Аның шаулап үсәсенә, яңа шытымнар бирәсенә чын күңелдән ышанам мин!

